Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 44 (1409) 11 ноябрь 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga
madanizhomga
madani_zhomga

2

Казан университетының татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультетын хәзер сагынып искә алырга гына калды...

12

Инкыйлабка кадәр Оренбургта татар сәүдәгәрләре, татар зыялылары төзеткән барча тарихи ядкәрләргә бүген килмешәкләр хуҗа.

16

Татарстанның халык артисты Нәфкать Нигъмәтуллин, михнәтле балачак кичерсә дә, туган-үскән якларын һәрчак сагынып кайта.



Игелекле булу һөнәренә Кечкенәдән үсик өйрәнеп!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Россия башкаласындагы Шәрык дәүләт музеенда Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышланган «Мәскәү Коръәннәре» күргәзмәсе ачылды.

- Татарстанның биш театры «Алтын битлек» театр премиясен дәгъва итүчеләрнең башлангыч, киңәйтелгән исемлегенә кергән.

- Норлат шәһәрендә тынычлык һәм шәфкатьлелеккә багышланган «Тузганак» һәйкәле куелды.

- Казанның Яңа Савин районындагы 146 нчы «Ресурс» лицее укытучысы Мария Гайнетдинова «Педагогик дебют – 2022» Бөтенроссия конкурсында «Өстәмә белем бирүнең яшь педагоглары» номинациясендә җиңде.

- Миллəттәшебез Камилә Вәлиева фигуралы шуу буенча Россия Гран-приенең өченче этабында беренче урынны алды.

- Төркиянең Бурса каласында узган ТӨРКСОЙ утырышында Төрекмәнстандагы тарихи Анев шәһәре «2024 елда төрки дөньяның мәдәни башкаласы» дип игълан ителде.

- Татарстан китап нәшрияты Үзбәкстан башкаласында узган «TASHKENT BOOK FEST» халыкара китап күргәзмә-ярминкәсендә катнашты.

- Россия ислам институты дини уку йортлары студентлары арасында республикакүләм татарча вәгазь укучылар бәйгесе уздыра.

- «Мәдәният» илкүләм проекты кысаларында, «Татнефть» ширкәте ярдәме белән Әлмәттә заманча китапханә ачылды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Рамил МУЛЛИН, Түбән Кама шәһәре мэры:

«Бүген нинди орлык салабыз, 30-40 елдан соң шуның җимешләрен татырбыз. Без тәрбияләгән балаларыбыз – киләчәгебез. Бүген безгә хата ясамаска кирәк. 1990 елны буш орлык салганлык җимешен татыйбыз: агач үсте, ә җимеш юк. Бүген нәрсә татыдык? Алдыбызга бик зур мәсьәләләр килеп басты».

СЫНАМЫШЛАР

14 ноябрьдә кар яуса, язгы ташу мул була ● Әтәч бер аягында басып торса, тавык һәм казлар башларын канат астына яшерсә – суыта ● Таң алдыннан йолдызлар бик каты җемелдәсә, якын арада көн бозыла ● Каргалар көтүләре белән бер сәбәпсез каркылдашса, тиздән суыта ● Көз ахырында түгәрәк-түгәрәк вак кына боз яуса, кыш суык була.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **7 сәгать 10 минутта** чыкты, һәм ул **15 сәгать 44 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **8 сәгать 34 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **26 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни 1**8 ноябрьдә 8 сәгать 08 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

13 ноябрь – әдәбият галиме, филология фәннәре докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Резеда Кадыйр кызы Ганиеваның тууына 90 ел (1932–2020).

15 ноябрь – тел галиме, филология фәннәре кандидаты Каюм Сабир улы Сабировның тууына 100 ел (1922–1979);

– шагыйрь Хатыйп Касыйм улы Исрафиловның тууына 90 ел (1932–2009).

16 ноябрь – шагыйрә Асия Миръякут кызы Минһаҗевага 70 яшь (1952);

– язучы, шагыйрә, публицист Кояш Закир кызы Тимбикованың тууына 85 ел (1937–2004);

– җырчы, Татарстанның халык артисты Нәфкать Тимергали улы Нигъмәтуллинга 60 яшь (1962).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Ноябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 11, 15 ноябрь.**

* * *

Гадәттә, тулы айдан айның соңгы чирегенә кадәр **(8-16 ноябрь)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **25 октябрьдән 31 декабрьгә кадәр** бөер һәм бәвел куыгы актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген рабигүл ахир аеның 17 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН,
филология фәннәре докторы

«ТАТФАК»ны юксыну

Милләт балаларын барлык фәннәрне диярлек үзебезнең Тукай телендә укыту турында ничәмә-ничә буын хыялланып та, инде өметләребез өзелер дәрәҗәгә җиткән бер мәлдә, үткән гасырның соңгы чирегендә милли күтәрелеш йогынтысында мәгариф, мәгърифәт, матбугат, югары белем өлкәләрендә ирешелгән уңышларның бер нәтиҗәсе – Казан дәүләт дарелфөнүнендә татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультеты (ягъни татфак), соңрак аның каршында кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен яклау шурасын гамәлгә кую булды. Милләтебезнең алдынгы, үзфикерле катламы хөрриятнең бик азга һәдия ителгәнен сизенеп, һәр төбәктә татар бүлекләрен, гимназияләрне, мәктәпләрне ачып калырга тырышты.

Әмма ун ел элек бик күп уку йортларын, аерым алганда, Казан педагогика университетын, Гуманитар институтны «йотачак» КФУ оешкан чорда, нәкъ менә татфак тегермән ташы астында калды. Г.Исхакый әйтмешли, моңсу «сүземез» шул хакта.

Халкыбыз кичергән бөек тә, әрнүле дә олы тарих бизмәненә салып бәяләгәндә, нибары бер «мизгел» – 20 елга якын гына яшәп калса да, тирән белемле, милли җанлы укытучылар, галимнәр, гаярь журналистлар, язучылар әзерләүдә җуелмас һәм онытылмас эз калдырган «татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр» факультетын ниндидер гаҗәеп магик дулкында юксынып, сагынып искә алучыларның бер мин генә түгеллеген тәгаен беләм. Биш сүзле исем «туган тел», «газиз милләт», «милли мохит» кебек иң изге төшенчәләрне ачыклап килә иде сыман.

Әлеге гыйльми-мәдәни берәмлекне халкыбызның төрле катламы газиз баласы кебек кабул итте. Өлкән буын, хәтта нәзберек дин әһелләре дә аны Мөхәммәдия, Галия, Иж-Бубый мәдрәсәләренең дәвамчысына тиңләсә, Кытайның үзеннән чакырып китерелгән укытучылар төрле халыклар, татарның «күк атларында» бергәләп Алтай далаларында, Ерак Көнчыгышта яшәгән чорларын мәңгүси аңнарда уятып куйса, күпчелек милләттәшләребез факультетны туган телебезне саклау, үстерү, киләчәк буыннарга җиткерү юнәлешендә ирешелгән җитди адым – алгарыш дип бәяләде.

Татарларның Ватан сугышында күрсәткән батырлыкларына шаклар каткан җаһил Сталин «бүләк» иткән бүлекне үстереп оештырылган, яңа уку-укыту берәмлеге, экияти бала төсле, гаҗәеп тизлек белән аякка басып, елдан-ел үсә барып, студентлар саны, укытучыларының абруе буенча, хәтта күз өстендәге каш кебек, кадер-хөрмәттә яшәгән, юридик факультеты белән күп җәһәттән, «син»гә күчеп сөйләшә алу дәрәҗәсенә күтәрелә.

Яшьлекләренә әйләнеп кайткандай очынып (кызганычка, күбесе инде «оҗмах кошлары») йөргән, деканатның һәр гозерен үтәргә әзер профессор-доцентлар, күренекле татар галимнәре Д.Тумашева, В.Хаков, Ф.Хисамова, Г.Саттаров, Ф.Юсупов, Ә.Әфләтунов, М.Мәһдиев, Ф.Сафиуллина, С.Ибраһимовлар башларын югары тотып, ихтыяҗ булганда, борыннарын да «чөеп» җибәргәләде. Хәзергәчә әдәбият мәйданы дисбесен кулларында тоткан Х.Миңнегулов, М.Бакиров, Д.Заһидуллиналар турында сүз катып та тормыйм. Татар факультетын бөтен ислам дөньясы гына түгел, безнең фәннән ераграк торган эшмәкәрләр дә җылы кабул итте. Матди ярдәмнәр дә күрсәтелде. Өр-яңа компьютерлар, язу машинкалары, затлы җиһазлар алынды. Университетның икенче уку бинасының 11 катына «җан керде». Германиянең төркиләр күпләп яши торган Гиссен шәһәре университеты белән ижади хезмәттәшлек факультет «күзен йомганчы» дәвам итте.

Татфакка конкурс хәттин ашты, бар имтиханнарны да уңышлы тапшырып, тиешле балларын җыйган абитуриентларга урыннар җитми башлап, ярдәм сорап мәгариф министрлыгына мөрәҗәгать иткәч, Декабристлар урамында элеккеге балалар бакчасын биреп, стипендиягә, хезмәт хакына акча табылгач, тиз арада Гуманитар институтны оештырып җибәрдек. Анда да безнең укытучылар дәресләрне факультет программасы нигезендә алып барды. Татар факультетының уңышлары, гөрләп үсүе, кемнәрнеңдер «саруын кайнатты», кинәт оешкан КФУ офыкта пәйда булганчы ук, аны таркату башланды.

Университетта заманында «Восточный разряд» булган, аны торгызырга вакыт дигән сылтау белән, көнчыгыш телләр бүлеген тартып алдылар, соңрак кушылу сылтавы белән факультетны яңадан бүлек дәрәҗәсенә төшерделәр. Чөнки яңа гасыр башыннан уртак илебездә, буйсынган милләтләрнең мәнфәгатьләрен, бигрәк тә телләрен кысрыклау, биздерү, тыю дәүләт сәясәте дәрәҗәсенә күтәрелде. Гаять зур авырлык белән ачылган татар теле, әдәбияты бүлекләре, милли гимназияләр, мәктәпләр («ата-ана үтенече белән»), күз ачып йомганчы, яшәүдән туктады. Татарча укытуны дәвам иткән, үз фикерле, милли җанлы мөгаллимнәрне, әләкчеләр ярдәмендә ачыклап, төннәрен прокуратура вәкилләре «уята», өркетә башлады. Сәясәткә катнашмыйча, бары тик югары кимәлле белем биреп яткан төрек укытучылары, шымчылыкта гаепләнеп, илдән куылды.

Яңа программа белән укыту, «прогресс шуны таләп итә» дип аңлатсалар да, иң кешелекле, иң гуманлы татар галәменә якты нур бөркеп яшәгән факультетның «кушылу» дигән сылтау белән юкка чыгарылуына һич кенә дә ышанасы килми. Аның күп төрле үз сәбәпләре бар. Факультет рәсми яшәүдән туктаса да, аның рухы халәтебездә яши. Мәдәният, мәгариф, матбугат белән бәйле кайсы оешмага кагылсаң да, анда тиз арада рәсми «күзен йомган» факультетта белем, әхлак дәресләре алган шәхесләргә тап буласың һәм ошбу гаделсезлекне кичерә алмыйсың! Кыска гомерле булса да, милли яшәешебездә җуеп та, онытып та «котыла» алмаслык зыялы, белемле катлам әзерләп калдыра алган газизебез. Әйтик, «Казан утлары», «Шәһри Казан», ТНВ каналы кебек матбугат үзәкләренең баш мөхәррирләре шунда укып, аспирантура узып, берсе – Р.Галиуллин җиһан буйлап сибелгән татарларның язмышын барлап, гаҗәеп бай мирас калдырган Тәүфыйк Әйди иҗатын үзәккә алган, Р.Сабиров «Туфан лирик героеның рухи дөньясы» дигән темага кандидатлык диссертацияләрен яклап, дипломнарын сейфларына «биклап» куйды. Мөхтәрәм журналыбызның иң четерекле, авторлар белән бимазалану кебек «эчке эшләре» өчен җаваплы сәркатибе Л.Әбүдарова Г.Кариев исемендәге яшьләр театрының җитәкчесе Луиза Янсуар татфакта бер төркемдә укыган зат. Икесе дә – иңнәренә фәрештә канаты кагылган шагыйрәләр.

Озак еллар «Мәдәни җомга»бызның сәркатибе вазыйфасындагы матбугат «гизәре» Илгизәр Зәкиев тә тыйнаклык һәм әхлак дәресләрен татфакта алган. Күптән түгел басылып чыккан «Гаиләдә дип алданмыйк» (М/Ж. №27, 2022) исемле мәкаләсендә кайсы беренчел булган, «тавыкмы әллә йомыркамы» дигән мәңгелек бәхәскә «аң» белән «яшәеш» арасындагы (кайсы беренчел) мөнәсәбәтләр турында уйлану белән килеп кереп киләчәк буыннарга телебезне (димәк, милләтебезне) саклап калдыру мәсьәләләрен күтәрә һәм хаклы рәвештә, «Телне мәҗбүри өйрәтү ихтыяҗ гына саклый ала», дигән гөманын һәм таләбен калкытып куя.

Татфакта белем, тәрбия алып, туган халкының язмышы өчен җан атып, «амбразураларны» күкрәкләре белән капларга торган, Татарстанда гына түгел, төрле төбәкләрдә яшәүче фидакяр көрәшчеләребезне дә онытасы түгел. Мин үзем белгән күп санлы мисаллардан берсен генә китереп узам. Ул – Марий Эл башкаласы Йошкар-Олада татар иҗтимагый үзәген үз кулына алып, Казандагы барлык чараларга милләттәшләребезне алып килүче Рамай Юлдашев (кушаматы – «татар Чапае»). Җитәкчелекне, телебезне, милли мәнфәгатьләребезне яклауда йомшак битарафлыклары турында телевизордан әйткән сүзләре өчен аны кулга алып, зинданга ябып куялар. Шул хәбәрне ишеткән татфак студентлары (500 ләп кеше), азатлык мәйданына, опера һәм балет театры каршына тезелеп басалар һәм полиция полковнигы «бүген аны чыгарабыз» дигәч һәм деканат үтенече буенча, уку бинасына кайттылар. Рамайны азат итсәләр дә, Татарстанда яшәтмәделәр һәм ул күрше мәмләкәт җиренә күченеп, хатыны – мари кызын татарчага өйрәтеп, милләте өчен көрәшүен дәвам итә. Шундый кыю, тәвәккәл егет-кызларыбыз күбрәк булсын иде.

Тыйнаклык кәсафәтен читкәрәк куеп, татфакта белем алганнарны президент аппаратында, министрлыкларда, Язучылар берлеге, радиокомитет, конгресс һәм иҗтимагый-сәяси оешмаларда хезмәт итүче мөхтәрәм затларны санап чыгу мөмкин түгел. Аларның күбесе – милләт хадимнәре – зурлап искә алуга лаеклы. Мин «татфак эзсез югалмады, ул хәтер ярларында яши» дигән ышанычымны раслау өчен, үземә танышрак та, изгерәк тә фәнни-гамәли мөхите игътибар үзәгенә алып, язгы ташкындай буаларны ерып чыккан шәхесләрне олылыйсым килә.

(Дәвамы 4 нче биттә).

Илаһи рухсыз симфония тумый

Россия Президенты В.Путинның «Валдай» форумында әйткәннәре җәһәтеннән туган кайбер фикерләр белән уртаклашуыбызны дәвам итик (башы газетабызның узган санында). Темадан тайпылмас өчен, бераз озынрак булса да, аның чыгышыннан бер өземтә дә китерик. Экологик проблемаларга бәйләп, чыгышының төп юнәлешен ул: «Одно из опаснейших последствий нарушения экологического баланса – это сокращение биоразнообразия в природе. И сейчас перехожу к основной теме, ради которой мы все и собрались: разве менее важно другое разнообразие – культурное, социальное, политическое, цивилизационое? Вместе с тем упрощение, стирание всех и всяких различий стали чуть ли не сущностью современного Запада. Что стоит за таким упрощением? Прежде всего это исчезновение творческого потенциала самого Запада и стремление сдержать, блокировать свободное развитие других цивилизаций... Не случайно Запад утверждает, что именно его культура и мировоззрение должны быть универсальными», – дип билгеләде. Гомумән алганда, монда хилафлык юк та кебек. Тик игътибарны сүз белән гамәл арасындагы капма-каршылык җәлеп итә.

Бүгенге хәтәр хәлләрне В.Путин дөньяны америкача (неолибераль) кору моделенең доктриналь кризисы буларак бәяли, чын демократия исә күпполярлы дөньяда теләсә кайсы халык, җәмгыять яки цивилизациянең үз юлын, үз социаль вә сәяси системасын сайлап алу мөмкинлеген күздә тота, дип саный. Боларны тыңлагач, 22 еллык хакимлектән соң, бәлки, Россиядә төп халыклар өчен чын демократиянең үрнәк моделе табылгандыр, дип тә уйлап куясың. Әмма эшләр нәкъ киресенчә тора: сайлау һәм демократик нормалар имитацияләнә генә, ә 90 нчы елларда төп халыклар сайлаган юллар инде эзе дә калмаслык итеп бетерелде һәм илдә авторитар режим урнаштырылды. Реаль тормышта исә бүгенгәчә бөекдержавачыл шовинизм идеологиясе өстенлек итә. Җөмләдән, ул әлеге форумда да сизелде: һавада өрәк булып А.Солженицын, Ф.Достоевский кебек каләм әһелләре рухы эленеп торса, залда инде экспертлар сыйфатында А.Проханов ише державниклар утырды. Төп чыгышта яңа фикерләр ишетелмәде. Әмма кешелек үсеше, цивилизацияләр диалогы рәвешендә, рухи вә әхлакый кыйммәтләргә таянып барырга тиешлеге әйтелде. Президент үзенең чыгышын киләчәк дөнья төзелешен, һәр караш вә идеяне исәпкә алып һәм һәр халыкны ишетеп, шулай ук һәр мәсләк, дөньяга караш һәм дини күзаллауларны да игътибарга алып, шул ук вакытта беркемгә дә ниндидер уртак карашны көчләп такмыйча, әмма халыклар язмышы өчен җаваплылыкны да тоеп, кешелек цивилизациясенең симфониясе итеп корырга чакыру белән төгәлләде.

Мәсьәләнең фәлсәфи ягына килгәндә, «кешелек цивилизациясенең симфониясе» дигән гыйбарә, асылда, планетада цивилизацияләр берлеге булдыру һәм алар арасында гармонияле яшәешкә дә ирешүне, ягъни Җирдә илаһият кануннары буенча яши башлауны аңлата. Сүз дә юк, фикер йөртүдәге мондый борылыш Россия өчен уңай күренеш. Әмма анда каршылыклар да күп. Төп каршылык – илаһият өлкәсенә кагылышлы проблеманы геосәяси ысуллар белән хәл итәргә омтылуда. Башка төрдәге каршылыклар да җитәрлек. Әйтик, В.Путин Россиянең гегемонлыкка омтылмавы турында белдерә, әмма аның эчке вә тышкы сәясәте моның нәкъ киресе турында сөйли һ.б. Шул ук вакытта ул барлык бәлаләрдә Көнбатышны гаепли, яңа чорның төп каршылыгын да Көнбатышның дөнья белән үзе генә идарә итәргә омтылуында, әмма моңа сәләтсез булуында күрә. Чөнки дөньядагы күпчелек халыклар моны теләми.

Ә катлы-катлы каршылыкларга ачкыкны геосәясәтнең туу тарихы кертә. Ул семит диннәренең (иудаизм, христиан дине һәм ислам) формалашу һәм таралу тарихына ук барып тоташа. Дөнья тотучылар Көнбатышны да, Кытай цивилизациясенә альтернатива буларак, иудаизм һәм христиан кыйммәтләрендә формалаштыра. Россия исә, империя («Өченче Рим») һәм Кытай белән ике арада буфер зонасы буларак, Урталык җирләрендә тотыла. Дөнья тотучылар аны (аның халкын) бөтен тарихы буена (бүген дә!) «сәясәт коралы» һәм «туп азыгы» итеп куллана. Геосәясәттә исә бүген Көнбатыш һәм Россия, капма-каршы яктан, әмма уртак максатларда (яңа дөньяви тәртип урнаштыру) эш итә. Мондый экскурстан соң, хактыр ки, катлы-катлы каршылыкларның да һәркайсы үз урынын ала. Ә цивилизацияләр симфониясе турындагы сорауларга җавапны инде киләсе язмаларда эзләргә туры килер.

Фоат УРАЗАЙ.

Җәлил мәктәбендә җыен

Мәскәүнең Муса Җәлил исемендәге 1186 нчы мәктәбе 25 еллыгын бәйрәм итә. Хәзер мәктәптә 32 милләт баласы белем ала, дүрт музей («Дөнья мәдәнияте галереясе», «Разведка легендалары», «Татар халкының мәдәнияте һәм көнкүреше музее», «Мәктәп тарихы») эшли, татар телендә дәресләр үткәрелә. Уку йортында «Җәлилчеләр» балалар иҗтимагый берләшмәсе эшләп килә, мәктәп «Яңарыш һәм Өмет» фондының «Ватан даны хакына» иҗтимагый медаленә лаек булган, биредә ел саен билбау көрәше буенча турнир үткәрелә. 2015 елда мәктәптә «Каюм Насыйри институтының белем бирү-мәдәни үзәге» ачылды.

Муса Җәлил исемендәге мәктәпнең юбилеена багышлап «Көчле кешеләр» фильмын төшергәннәр.

25 еллык уңаеннан уку йортында «Россия Федерациясендә яшәүче халыкларның туган телләрен саклау» дигән темага багышланган түгәрәк өстәл узды. Чарада РФ Мәгариф министрлыгы, Россия Фәннәр академиясе, белем бирү оешмалары вәкилләре катнашты. Мәктәп кунакларын РФ Дәүләт Думасы депутаты, Федераль татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Илдар Гыйльметдинов сәламләде. Түгәрәк өстәлгә шулай ук Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, республиканың Премьер-министры урынбасары – Татарстанның Россиядәге Вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин, генерал-полковник Рәсим Акчурин, герой-шагыйрьнең кызы Чулпан Җәлилова һ.б да килгән иде.

Берлектә яңа әгъзалар

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе өч кешене күпчелек тавыш белән үз сафларына кабул итте. Уфада яшәүче татар язучысы Мөнир Вафин, Алабугада яшәүче әдәбият галиме, язучы Гомәр Даутов һәм Казанда яшәүче Людмила Уфимцева берлекнең яңа әгъзалары булды.

«Башкортстанда яшәүче татар язучылары – безнең илчеләребез. Алар сирәгәя башлаган иде, ләкин андыйлар булырга тиеш. Мөнир Вафин шундый илчебез булачак. Башкортстанда безнең миллионнан артык татарыбыз бар. Ул милләтпәрвәр шәхес», – диде Татарстан Язучылар берлегенең кабул итү комиссиясе рәисе, халык язучысы Зиннур Мансуров.

Гомәр Даутов кандидатурасын караганда язучылар әдәби тәнкыйть юнәлешенең соңгы елларда бик аксавын билгеләп үтте. Алар үз араларына алынган галимгә бу юнәлештә зур өметләр баглады. «Безгә әдәби тәнкыйтьне нигытырга кирәк. Ул чеметеп тә алсын, безне уятып та җибәрсен. Безгә җанлы тәнкыйть кирәк. Гомәр Даутовны шушы максатларны күздә тотып Язучылар берлегенә тәкъдим итәбез», – дип чыгыш ясады З.Мансуров.

Өченче яңа әгъза – Людмила Уфимцеваны берлекнең рус телендәге әдәбият остаханәсе җитәкчесе, язучы Әхәт Мушинский тәкъдим итте. Язучылар Людмила Уфимцеваның күренекле әдип Геннадий Паушкин истәлегенә багышланган китабын югары бәяләде.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

Хезмәт кешесе бәйрәме

Казанда «Наше время – Безнең заман» X ачык республика телевизион фестиваленең йомгаклау гала-концерты узды. Бу фестиваль төрле эшче һөнәр ияләре булган яшьләр арасында үткәрелә.

«Безнең фестиваль елдан-ел киңәя: быел 185 предприятие, оешма һәм учреждение чыгыш ясый. 1600 дән артык кеше катнаша, шулардан 600 кеше бүген безнең белән», – диде Татарстан Президент Рөстәм Миңнеханов гала-концерт ачылышында.

«Бүген без дәүләтебез өчен иң мөһиме – хезмәт кешесе икәнен аңлыйбыз. Бу кешеләр безнең республика предприятиеләрендә һәм оешмаларында эшләп кенә калмый, алар талантлы да. Без фестивальнең үсеш динамикасын күрәбез, шулай ук предприятие җитәкчеләреннән дә ярдәм таптык. Фестиваль коллективларны чын мәгънәсендә берләштерә», – дип белдерде Р. Миңнеханов .

Гала-концертка кадәр өч сайлап алу этабы үткәрелде. Алар Әлмәт, Түбән Кама һәм Казанда узды. Беренче зона этабы өч йөзгә якын катнашучы җыйды, Түбән Кама туры – дүрт йөздән артык артистны, Казан этабы – алты йөздән артык башкаручыны җәлеп итте.

Быел Гран-прига «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе командасы лаек булды. Ул Татарстан Президентының күчмә кубогын, фестиваль иганәчеләрненнән бүләкләр һәм 500 мең сумлык акчалата сертификат алды. «Безнең заман герое» махсус призы «КАМАЗ» гавәми акционерлык җәмгыяте командасына бирелде. Командага кубок һәм 300 мең сумлык сертификат тапшырылды.

Фәтвалар һәр заманда кирәк

Казанда «Фәтвалар чыгару методологиясе: хәзерге заман проблемалары» дип исемләнгән ике көнлек семинар узды. Әлеге чараны Россия ислам институты, Татарстан мөфтияте Төркия дин эшләре идарәсе һәм Ислам мәдәниятенә, фәненә һәм мәгарифенә ярдәм фонды белән бергәлектә үткәрде. Семинарда Төркия дин эшләре Югары Советы, шулай ук Казахстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Азәрбайҗан, Монголия, Беларусь һәм Россия төбәкләренең Диния Нәзарәте җитәкчеләре катнашты.

Семинар барышында заманча проблемаларны хәл иткәндә фәтваларны куллану практикасы, исламда хокук белән бәйле мирасны куллану мөмкинлекләренең колачы, төрле мәзһәбләрнең фәтваларын куллану принциплары, барлык мөселманнарга кагылышлы сорауларны хәл итүдә фәтваларны бергә туплауның мөһимлегенә кагылышлы мәсьәләләр каралды. Төрле илләрнең галимнәре үз илләрендә фәтваларның ничек чыгарылуы, шулай ук әлеге эш барышында нинди проблемалар белән очрашырга туры килүе турында сөйләде.

1 нче биттә – Казандагы Серафим Саровский чиркәве мәхәлләсенең рухи һәм иҗади үсеш үзәгендә балалар өчен бер осталык дәресе. Фото: president.tatarstan.ru

Гали Рәхимне яд итү

Казандагы Яңа Татар бистәсе зиратында күренекле татар галиме, язучы Гали Рәхимгә истәлек тактасы куелды. Бу чара Г.Рәхимнең тууына 130 ел булуга багышланган иде.

Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры Радик Салихов бу шәхескә әле дә тиешле бәя бирелмәвен әйтте: «XX гасыр башында ул татар мәдәнияте һәм фәне өмете була. Гали Рәхим бай гаиләдә туа, сәүдә юнәлеше буенча белем ала, әмма бөтен гомерен татар тарихы, әдәбияты, мәдәниятына багышлый».

Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият бүлеге мөдире Әлфәт Закирҗанов фикеренчә, Гали Рәхим – татар әдәбиятында тирән эз калдырган шәхесләрнең берсе: «Беренче драма әсәрләре белән танылганнан соң, ул әдәби тәнкыйтькә, әдәбият фәненә килә. 1920 нче еллар башында тарихчы Газиз Гобәйдуллин белән берлектә «Татар әдәбияты тарихыннан материаллар» дип аталган җыентык әзерли. Ул татар әдәбиятын яңача өйрәнү концепциясенә нигез салучыларның берсе булып таныла. Без бүген дә аның хезмәтләренә мөрәҗәгать итәбез».

Яңа Татар бистәсе зиратын өйрәнгән тарихчы Айдар Гайнетдинов сүзләренчә, Гали Рәхим кабер ташларын өйрәнгән булган. Бу зиратта язучының әнисе һәм бабасы да җирләнгән. «Гали Рәхим җирләнгән урынны аның сеңлесе Рауза

ханым белгән. 1991 елда бу урынны ул язучы Шаһинур Мостафин һәм Мөхәммәт Мәһдиевкә күрсәтә. Яңа Татар бистәсе зираты турында китап әзерләгәндә, без Гали Рәхим исеменә тап булдык. Барлык чыганакларда җирләнгән урыны билгесез, дип язылган иде. Миңа очраклы рәвештә: «Шаһинур Мостафин белергә тиеш», – диделәр», – дип сөйләде ул. Тарихчы сүзләренчә, язучы аңа төгәл урынны түгел, ә бернечә кабер ташы торган мәйданны күрсәтә.

«Аның каберендә бервакытта да таш булмаган. Җирләгәч, такта гына куйганнар. Сугыш еллары булгач, ул такта да юкка чыккан», – диде А. Гайнетдинов. Ул Гали Рәхимнең репрессиягә эләгеп, ике тапкыр төрмәгә эләгүен искә ала. Икенче тапкыр төрмәдә утырганда ул чирли башлый, һәм аны 1943 елның февралендә кайтарып җибәрәләр: «Карар буенча, ул Кукмарага кайтырга тиеш була. Хәле авыр булганга, кайта алмый. Казанда Горький урамындагы йортның подвалында апасында ике атна яшәп кала, март аенда вафат була. Апасы аны Кукмарага алып кайта алмый, яшерен рәвештә бу зиратка җирләргә туры килә. Апасы зират хезмәткәрләре белән сөйләшә һәм аны монда төнлә чаңгы белән алып киләләр, качып җирлиләр».

«Гали Рәхим алтмыштан артык кабер ташын өйрәнгән. Казан ханлыгы чорындагы ташларны өйрәнү ул заманда батырлык булып саналган. Г. Рәхим башкаларның игътибарын тарихка җәлеп итәргә тырышкан. Без ул өйрәнгән кабер ташларын күрдек, аларның язулары юкка чыккан. Вакытында өйрәнеп калуы зур файда булды», – дип сөйләде тарихчы.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Илсөяр Иксанова сүзләренчә, Гали Рәхимнең иҗатына мөрәҗәгать итүчеләр яшьләр арасында да бар. «Аның зур мирасы калмаган, әмма һәр эше тирән мәгънәгә ия. Аның хикәяләрен үрнәк итеп күрсәтергә була. Соңгы елларда аның иҗатына игътибар артты. Туган телләрен саклау, үстерү комиссиясе оештырган бәйгедә Лилия Гыйбадуллина аңа багышланган поэмасы белән беренче урын алды», – диде ул.

Гөлүзә ИБРАҺИМОВА.
А.ФАРХАН фотосы.

Төньяк кала татарлары үткәнне барлый

Ленинград өлкәсе дуслык йортында Идел буе Болгар дәүләтенең ислам динен кабул итүенә 1100 ел тулуга багышланган түгәрәк өстәл булды.

Түгәрәк өстәлне Татарстан Республикасының Санкт-Петербург шәһәре һәм Ленинград өлкәсендәге Тулы вәкаләтле вәкиле урынбасары Дамир Сабиров ачты. «Изге юл» иҗтимагый оешмасы рәисе Иниятулла Кутуев татар халкы тарихын, Петербург шәһәрен төзегән вакытта бирегә аларның ничек килеп урнашуын искә алды. Тосно һәм Любань шәһәрләренә исә татарлар икенче дулкында килгәнлеген аңлатты.

Журналист һәм язучы Рәхимҗан Теләшев үз чыгышында ислам һәм христиан диннәре, аларның охшаш һәм аермалы яклары хакында сөйләде. Ул Ленинградта татар хәрәкәтенең ни рәвешле үсеш кичерүен, Корбан бәйрәме һәм хәйрия эшчәнлегенең яңадан үткәрелә башлавын искә алды.

Р.Теләшев Коръәннең шигъри тәрҗемәсе авторы Теодор Шумовский, татарларга гарәп телен өйрәткән Мөхлисә Зарипова хакында да сөйләде.

Кичә кунаклары «Файда» татар мәдәнияте җәмгыяте җитәкчесе Айрат Маннанов белән бергә, татар һәм чуаш музее ядкәрләре белән танышты. Анда Чуаш җәмгыяте рәисе Валериан Гаврилов атаклы чуашлар һәм чуаш халкы тарихы турында күп кызыклы мәгълүмат җиткерде.

«ТАТФАК»ны сагыну

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Гомерләрен архивларда, китапханәләрдә утырып, каләмнәреннән төшкән һәр җөмләсе өчен янып-көеп яшәгән затларны мин хезмәт батырлары, иген игүчеләр, чуен эретүчеләр, урман кисүчеләр белән бертигез бәяләр идем. Диссертация язучылар фәнни дәрәҗәгә ирешүнең җелегеңне суырган авырлыкларын белсә дә, аңлы рәвештә шул омтылыш-хыялдан баш тарткан шәхес белән, гафу итегез, минем «танышлыгым» юк. Фәнни дәрәҗәгә лаек булуның абруйлы гына түгел, «төшемле» дә икәнлеген күренекле галим, усал телле тәнкыйтьче Гали Халит, үзе сират күпере кичеп, доктор булып алгач, безне, ул чорда әлеге дәрәҗә турында хыяллана да алмаган кече фәнни хезмәткәрләрне ирештереп, шаярта торган иде: «Доктор – тик тор! Әмма – тук тор!»

Әзер диссертацияңне яклауның да җиңел гамәл түгеллеген үзе шул хәятта «әвәрә» килмәгән кеше аңлап бетермәскә, хәтта күз алдына китерә алмаска да мөмкин.

Фәнни җитәкчең абруйлы, хезмәтең югары сыйфатлы булса да, аны төрле дәрәҗәдә кат-кат тикшерүләр, аерым алганда, синең «нурлы йөзеңне» төшендә дә күрергә теләмәгән галимгә укырга бирү кебек сынауларны үтәргә туры килә. Мин фәнни әзерлекле, җитлеккән өлкән әдәбият галимнәре Х.Госман, Г.Халит, Г.Кашшаф, А.Сайганов, И.Нуруллиннарның диссертацияләрен алтмышка җитеп килгәндә генә яклагандагы сыйнфый күзлектән чыгып бәя бирүләрне, ачыктан-ачык, «ул доктор исемен йөртүгә лаек түгел», дип урыннан кычкыруларны күздә тотмыйм. Иншалла, хәзерге яклауларда зыялылык рухы өстенлек итә. Мәгәр, астыртын, бары тик көнчелек белән генә аңлатылган, психологик яктан мин-минлеккә, үзеңне күрсәтеп калуга нигезләнгән «төер» әле дә безнең белән. Шул ук вакытта, фәнни дәрәҗәгә омтылуны берминди «дошмани» көч тә туктата алмый. Академик А.Таһиров язганча, «Телебезгә карата кылган явызлыкларга каршы татар фәне күтәрелә» (М/Җ., №24. 2022). Иншалла, шулай була күрсен!

Җае чыкканда, тел-әдәбият фәнебез үсештә, галимнәребез бихисап дип күкрәк кагып алгаласак та, фәнни дәрәҗәгә тәгаенләү шурабыз үткән гасырның туксанынчы еллары башында гына оешты. Шуңа чаклы эшеңне Мәскәүдә яисә ул чорлардагы союздаш республика башкалаларында урнаштыру җаен эзләргә туры килә иде. Мин, мәсәлән, безгә тел һәм рухи урталык ягыннан хәерхаклырак Казахстанга барырга булдым. Әдәбият институты директоры, шигырь төзелеше буенча зур белгеч Зәки Әхмәтов бик җылы каршылап, хезмәтне тикшерергә җибәргән кафедра уңай бәя биреп, эшне советка чыгарырга тәкъдим итте.

Чит советта яклауның мәҗбүри үтәлергә тиешле ягы бар икән: шурага үз белгечлегең, ягъни татар әдәбияты буенча, өч доктор вакытлы әгъза булып керергә тиеш. Сабакташым, соңрак үзе дә шул мәшәкатьләрнең «ләззәт»ен татыган, филология фәннәре докторы Фәрит Юсупов белән «татар десанты»н туплауга керештек. Ерак юлларга алып чыгарлык докторларыбызның санаулы икәненә инандык: берсе – чирле, икенчесе – «назлы түрә», өченчесе – синең мәүзугтан ерак тора... Көчкә-көчкә Г.Халит, Н.Юзиев, Ә.Кәримулиннарны юлга чыгарга күндердек. Тәрәзәдән Ала-Тоо матурлыгы күренеп торган кунакханәдә яшәүдән, үзара һәм казах галимнәре белән аралашудан барысы да канәгать калды. Минем эздән барып, Ф.Хатыйпов, А.Әхмәдуллиннар доктор булуга лаеклы икәнлекләрен шунда раслап кайтты.

Мин үз башымнан узган мәшәкатьләрне «мактану» яисә «җәлләтү» өчен әйтмим. Ахыры сөенечле бу низагларны «булганын саклый белик, бер-беребездән көнләшеп, үзәккә хатлар юллап, аяк чалулардан котылыйк» дигән фикеремне әйтеп калу өчен генә искә төшерәм. Үзебездә яклау шурасын ачу артыннан йөргәндә, безгә уңай карашлы, ВАКның бүлек мөдире, милләте белән чечен А.Парастаевның: «Азәри белән грузиннардан тартма-тартма коньяк, ә Казан белән Уфадан төргәк-төргәк шикаять хатлар килә», – дип төрттерүе күңелдән китми.

Чит-ят җирләрдә яклаулар авырлыгы диссертацияләр шурасын үзебездә ачу киреклеген көн тәртибенә китереп бастырды. Эшләре әзер булса да, чит-ят мәмләкәтләргә барып йөрерлек исәнлекләре яисә матди мөмкинлекләре булмаганнары өчен андый берәмлекнең Казанда булуы бигрәк тә мөһим иде.

Үзебездә яклау шурасы ачуны ул чорда уку-укыту буенча дарелфөнүн проректоры М.Госманов хуплады һәм һәръяклы ярдәмен күрсәтте. Төрле рәсми кәгазьләр белән мөгаллимнәр Х.Миңнегулов, К.Биктагиров, И.Гыйләҗев һ.б. Мәскәү юлларын күп тапкыр таптады.

Аның каруы, яклау шурасы 20 ел дәвамында бик күпләргә фәнни дәрәҗә мантиясен «бүләк итте». Андый мөмкинлеге булмаган (совет 80 процентка докторлардан торырга тиеш) адыгей, якут, алтай, хакас, тува кебек халыкларның галимнәренә азмы-күпме булышып кала алды. Шәхсән, минем фәнни җитәкчелектә генә өч дәгъвачының икесе алтай, өченчесе хакас әдәбияты буенча иде. Аларга әүвәл татфакта стажировка үтәргә туры килде. Кандидатлыкларын уңышлы яклап, хәзер үзләрендә укытып, бездә оештырылган һәр гыйльми конференциядә катнашырга ашкынып торалар.

● Экология һәм табигый байлыклар министры Александр Шадриков әйтүенчә, Татарстанда барлыгы 36 мең су объекты исәпләнә. Республика Фәннәр академиясенең Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары институты үткәргән инвентарьләштерү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, соңгы 50 ел эчендә республика картасыннан 3133 күл юкка чыккан.

● Казанның меңьеллыгы билгеләп үтелгән 2005 елда башкалада 1 миллион 140 мең кеше яшәсә, хәзер халык саны 1 миллион 308 меңнән арткан.

● Казан бистәләрендәге юлларны яхшыртуга быел барлыгы 500 миллион сум акча тотыла. Андагы урамнарны яктырту буенча да зур эш алып барыла: 2014 елдан 2021 елга кадәр башкаланың 83 бистәсенә 8 меңнән артык яктырткыч куелган. Быел 33 торак массивта барлыгы 43 миллион сумлык 1500 фонарь кую планлаштырыла.

Казанда чат саен диярлек сальса, фламенко, аргентин тангосы биергә өйрәтәләр. Нишләп татар бию студияләре юк? Концертта һәм туй, юбилей мәҗлесләрендә генә башкарылса, якын киләчәктә татар биюе онытылмасмы? Кавказ халыкларының биюләре көндәлек дәрт, горурлык уята. Татар биюе исә нәрсәсе белән үзенчәлекле? Яшьләрне кызыктыру өчен биюләребезне заманчалаштырсак, аларның асылы югалмасмы?

БИЮЛӘР югалмасын иде

Г.Кариев театрында Россиянең алты төбәгеннән килгән хореографлар, бию түгәрәкләре җитәкчеләре катнашында атна дәвамында барган «ӘйдәБас» татар биюен үстерү остаханәсендә бу һәм башка сорауларга җавап эзләделәр. «Калеб» яңа буын яшьләре җыены беренче мондый очрашуны моннан бер еллап элек оештырган иде. Аннан соң бию өлкәсендә байтак вакыйгалар булды – җыр һәм бию дәүләт ансамбленең солисты Алсу Мәгъсумҗанова җитәкчелегендә «Дәрман» бию студиясе эшли башлады, ансамбльнең тагын бер солисты Сәйдә Миңнебаева «Таврида АРТ» Бөтенроссия фестивалендә «ӘйдәБас» проекты белән грант отты. Чираттагы бу очрашу шул проект кысаларында татар бию түгәрәкләре җитәкчеләре, хореографларның аң-тәҗрибәләрен үстерү максатыннан оештырылды. Бию куючылар өчен осталык дәресләре үткәрелде, милли костюм, фольклорны сәхнәләштерү мәсьәләләренә багышланган һ.б. темаларга галимнәребездән кызыклы лекцияләр тәкъдим ителде.

2021 елда Казан мэриясе парк һәм скверлар дирекциясе белән оештырган «Хәрәкәттә-бәрәкәт» проекты да бию сәнгатебезне халыкка таратуга ярдәм итте. Үткән ел Казаныбызда ундүрт чара узды. Шулар арасында иң зурлары «Зәлидә» уены, «Ярмәк вагы», «Чабата биюе», «Батыр-батл», балалар өчен «Шаян тиззаряд-ка»ны искә төшерү дә җитә.

Бию өлкәсендә уңай якка үзгәреш сизелсә дә, көнелне тырнап торган хәл ителәсе проблемалар да байтак әле. Шуларның берсе – төрле этник төркемнәрнең, әйтик, Себер татарлары, керәшеннәрнең һ.б. биюләре аерым өйрәнелмәве, аларны башкара белгән өлкән буынның исә бакыйлыкка күчә баруы. Казаныбызда озын, зифа буе, чибәрлеге белән генә түгел, башкарган эшләре белән дә соклану һәм ихтирам уяткан Әстерхан татары Дәүләт Үмәров бар һәм ул экспедицияләргә йөреп тупланган материалдан ике китап нәшер итте. Татарның һәрбер этник төркеменә һичьюгы бер хореограф булса, без инде әллә кайчан бай бию сәнгатебезне өйрәнеп тәртипкә салган булыр идек. Фольклорны җыю җиңел эш түгел. Бер ай дәвамында экспедициядә җыелган материалны бер ел эшкәртәләр.

Борынгы бию үрнәкләрен җыючы хореографларны каян алырга соң? Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында хореографларны әзерлиләр-әзерләвен, әмма бию кафедрасы мөдире Әлфия Кавееваның әйтүенә караганда, бүлектә төрле төбәкләрдән һәм чит илләрдән килүчеләр белем алганга күрә, татар биюен бик тирәнгә кермичә, өстән-өстән таныштыру өчен генә өйрәтәләр, моның өчен нигездә җыр һәм бию дәүләт ансамбленең «алтын фонды»на кергән бию җәүһәрләребезгә тукталалар. Экспедицияләргә бару кая ул! Аның өчен вакыт та, акча да юк. Кафедра мөдире бию турында фән булмавына, күп хәрәкәтләрнең асыл мәгънәсе, исемнәре югалуына игътибар юнәлтте. Шулай булгач, бию язып кайта алырдай яшь белгечләр әзерләү турында хыялланасы да түгел. Техника алга киткән заманда кесә телефоны белән дә биюне төшереп кайтып була, дип яшь буын мәсьәләгә карата үз фикерен белдерсә дә, хореограф Дәүләт Үмәров бу җәһәттән кискен ризасызлыгын әйтте. «Флешка, лазер тәлинкәнең куллану вакыты бик чикле, китап исә гасырлар буена саклана. Нишләп музыкантлар көйләрне диктофонга гына язырып кайтмый? Ник нотага салып газаплаалар», – дип ул бию осталарын уйга калдырды.

Уйлавыбызча, мәдәниятне саклау, шул исәптән бию җәүһәрләребезне өйрәнү, тәртипкә салу дәүләт югарылыгында алып барылырга тиеш. Дәүләтнең исә татар бию мәсьәләсенә карашы нинди? Россиядә материаль булмаган мәдәни мирасны саклау мәсьәләсе ни дәрәҗәдә куелган булса, республикабызда татар биюен өйрәнү дә шул чама, шуннан артык та, ким дә түгел. Татарстан Мәдәният министрлыгы каршындагы «Таткультресурсүзәк» белгече Рәмзия Гайфетдинованың чыгышыннан илдә матди булмаган мәдәни мирасны саклау шактый аксавы аңлашылды. Рәмзия ханым 2003 елда ЮНЕСКОда кабул ителгән Конвенция турында әйтеп китте. Аның исемлегенә Россиядән нибары якутларның Олонхо эпосы һәм Байкал арты искечә гыйбадәт кылучыларның мирасы гына кертелү җәһәтеннән уфтанды. Ары китеп, 2017 елда Татарстаныбызда гамәлгә кергән матди булмаган мәдәни мирас объектлары турында законны искә төшерде. Россиянең һәр төбәге милли байлыкларының үз реестрын булдырырга тиеш. Мониторинг үткәреп, республикабызның 45 районыннан 200ләп объект ачыкланганнар. Шулар арасында нибары биш бию бар. Былтыр исә «Таткультресурсүзәк» сайтында Татарстанның матди булмаган мәдәни мирас реестрын төзегәннәр. Аны теләге булган һәркем кереп карый ала. Әмма бию сөючеләр әллә ни шатланмасын, чөнки реестрда нибары мариларның сигезле биюен генә күрергә мөмкин. Кая балетмейстерларыбыз язып кайткан биюләр? 1960 елларда Гай Таһиров бер Минзәлә районыннан гына да 58 бию язып алган лабаса! Дәүләт Үмәров тапкан биюләр кая? Алар бар, әмма реестрга чират көтеп ята, ди. Эксперт советы аларны расларга тиеш икән. Совет елга ике тапкыр җыела. Сайтта актарына торгач, матди булмаган мәдәни мирас объектларының Россия реестрына да барып чыгарга мөмкин. Анда исә татар мәдәниятенә караган Карга боткасы бәйрәме генә теркәлгән...

Дәүләт дәрәҗәсендә эш шулай акрын баргач, бию өлкәсендә фәннең булмавына да, белем бирү көйләнмәвенә дә, фольклор фестивальләренең азлыгына да гаҗәпләнәсе түгел. Бию фольклор фестивальләре, гомумән, юк. Заманында филология фәннәре кандидаты Фәнзилә Җәүһәрова «Түгәрәк уен» фестивалендә бик авырлык белән фольклор бию номинациясен керткән иде. Бөтен авырлык – коллективларның җыр һәм бию дәүләт ансамбленең биюләрен генә кабатлап, үзләренең җирле биюләренә игътибар бирмәвендә. Әмма башланган эш барыбер нәтиҗәле булды. «ӘйдәБас» татар биюен үстерү остаханәсенә, мәсәлән, Пермь крае татар иҗтимагый оешмасы җитәкчесе урынбасары, «Гүзәл Чулман» фольклор коллективы җитәкчесе Гөлүзә Хәмзина килеп, моннан унбер ел элек «Түгәрәк уен» фестивалендә оешкан ансамбльнең берничә елдан соң гына үз йөзен табуы турында сөйләде. Өр-яңа сәхнә костюмнары, көянтәле биюләре белән Самарага икенче «Түгәрәк уен»га барып төшә алар. Анда исә, татарның төрле этник төркемнәре сәнгатен күреп башлары әйләнә. Без кем, сәнгатебез нинди, дип уйга калалар. Көянтәле биюегез Казанныкы, икенче юлы үзегезнекен өйрәнеп килегез, дип үгет-нәсыйхәт биреп кайтарып җибәрәләр аларны. Шуннан экспедицияләргә йөри башлыйлар, анда биниһая байлык туплана. Пермь краеның үзенчәлекле биюләренә, киемнәренә, гамәли-бизәү сәнгатенә үзләре үк шакката. Шуннан «Кәтинкә» биюенә тап булалар. Җыр һәм бию дәүләт ансамбленең баш балетмейстеры Раилә Гарипова Пермьдәге милләттәшләребезгә «Кәтинкә»не куеп кайта. «Фәнзилә Җәүһәрова – безне дөньяга китерсә, Раилә Гарипова икенче әниебез булды, – дип сүзен җөпләп куйды Гөлүзә ханым. – «Түгәрәк уен» хәзер дә үткәрелә, әмма элеккеге фестиваль түгел инде ул», – дип, бик кадерле нәрсәсен югалткандай, уфтанып куйды Пермь кунагы.

Дөрес, бездә «Әпипә» фестивале бар. Былтыр ул беренче тапкыр үтте. Илле катнашучыдан ундүрте финалга чыккан иде. Җюрине дәүләт җыр һәм бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе, күренекле биючебез Айрат Хәмитов җитәкләде. Быел аны тагын да колачлырак итеп телевизион форматта үткәрү каралган. Иң сөендергәне, былтыр фестиваль белән беррәттән Ләйсән Хәмитова җитәкчелегендә бию буенча осталык дәресләре төшерелде. Быел аларны бию коллективларына тарату ниятләнелә. Үткән ел нәкъ менә Г.Хәмзинаның «Гүзәл Чулман» ансамбленә беренчелекне бирүләре фестивальнең фольклорга йөз тотуын расласа да, телевизион форматка күчкәч, ул үзәк телевидениедәге бию, тимер аякта шуу, җыр шоуларына охшап калмасмы соң?

Дәүләт дәрәҗәсендә җитәрлек күләмдә игътибар, бию өлкәсендә фән, мәгариф, фестивальләр булмаганга күрә, бериш коллективларыбыз сәхнәгә чабата киеп чыга да инде. Ризасызлык белдерүчеләргә җавап итеп, җитәкчеләре, төкерекләр чәчә-чәчә, үткән гасырларда татарларның да чабата кигәнен дәлилләргә тырыша. Чабата аякка килешсә дә, биткә кимә, дигән борынгылар.

Яшь буын биючеләр, татар биюе музей әсбаплары сыман үзгәрешсез калып онытылмасын иде, дип теләк белдерә. 12 ел испаннарның фламенкосын өйрәнгән Гөлсинә Галимуллина, мәсәлән, испан биюенең ЮНЕСКО тарафыннан гомумкешелек матди булмаган мирас шедевры буларак танылуын аның яңалыкка ачык булуыннан күрә. «Бию – музей экспонаты түгел, тере тел», – дип дәлилләргә тырышты яшь биюче. «Сальса, бачата биергә адым саен өйрәтәләр, Казаныбызда татарча бию студияләре юк дәрәҗәсендә», – дип Гөлсинә проблемага ачыклык кертә төште. «Фламенко йортлары булмаса, һәр теләгән кеше килеп анда, җырламаса, биемәсә, фламенко да онытылган булыр иде, бәлки», – дип, ул биюләребезне популярлаштыру эшен нидән башларга кирәклеген искәртте. Үзе «Хәрәкәттә-бәрәкәт» проектында актив катнашып, татарча биергә теләүчеләр өчен уңайлы мохит булдыруга саллы өлеш кертте. Проект чараларының концерт залларында түгел, парк һәм скверларда үтүе, бер яктан караганда, отышлы, чөнки күп кеше сәхнәгә чыгудан ояла. Әмма шул ук вакытта татар биюенә җан өрәбез дип, артыгын кыланып җибәрү дә ярамый. Татар биюе милли бию булып калсын иде. Ягъни чабатаны салсак та, кроссовкига күчү шөкәтсезлектер. Һәр эштә бер чиктән икенче чиккә ташланмыйча, чама хисен югалтмау сорала.

Ахырдан «ӘйдәБас» проектының җитәкчесе Сәйдә Миңнебаеваның сүзләрен китерәсе килә: «Һәр кеше, милләтем өчен нәрсә эшли алам, дип уйлансын һәм ялгышлардан курыкмасын иде. Юкса татар җырларының, биюләренең безнең балаларга барып җитмичә онытылу ихтималы бар. Татар мәдәнияте зур, киң. Һәммәбезгә урын җитәчәк». Яшьләрнең сүзләрендә хаклык бар.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мөслимдә хәтерләр яралы

Татар төбәк тарихын өйрәнүчеләрнең «Урал ягы татарлары: тарих һәм заман» VII Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясендә катнашучылар Чиләбе өлкәсенең Коншак районындагы Мөслим Тимер юл бистәсендә дә булды.

Автобусыбыз белән кыр уртасындагы юлдан узып барабыз. Кинәт ялан җирдә ялгыз торган мәчет сискәндерде. Манарасы да, ае да бар... Ә юлның бер ягында кызыл кирпечтән салынган шактый озын дивар. Соңыннан белешүемчә, ул бертуган Злоказовларның Теча елгасы ярында төзегән зур су тегермәне булган. Бу элекке Мөслим авылы торган җирләр.

Чиләбе өлкәсендәге бу авыл XVIII гасыр башында нигезләнгән, тиз ишәйгән. XIX йөз ахырына Мөслим зур тегермәнле, өч мәчетле, мәдрәсәле авылга әверелгән. XX гасыр башында авылда 600 гә якын хуҗалыкта өч мең ярымнан артык кеше яшәгән. Тирәлек табигый байлыкларга мул була. Урманнарында кыргый җәнлекләр үрчегән, йорт хайваннары көтүлекләре өчен дә уңайлы болынлыклар җәйрәп яткан. Соңрак авылдан ике чакрым ераклыкта гына тимер юл да салынуы тормышны тагын да җайлаштырган. Элегрәк май заводы, «Ашлык кабул итү пункты» «Сельхозхимия», «Трактор» предприятиеләре Коншак районындагы барлык хуҗалыкларга хезмәт күрсәтә һәм продукция белән тәэмин итә. Әмма аларның

йортында милли моңнарыбыз яңгырап тору да күңелләребезгә хуш килде. Коридорларда милләтебез тарихы белән бәйле күргәзмә оештырылган, диварда халкыбызның мәдәнияте һәм йолаларына багышланган стенд та куелган. Анда милли ризык һәм бәйрәмнәребез турында рәсемле мәгълүмат белән бергә Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Габдулла Тукай кебек мәшһүрләребезнең фотосурәтләре дә бар. Конференция барышында мәктәптә укучы балалар, татар җырларын, биюләрен башкарып, сәнгатьтә дә осталыкларын күрсәтте. Әмма соңыннан үзара аралашканда, күбесенең үз туган телен белмәве аңлашылды.

Конференциядә ясалган чыгышларның шактые бу якларның моңсу тарихына багышланган иде. Татарстанның атказанган артисты Гөлшат Имамиева мөслимлеләр өчен матур җырлар яңгыратты, тарихчы галим Альберт Борһанов белем учагына китаплар бүләк итте. Гармуннар ясау остасы, төбәкне өйрәнүче Расих Сабиржановның да шәхси бүләге бар иде. Ул мәктәп директоры Зөлфия Вәлиевага баян тапшырды.

Бистәне уңайлау, ямьләндерү эше дәвам итә. Мөслим авылында

● **Мөслим авылында Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 30 ел тулу уңаеннан куелган затлы һәйкәлне дә 2018 елда Мөслим тимер юл станциясенә күчергәннәр.**

● **Бөек Ватан сугышында катнашучылар истәлегенә куелган һәйкәл.**

күбесе үзгәртеп кору елларында ябыла. Моннан тыш Мөслим авылы тарихы ирек өчен көрәшче Батырша белән дә бәйле. Ул дүрт елга якын Мөслим авылында старшина, мулла һәм мөгаллим булып эшләгән.

Әмма... 1948 елда Мөслим авылыннан кырык чакрым ераклыкта гына Сталин фәрманы белән, «Маяк» комбинаты, ягъни атом берләшмәсе сафка баса... Тагын да яманрагы – «Маяк» комбинатында даими рәвештә авария арты авария булып тора. Аның беренчесе 1949 елда радиактив калдыкларны саксыз саклау нәтиҗәсендә килеп чыга, сыек радиоактив калдыклары Теча елгасына агызыла. Су буенда дистәләгән авыл утыруына карамастан, бу турыда халыкка хәбәр ителми, кешеләр судан файдалана, балыкларын тота, яр буенда малларын йөртә, бала-чага елгада мәш килә. Авылларда яшәүчеләр исә ни сәбәпле начар авырулардан интегүләрен, дөньядан вакытсыз китүләрен белми. Шул ук вакытта «Маяк» радиоактив матдәләре Исет һәм Тубыл елгалары аша Төньяк Боз океанын пычратып тора. Бу хәлгә 1961 елда ук НАТО разведкасы игътибар итә.

1957 елда хәрби заводта тагын зур бер фаҗига – зур термик шартлау килеп чыгу сәбәпле, тирә-як мохит, бигрәк тә Теча елгасы радиоактив матдәләр белән тагын зарарлана. Барысын да эвакуацияләмиләр. Ә Теча елгасыннан 50 метр гына ераклыкта урнашкан, 2000 нән артык торак йорты булган Мөслим авылы шулай кала, күчерелми. Өченче каза 1967 елда килеп чыга. Ул радионуклидларның кырдан көчле җил белән килүенә бәйле. Ике авариядән соң Теча елгасында саклану корылмалары системасын төзергә ниятлиләр. "Маяк"ның сыек калдыкларын ясалма һәм табигый сулыкларга, шул исәптән Карачай күленә дә түгә башлыйлар, шушы рәвешле елганы куркыныч матдәләрдән сакламакчы булалар. Әмма 1967 елның җәе бик коры килә, күлдә су нык кими, яр буе ачыла. Кояш исә радиактив суүсемнәрне киптереп, тузанга әверелдерә. Ә Уралда, урманнар күп булуга карамастан, еш кына көчле җилләр исә. Шундый давылларның берсендә җил радиактивлы тузанны күтәреп кешеләр яши торган биләмәләргә тарата.

Википедия энциклопедиясендә хәбәр ителгәнчә, Мөслим авылында һәр дүрт баланың берсе – гарип-мутант, һәр биш баланың берсендә – йөрәк чире, 70 проценты – психик тайпылышлы, 1997 елдан соң туган һәр сабыйда нурланыш авыруы булу ачыклана. Алга таба хәлләр тагын да начарлана. 1999 елда туган 45 баланың 43 ендә – патология, 90 процент балаларда анемия булуы теркәлә. Сабыйларның иммунитетлары юк дәрәҗәсендә, организмнары бернинди авыру белән дә көрәшерлек түгел. Мөслим авылында атом калдыклары ташланган суны эчкән, һавасын сулаган халык тууучыларга караганда ике тапкыр күбрәк кырыла, авылның ун зиратына каберләр өстәлеп кенә тора. Шуңа да карамастан, бары тик биш дистә ел (!) узгач, күпме гомерләр газапланып өзелгәч, якыннарын югалтканнарның күз яшьләре күлләр булып түгелгәч, җаннар яраланып беткәч – 2009 елда гына авыл халкын куркынычсызрак урынга, Мөслим Тимер юл станциясе бистәсенә күчерү башлана. Яңа җирлек элекке Мөслим авылыннан ике чакрым гына ераклыкта. Урнашу эше бары тик 2013 елда гына тәмамлана. Хәзер бистәдә 2500 кеше гомер кичерә. Әмма әле элек сулаган һаваларның, эчкән суларның йогынтысыннан тулысынча арынып бетмәгәннәр. Авыру белән көрәшеп ятучылар санап бетергесез.

* * *

Автобусыбыз, Мөслим Тимер юл станциясе бистәсенә, ягъни Яңа Мөслим авылына килеп керде. Бирედә инде төзек, әмма бер-берсенә игезәкләрдәй охшаш йортлар (Татарстанда ипотека буенча шундый йортлар салына) игътибарны җәлеп итә. Тирә-якны күзәтеп бара торгач, автобусыбызның өч катлы бина янына туктавын сизми дә калдык. «Мөслим тимер юл станциясе урта гомуми белем бирү мәктәбе»н рәсми рәвештә дәрәҗәле кунаклар катнашында 2008 елның ноябрь аенда ачканнар. Уку йортында бүген 325 бала белем ала. Балалар бакчасы да мәктәпкә карый. Мәктәптә фәннәрне үзләштерү өчен барлык шартлар тудырылган, киң коридорлар, зур актлар залы, иркен сыйныф бүлмәләре, заманча җиһаз... Мәктәптә хәтта бассейн да бар.

Милли киемдәге кыз-малайлар кунакларны чәк-чәк һәм кош теле белән каршы алды. Уку

Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 30 ел тулу уңаеннан куелган затлы һәйкәлне дә 2018 елда Мөслим тимер юл станциясенә күчергәннәр. Моннан тыш бистәнең үзәк мәйданында Бөек Ватан сугышы каһарманнарына куелган тагын бер һәйкәл бар. Анда Бөек Ватан сугышында катнашучыларның фамилияләре язылган. Мөслим авылында 200 урынлы тамаша залы булган мәдәният йорты да төзелә башлаган.

Төбәкне өйрәнүчеләр бу көнне Коншак район тарихи-крайны өйрәнү музеенда да булды, ветераннар белән очрашты. 55 ел элек Бөек Ватан сугышы һәм педагогика хезмәте ветераны Зәйнетдин Гайнетдинов нигезләгән хәтер мәгарәсендә дүрт меңгә якын ядкәр тупланган. Анда татар һәм башкорт халыкларының көнкүреш, этнографик ядкәрләреннән тыш милли музыка кораллары, борынгы китаплар белән танышырга мөмкин. 2013 елның февралендә төшкән Чиләбе метеориты кисәге, бу якларда табылган төрле ташлар, борынгы сармат кылычы – кунакларда аеруча кызыксыну уятты.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

КАБАТЛАНАЧАК ТАРИХ!

(Өмет балладасы)

Үткәннәргә күзне йомып,
Яраклашып бүгенгә,
Яшәү җиңел, төтен чыга! –
Нәрсә яна җиңендә?

Төйнәлгән йодрыгыңны да
Күрсәтәлмәгәч чөеп,
Ни мәгънә бар яшәвеңдә,
Утларда янып-көеп?

Утсыз төтен чыкмый инде,
Карап кына торалар.
Хәтта төтен юнәлешен
Башка якка боралар. –
Күрмәсен, сизмәсеннәр дип,
Төтенен дә, утын да.
Белмәсеннәр үзләренең
Милләтенең чутын да...

Нәҗибә САФИНА

Аңлат, теге дүрт ягын да
Кыйбла итеп көн күргән,
Милләткә берни дә бирми,
Бары үзе үзгәргән,
Көфер хезмәтчесе булып,
Миллиардлар җыйганнарның
Тарих иләгеннән инде
Бүген коелганнарын!
– Шулай, шагыйрь,
Заман андыйларны
Тарих иләгенә салачак.
Туган җирен, Туган телен сатып
Баеганнар шәрә калачак!
Чөнки санга
Күлмәк киеп була,
Вөҗдан чүпрәкләргә төренми.
Бүген милләтемнең хәле авыр,
Тик көрәштән
Тукта-ма-я-чак ул терелми!

Югалтулар...
Алар ышанудан
Өстәгеләр әйткән сүзләргә.

Анда түгел, инде монда
Тынычлык юк җаннарга.
Бүген дә бил бөгә түрә,
Киләчәге янганда...
Дәшми генә акча саный,
Дәшми генә шомлана.
Уйсыз түгел ул түгелен,
Җаны сукыр, томана.
Әйди алмагач милләтен
Киләчәге юлына,
Бирәлмәгәч Туган телен
Кызына һәм улына,
Нинди юлбашчы булсыннар,
Ни-нәрсә булдыралар?
Казанны саткан чакта да
Гел шундый булган алар.
Инде биш гасырдан соң да
Иман иңмәгән икән,
Ул кешеләр нәфесләрен
Һаман җиңмәгән икән,
Тагы бер кабат Казанны
Әзер алар бирергә.

Туган телдә уйлыйм, сөйлим, җырлыйм, Туган телдә елыйм мин бүген...

Уйласыннар, без аз диеп,
Инде беткәнбез диеп.
Һаман да хезмәт итсеннәр,
Коллык богавын киеп.

Бер-берсен ишетмәсеннәр,
Берләшә күрмәсеннәр.
Бөтен төркинең бер телле
Икәнен белмәсеннәр.

Пантөркилекне яңадан
Күтәрсәләр, эш харап!
Әлегә алар торалар
Бары көфергә карап.

Ничәнче кат, ничә гасыр
Шулай буалар безне.
Нигә соң ни булыр диеп,
Йомып торабыз күзне?

Ник әйтмибез уйлаганны,
Юк диеп – булмаганны.
Әллә кем итеп сайлыйбыз
Акылга тулмаганны.

Туган телебезне саклау
Чарасын табалмыйбыз.
Үзебезгә тиеш булган
Өлешне алалмыйбыз.

«Юк»ны «бар»диеп халыкны
Ышандырмакчы кемнәр?
Буыннарны өзү өчен
Эшли һәр үткән көннәр.

Баланы бәби чагыннан
Алып сугаралар бит.
Шул мохиткә бала биргән
Безләр–диваналар бит.

Түрәләргә акча – иман.
Кычкырып көлә Иван.
Мәйданнарга алар юлны
Күптәннән бикләп куйган,

Күрмәсен дип, килер буын
Хәтере исәннәрне,
Сизмәсеннәр буын җебен
Хәйләләп кискәннәрне.

Тарихны киләчәк белән
Тик хәтер бәйләп тота.
Бары тарихи хәтерен
Саклаган милләт ота.

Үткәннәргә күзне йомып,
Тик бүгенгә ярашып,
Тормагыз, ни булыр диеп,
Бер-берегезгә карашып!

Милли балалар бакчасы,
Укыту туган телдә,
Туган телдә иҗат итү,
Үзеңчә яшәү көн дә
Кирәк! –
Ә шушы чынлыкны алар
Теләмиләр танырга.
Тырышалар ничә гасыр
Безгә барсын тагарга.

Такканнарын тарта-тарта
Чиләнеп бетте арка.
Тарткан саен салалар бит,
Йөге туктаусыз арта.

Үз йөгең авыр булмый ул,
Алар белеп сөйлиләр.
Ә без кабатласак шуны ,
Алар безне сөймиләр.

Үз йөгебез авыр түгел –
Туган тел, дәүләтебез!
Тарихи хәтер кабатлый:
Тарихта дәүләтле без!

Йөгебезне киләчәккә
Илтеп җиткерәчәкбез!
Туган тел, дәүләт, милләт дип,
Утка да керәчәкбез!
Милләтне тарихта кабат
Дәүләтле күрәчәкбез!

2010.

РЕСПУБЛИКА КӨНЕ

Бәйрәм белән матәм буталса,
Иделләрдә агым тукталыр.
Киләчәккә барыр юлыңны
Дәрья басар, җанны ут алыр.

Карадым да сурәтенә,
Мин сорау бирдем аңа:
– Әйт әле, нишләргә инде?
Милләтнең җаны яна...
– Үзең бел, – диде, үзең бел,
Син – шагыйрь шуның өчен,
Эшкә җиң бар гайрәтенә
Туган телебез көчен!

Инде тормас татар авыз ачып,
Төтен җибәргәндә күзләргә!–

Анда – сәхнә,
Монда сәхнә корган
Һәм ясалма бәйрәм ясыйлар.
Чын бәйрәм ул җанда гына була, –
Аңлый алмый шуны кайсылар...

Ятлаганны сөйләп,
Фәрман үтәп,
Тыпыр-тыпыр китә биеп тә.
Ышандырдык беркатлыны диеп,
Кемнәр көлеп тора «биектә»?

Чын бәйрәм ул
Җанны ачып керә.
Беләм, «шоу»ның бәйрәм түгелен.
Туган телдә уйлыйм, сөйлим, җырлыйм,
Туган телдә елыйм мин бүген...

Чын бәйрәмдә
Җаннар җырлап тора.
Чын бәйрәмдә–җанда тантана!
Бүген әле телен җуйган милләт
Гаҗизлектән генә таптана.

Бәйрәмме бу?
Әллә матәмме бу?–
Нәрсә әллә ялгыш әйтәмме:
Туган телне тартып өзгәндә,
Авызың тулы кара кан булып та,
Ятлар сизмәсен дип түзгәндә...

Әйтче, Тукай, әйтче, Исхакый!
Әйтче, Дәрдмәнд, Такташ,
Әйт, Туфан!
Әйтегезче, Зөлфәт, Мөдәррис! –
Бәйрәм итәр идегезме бүген,
Фани җиргә кабат килсәгез?
....
Дүрт ягын да кыйбла иткәннәрне
Герой иткәннәрен күрсәгез?

26.04.2017.

МӨДӘРРИСНЕҢ ТУГАН КӨНЕНДӘ

Аның тавышын тыңладым,
Тыңладым озын төнне.
Каберennән аваз салды:
– Бәгърем, сөйләмә инде...

Тагы әзер армиясе
Казан-илгә керергә.
Монда җирне тыңлап ятам,
Хәтер ул – Җир катында.
Кемнәр өскә чыгармаска,
Таптый татар атында?
Таптый Яңа Бистәне дә,
Кабанны, Иделне дә,
Каберләр күренмәсен дип,
Иделләрнең төбендә.
Тере түгел, үләләрне
Ышандыралмыйм, бәгырь:
Кол булырга ризамыни
Татар милләте хәзер?
Үзем дә ышанмаганга,
Калганнар да ышанмый.
Мин – кабердә, чыга алмыйм.
Терелләр ник кымшанмый?
Фәрман белән хәтерне дә
Сүндермәкче булалар?!
Шул гамәлгә дә сүз әйтми
Таттүрәләр торалар?
Лә иләһә иллалаһе
Мөхәммәд-рәсүл-улла!
Кабердәшләр торганчы дим,
Татар түрәсе, уйла!
Син дә мәңгелек түгелсең,
Ә яшәү дәвам итә.
Күпме бәхетсезләр бүген
Сезне каһәрләп китә!
Уйлап кына чыгарылган
Сүз түгел: ләгънәт, каһәр!
Сөякләрегез өстенә
Салыныр шәһәр-каһәр...
Мин дә китеп барган булдым,
Ә өмет калды анда!
Җан – мәңгелек, анда – өмет, –
Кояш чыгачак таңда!
Исәчәк тарих җилләре,
Иләячәк иләге!
Киләчәккә берегезнең дә
Калмаячак кирәге!
Милләтен дә сакламаган
Нәфесле сатлык җаннар,
Сез тәмугта янганда да,
Чиркәүләр кагар чаңнар!

13.10.2020.

«Үземне башкалардан

Татарстанның атказанган артисты Нәҗип Бәдретдинов татар тамашачысы өчен «Җырлыйк әле» телетапшыруы авторы, мөхәррире, музыкант буларак яхшы таныш. Нәҗип абый бүген баянчыларның роле, эстрадага карашы һәм шәхси тормышы турында да яшермичә сөйли.

– Нәҗип абый, сез ничек итеп сәнгать юлына кереп киттегез?

– Мин музыкаль гаиләдә үстем. Әти музыканы ярата иде. Яшь вакытында ул үзенә гармун сатып алырга хыялланган. Әшли башлагач, беренче хезмәт хакына авылдашыннан гармун сатып алган. Шуңа мин кечкенә чагымда ук бездә Вена гармуны һәм баян бар иде. Әти мине күбесенчә баянда уйнарга мәҗбүр итте. Шулай, яшьтән үк әти белән бергәләп, ул – гармунда, мин баянда уйнадык. Аннары мине мәктәптә аккомпаниатор итеп файдалана башладылар. Саба урта мәктәбендәге бөтен музыкаль чараларда баянчы булдым, ә яшьтәшләремә аккомпаниатор буларак ярдәм итә идем. Ул вакытта музыка мәктәбе юк иде бит, шуңа баянчылар да әллә ни күп булмады. Мин бишенче сыйныфка баргач кына музыка мәктәбен ачтылар.

– Музыка мәктәбенә йөрдегезме?

– Юк, мин анда йөри алмадым. Миннән 5 яшькә кече энем бу уку йортын тәмамлап, баянчы булып китте. Ә мин 1967 елда 8 классны тәмамлауга, Казан музыка училищесына барып кердем. Хикмәте шул: музыкаль белеме булмаган кешене училищега алмыйлар иде, ә мине алдылар. Радиодан ишеткән көйләрне яттан уйнап күрсәттем. Әмма ноталарны, музыка теориясен белмәгәч, алга таба укый алмадым, мине училищедан чыгардылар.

Сабага кайтып, мәдәният йортында баянчы булып эшли башладым. Җыеп кына әйткәндә, мин үземнең табигый талантым аркасында гына сәнгатькә килеп эләктем. Уку йортлары аша түгел.

– Аннары?

– Аннары армиягә хезмәт итәргә киттем. Кайткач, мәктәптә ун классны тәмамлап, Казан педагогия институтының музыка факультетына кердем. Бер үк вакытта мәдәният йортларында эшләдем. Укуны тәмамлагач, очраклы рәвештә, Татар дәүләт филармониясенә лекторий бүлегенә килеп эләктем. Бер баянчы армиягә алдылар, аның урынына мин калдым. Ике көн эчендә репетиция ясап, Нәҗия Теркулова, Рәшит Гобәйдуллиннар белән Чаллыга 24 концерт куярга чыгып киттек. Кайткач, артистлар филармония җитәкчелегенә кереп: «Бу егетне безгә алырга кирәк», – дигән. 21 елга мин филармониядә калдым. 1979 елдан 2000 елга кадәр шунда эшләдем.

– Коллективта ничек кабул иттеләр? Конкурентлык булмадымы?

– Мин килгәндә татар баянчылары күп иде анда: Рамил Курамшин, Ирек Галимов, Фәнис Гыйльметдинов, Фаил Исхаков, Илфират Гыйззәтуллин һ.б. Менә бүгенге шоу-бизнеста җырчылар арасында көндәшлек, үзара ярышу, хәтта терсәк уены бар. Ә баянчы-музыкантлар һәрвакыт ярдәмчел, бер-берсен хөрмәт итеп яши. Моның сәбәбе дә аңлашыла, чөнки сәхнәгә чыгып баянда уйнау өчен күпме хезмәт куярга кирәк!

«Филармония» дигәч, һәрчак Илһам Шакиров, Әлфия Авзаловаларны искә төшерәләр. Ә әдәби-музыкаль лекторий музыка сәнгатен пропагандалый торган бүлек иде, анда минем белән бергә бик зур шәхесләр эшләде: нәфис сүз остасы Айрат Арсланов, җырчылардан Венера Шәрипова, Әлфия Заһидуллина, Эмиль Җәләлетдинов, Гали Ильясов, Нәҗия Теркулова һ.б.

– Татар халкында баянчылар мәктәбе көчлеме?

– Үземне «баянчы» дип батырып әйтәсем килми. Чөнки мин баянда уйнап, солист-инструменталист буларак чыгыш ясаганым юк. Андый теләгем дә булмады. Мин җырчылар белән эшләдем, аларга аккомпанемент уйнадым. Ул – катлаулы. Син җырчының сулышын тоярга тиешсең.

Ә баянчылар мәктәбенә килгәндә, бездә бик оста баянчылар бар иде: Ильяс Шәрипов, Марс Макаровлар безнең буынга үрнәк булып торды. Аннан соң Рамил Курамшин баян өчен әсәрләр, концертинолар язды, шуларны үзе башкарды.

Башкортстан белән чагыштырсак, анда баянчылар мәктәбе күпкә көчлерәк. Безнең заманнарда баянчыларга игътибар җитенкерәмәгән. Ул заманда ук Башкортстан баянчылары Ридик Фәсхетдинов һ.б. иң дәрәҗәле кешеләр исемлегендә иде. Бездә, кызганыч, алай булмады. Баянчылар ничек арткы планда басып торган булса, шулай басып калды. Мәсәлән, Ирек Галимовның күтәреп чыгучы булмады, хезмәтен бәяләмәделәр. Ярый әле Рөстәм Вәлиев, Ринат Вәлиевлар зур исемнәргә лаек булды.

– Сезнең мактаулы исемегез бар бугай бит.

– Кызык өлкә бу. Бер көн дә артист булып эшләмәгән кешегә ничек итеп «атказанган», яисә «халык артисты» исемен бирәләрдер, һич тә аңлашылмый. Шул ук вакытта театрда иртәдән кичкә кадәр репетицияләрдә тир түгеп, унар ел эшләгән кешеләр «атказанган» исемен ала алмый.

Минемчә, республика җитәкчелегенең әлеге мәсьәләдә башбаштаклыгы бу. Шунысы кызганыч, күп кеше үзен җыр-музыка өлкәсендә белгеч итеп саный һәм, дәрәҗәле исемнәр биргәндә дә, бу өлкәдә компетентлы булмаган җитәкчеләрнең сүзе зур роль уйный. Бу исемнәрне профессионаллар расларга тиеш. Мәсәлән, театр артистына исем бирәсең икән – дәрәҗәле артистлар фикеренә таянырга, музыка өлкәсендә музыкант һәм композиторлар фикерен тыңларга кирәк. Шулай булганда гына без үзебезнең халык артистлары белән горурлана алырбыз. Ә бүген аларның күбесе өчен оят.

– Хәзер ситуация ничек, сезнең кебек талантлы баянчылар чыгамы яки аларга кытлыкмы?

– Хәзерге баянчыларның функциясе бөтенләй башка. Безнең заманда баян тулы оркестрны алмаштыра иде. Хәзер баянчы әзер фонограмма җаена уйнап, концертны бизәп торучы гына. Тулаем бер җырны баянчыларга кушылып башкару – сирәк күренеш. Кайбер очракларда башка кеше язмасы күләгәсендә басып торучы баянчыларны күрергә туры килә. Бу инде – бик зур түбәнчелек. Аяныч, елдан-ел музыка училищесында да, консерваториядә дә музыка белән кызыксыну кими. Мин баянда уйнап кына да тормышымны алып бара алдым. Хәзерге баянчыларга күпкә авыррактыр.

– Сәнгать өлкәсендә тагын нинди күренешкә күңелегез әрни?

– Бездә татарча сөйләшә торган профессиональ композиторлар юк. Үземнең тәҗрибәдән чыгып әйтәм: чын татарча музыка иҗат итү өчен, фәкать татар мохитендә яшәү кирәк. Шәһәр җирендә яшәгән егетләр-кызлар, туган телне белмәгән кебек үк, татар рухына туры килә торган итеп көй яза алмый.

Консерваториядә композиция бүлегенә музыка мәктәбен һәм музыка училищесын тәмамлаган кешеләрне генә алалар. Димәк, безнең авыл җирлегендә, авыл мохитендә яшәгән талантларыбыз «консерватория», «музыка училищесы» дигән уку йортына керүдән мәхрүм кала, чөнки башлангыч музыкаль белемнәре юк. Мәсәлән, 80 нче елларда Илгиз Закиров, Ринат Гобәйдуллин, Илһам Хисмәтуллин, Фирзәр Мортазиннар җыр яза башлады. Әгәр алар композиция бүлегендә укып чыкса, күләмле музыкаль әсәрләр туар иде. Бәлкем, алар иҗат иткән балет, опера, симфонияләр бүгенгеләреннән миллилеге, чын татарча булуы белән аерылып торыр иде... Менә бу – безнең халыкның, милләтнең музыка сәнгате ягыннан бик зур югалтуы.

Гомумән, җитәкчелекнең музыка сәнгатенә «бармак аркылы» гына каравы сизелә. Безнең Президент симфоник концертларга йөрсә, аңа ияреп, башка чиновниклар да барыр иде. Концертлар тулы аншлаг белән узар иде. Ә бездә андый хәл юк. Алар, әнә, ат чабышына бара. Бүгенге көндә профессиональ татар музыкаль сәнгате юк, дип әйтмичә дә булмый.

– Фонограммага авыз ачып торучыларны телгә алыргамы?..

– Концертка килгән тамашачы музыкаль авазның тууына шаһит булырга тиеш. Җырчы чыккач, ансамбльдәге музыкантлар бер-берсен тоемлап уйный башлый. Хәзер исә фонограмма җибәрәләр дә, шуңа җырчы (яхшы очракта) үзе җырлый.

Акча түләп билет алып килгән кеше чын сәнгатьне күрергә тиеш. Ә ул фәкать тере башкаруда гына була ала: музыкантлар, җырчылар бергә ансамбль булдыра алганда гына уңышка ирешү мөмкин. Ә ул бик күп хезмәт сорый. Тере музыка булмаганда, исемен «концерт» дип атау дөрес түгел. Ул ниндидер «шоу»дыр инде. Аның бәясе дә икенче булырга тиеш.

Мәсәлән, Филүс Каһировны алыйк. Ул «Мирас» ансамбле егетләре белән 2 сәгать буе тирләп-пешеп чыгыш ясый. Ә шул ук вакытта кемдер чыгып, фонограммасын куя, шуңа биеп йөри. Ничек итеп икесенә дә бер үк төрле бәя булырга мөмкин? Шунысы аяныч: теге концертка да, бу концертка да шул ук бәя. Ә халык аны аңламый. Аңа чикләүләр куярга кирәк. Фонограммага эшли икән, аның бәясе 50 сум, күп дигәндә 100 сум булырга тиеш. Кино караган шикелле. Үзе җырлап, тере уен коралларына чыгыш ясаучы икенче төрле бәяләнсен иде.

– Татар әсәре булгач, аңа йөрүче аз булыр, дип юатучылар да бар бит...

– Әлбәттә, тамашачы аз була. Татарча сөйләшүләр азайгач, татар музыкасы кемгә кызыклы инде? Татар музыкасына караганда, дөньякүләм камилрәк музыка бар. Вердиның опералары югары дәрәҗәдәдер. Ләкин татар балеты, татар операсына йөртер өчен, халыкта башта милли горурлык тәрбияләргә кирәк. Менә шул юк. Милли горурлыгы булган кеше татарча да сөйләшә, татар әдәбиятын да укый. Үз милләтен һәрвакыт хөрмәт итә, талантлы шәхесләре белән горурлана, аларны үстерә.

Менә сиңа бер мисал: бервакыт Анатолий Шутиков җитәкчелегендәге халык музыка уен кораллары оркестрына бер язучы шелтә язган. «Шутиков оркестры татарча уйнамый, русча гына уйный», – дигән. Бу – 2000 еллар башында булган хәл. Шуннан соң Шутиков концерт ясады: Илһам Шакиров, Зилә Сөнгатуллина, Рөстәм Маликов һ.б. татарның иң «элитный» җырчылары җырлады. Мин дә бардым бу концертка. 20 билет сатылган иде. Шушы шелтәне язган язучы да килмәгән, Язучылар берлегендә булган 300 язучының берсе дә килмәгән.

– Буш зал идемени?

– Халык белән тутырдылар: пенсионерлар килгән иде. 20 кешенең 12се – чит илдән килгән

өстен куйганым юк»

аспирант булып чыкты. Концерт беткәч, алар сәхнәгә менеп, уен коралларын тотып карады, кызыксындылар. Менә шундый хәл. Татар музыкасы татарның үзенә кирәкмәгәч, кемгә кадерле булсын соң? Шул ук татар теле кебек. Без татарча сөйләшмәсәк, ул кемгә кирәк, кем ул телдә сөйләшсен?

– Тыңлап туеп булмый торган җырлар бармы ул?

– Мине иң борчый торган әйбер – көйне бозып җырлау. Бу бит – бөтенләй башка сыймаслык әйбер. Әле аны «профессор»лар бозып җырласа, аларга ияреп, халык та шулай җырлый башлый. Шелтә ясасаң, «теге шулай җырлый бит» дип җавап бирәләр.

Элекке җырларны җырлыйм дисәң, оригиналын яхшылап өйрәнергә кирәк. Нотасын табып, кемнәр язганын белеп, нәрсә турында икәнене төшенеп, нинди стильдә җырланганын аңлап, югары дәрәҗәдә башкару мөмкин. Илһам Шакировның җырларын Филүс Каһиров җырлый. Аның ул бик матур килеп чыга, хуплыйм гына. Ә булдыра алмаган кешеләрнең җырлавы күңелне тырный.

Хәзер бит җырны теләсә кем яза. «Шыңшып» күрсәтә дә, аңа музыкант аранжировка ясый да, шуны «җыр» дип тәкъдим итәләр. Менә шундыйлардан котылу чарасын табарга кирәк. Массакүләм чаралар аларны бирмәсен иде, дигән теләк бар. Ләкин алар шул юл белән акча эшли. Димәк, Татарстан хөкүмәте өчен милли җырларыбыз белән халыкны тәрбияләүгә караганда әрсез җырчыларның ротация өчен түләгән тиеннәре кыйммәтрәк булып чыга.

Тагын бер ямьсез күренеш – җырны сатып алу. Җыр чыккан, халыкка кергән икән, син аны берни эшләтә алмыйсың, ул – халыкныкы. Аны чыгарган авторларга һәм беренче башкаручыларга рәхмәт әйтеп, аны алга таба яшәтергә кирәк. Җырны сатып алу – булдыксыз кешенең эше, дип уйлыйм. Мәсәлән, «Миләшләрем» җыры тирәсендә чыккан ыгы-зыгы. Мин җырның авторы Зөфәр урынында булсам, Ләйнага бу җырны җырлауны тыяр идем. Чөнки ул аны беренче башкарган Алсу Хисамиевадан нык түбән дәрәҗәдә җырлый.

Акча эшләү юлы белән, җырларны сатып алып, аларны башкаларга җырларга тыю – дөрес түгел. Руслар, башка милләтләр белән чагыштырганда татар халкы күпсанлы түгел, үзебезнең җырларны тыйган булып, низаг оештырып, талашып яту безне бер дә бизәми.

– Татар халык авыз иҗаты инде өйрәнелеп беткән, дип әйтә алабызмы?

– Ул өйрәнелеп бетмәгән һәм бетмәячәк тә. Чөнки аның яңалары чыгып тора. Өйрәнелеп, ноталары белән китапларга язылганнары да калын-калын язма китапларда ята. Мәхмүт Нигъмәтҗановларның китаплары бар. «Җырчы» дигән бәндәләр нота да белмәгәч, ничек өйрәнелеп бетсен инде ул?

Радио фондында Илһам Шакировның симфоник оркестрга кушылып башкарган «Бер алманы бишкә бүләек», «Бик еракта идек без», «Сәфәр» кебек җырлары бар. Әнә нинди шедеврлар бит! Милли музыка үрнәкләрен сорасалар, мин нәкъ шушы әсәрләрне күрсәтер идем. Илһам абыйдан соң күпме халык җырлары чыкты, шуларны симфоник оркестр белән бергә дөнья күләмендә күрсәтерлек дәрәҗәдә итеп эшкәрткән кеше юк. Югыйсә, дөнья күләмендә танылган җырчыларыбыз Альбина Шаһиморатова, Аида Гарифуллина, Рузил Гатиннарыбыз бар. Халык җырлары симфоник оркестр белән алар дәрәҗәсендә башкарылса, бу гамәл татарны дөньякүләм танытуга зур этәргеч булыр иде.

– «Җырлыйк әле» тапшыруын алып барганчыга кадәр, сез филармониядә эшләгәнсез. Шундагы вакыйгаларны тыңлап үтәсе килә.

– Истәлекләр күп… Апрель аенда – совет халкы өчен бөек Ленинның туган көне, һәм шуңа да безнең бүлек әзерләгән барлык программалар да Ильич исеме белән бәйле булырга тиеш иде.

Язның шушы матур көннәрендә без Гали Ильясов белән «Любимые песни Ильича» дигән әдәби-музыкаль темада бер төркемгә туры килдек. Гали, башка җырчылардан аермалы буларак, темага карап тормый, Ильич яраткан «Есть на Волге утёс», «Дубинушка»лардан соң, үзе иҗат иткән «Оныттың бугай»ны да «сылый». Бөек юлбашчының яраткан җырларыннан оеп утырган тамашачы гөрләтеп кул чаба, Галигә рәхмәтләр әйтеп, башка җырларын да җырлавын үтенә. Шулай итеп «Любимые песни Ильича» әдәби-музыкаль композициясе, әкренләп, Гали Ильясовның иҗат кичәсенә әйләнә.

Әлбәттә, бу хәлне кичәне рус телендә алып барган нәфис сүз осталары җитәкчелеккә җиткерә. Җыелышларның берсендә Гали әфәндегә шундый сорау бирәләр: «Ни өчен сез Ленинга багышланган җитди кичәнең әчтәлеген юкка чыгарып, үзегез иҗат иткән «...бугай»ны башкарасыз?»

Гали: «Әгәр Ильич исән булса, ул бу җырны, һичшиксез, яратыр иде!» – диде.

Икенче истәлек: 1980 елларда без – филармония артистлары – нефть төбәкләренә, хәтта Чаллыга да һава транспорты белән бара идек. Ул елларда әле аэропорт шәһәрдә, самолетлар сәгать саен. Кунакханәгә барып урнашу өчен 2-3 сәгать вакыт җитә. Дөрес, һава шартлары начар булу сәбәпле, өчәр тәүлек кайта алмый яткан чакларыбыз да булгалады.

Безнең арада замананың бу уңайлыкларыннан файдаланмый торган бер кеше бар. Ул – баянчы Фәнис Гыйльметдинов. Әлмәткә барасы булса, Фәнис бер атна алдан әзерләнә башлый. Башта филармониягә барып самолет билетын ала, аны авиакассага илтеп тапшыра, аннары тимер юл вокзалына барып поездга билет ала һәм башкалардан ике көн алда сәфәргә кузгала. Шулай итеп, минем коллегам, филармониядә эшләү дәверендә, үзенең газиз гомерен куркыныч астына куймый, Җир-анадан нык аерылмый гына гастрольләргә йөрде. Чөнки самолетка утырырга курка.

Шулай беркөнне Әлмәткә очарга дип аэропортка җыелдык. Ни сәбәпледер, бу юлы, баянын асып, Фәнис тә безнең арада йөри. Әлеге гадәти булмаган очракның сәбәбен аңларга теләп, Айрат абый Арсланов аңа сорау бирә:

– Фәнис, ничек әле син, үзеңнең газиз гомереңне зур куркыныч астына куеп, безнең белән самолетка утырырга булдың?

– Мин бу очышка озак әзерләндем, Айрат абый, ә тәвәккәллегемнең сере бик гади: сездәй бөек шәхесләр белән бергә үлеп, тарихка кереп каласым килә. Мондый мөмкинлек тагын кайчан туры килә әле, – дип җаваплады.

– Хәзер «Җырлыйк әле» тапшыруына күчик. Сез – аның авторы. Бу тапшыруны булдыру кемнең идеясе иде?

– Минем идея, әлбәттә. «Җырлыйк әле» тапшыруы 2000 елда башланды. Мәскәү каналларында «Угадай мелодию», «Два рояля» кебек музыкаль тапшырулар бара иде бит. Уйладым да, татар музыкасына нигезләнгән уен уйлап чыгарып булмасмы, дидем. Фикеремне җитәкчелеккә тәкъдим иттем. Ул вакытта Илшат Әминовның урынбасары Айрат Сибагатуллин иде, алар хуплап алды. Тапшыруны алып барырга Айдар Фәйзрахмановны чакырдым.

«Җырлыйк әле» баштан ребуслар форматында барды. Хәрефләр ачылып, шул хәрефкә җыр җырларга кирәк иде. Аннан соң үзгәрешләр керттек, чөнки «а» хәрефе ачылса, бөтенесе «Алмагачлары»н җырлый башлый. Яңа формалар эзләдек.

Тапшыруны 12 ел Айдар алып барды. Тапшыру популяр булгач, күрәсең, тапшыруны алып барырга теләүчеләр артып киткәндер. Айдар янына Зәмирәне китереп бастырдылар. Аның бернәрсәгә кирәге юк иде, ул җыр өлкәсендә беркем түгел.

Мин һәр эштә профессиональлекне яратам. Профессионал булмаса, кеше белән сөйләшәсе дә юк. Аннан соң, очраклы кешеләр «алып бара» башлады. Ул минем фикер белән түгел иде. Шушы мәсьәләдә үземнең сүземне әйткәч, конфликт та булды... Алып баручыларны җитәкчеләр куйды, алардан нинди файда булгандыр? Анысын белмим.

«Җырлыйк әле» – җыр турындагы тапшыру, шулай булгач, анда җырчылар булырга тиеш. Һәр тапшыруның максаты була. Безнең тапшыруның максаты – онытылган җырларны яңадан халыкның исенә төшерү. Менә, мәсәлән, мин хәзер программа төзим. Кунаклар бөтен җырны да белеп бетерми. Алып баручылар аларга булыша, бергә җырлыйлар. Тамашачыларга кеше аңларлык дәрәҗәдә тәкъдим итәләр.

Кызганыч, тапшыруны аена ике тапкырга гына калдырдылар.

Зилә МӨБАРӘКШИНА.

intertat.tatar

Декадага – 65 ел

Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтында, Мәскәүдә узган татар әдәбияты һәм сәнгате декадасының 65 еллыгына багышлап, «Совет мәдәниятендә иҗтимагый күренешләр һәм миллилек» дип аталган фәнни конференция узды. Тарихчылар фикеренчә, 1957 елның 24 маеннан 4 июненә кадәр Мәскәүдә узган татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы Советлар Союзы чорында татар мәдәнияте өчен иң әһәмиятле чараларның берсе булган.

Тарих институты директоры Радик Салихов сүзләренчә, декаданы өйрәнү Советлар Союзы периодының мәдәниятен аңларга ярдәм итә. «Без шуны аңлыйбыз: татар мәдәнияте чикләнгән автономия һәм тоталь идеологик контроль шартларында да чәчәк аткан, яңарыш кичергән. Бу декаданың Бөек Ватан сугышыннан соң узуын да истә тотарга кирәк. Милләтнең күп талантлары һәлак булган», – дип аңлатты ул.

Аның фикеренчә, Мәскәүдә үткән бу декада союздаш республикаларның аналогик чараларыннан әйбәтрәк узган дип тә әйтергә мөмкин: «Бу декада татар җәмгыятенең бик мөһим процессларына этәргеч булды. Алтмышынчы елларда килгән көчле буын турында горурланып сөйли алабыз. Нәкъ менә шул чорда татар интеллигенциясе автономияле республика статусын союз статусына кадәр күтәрү мәсьәләсен алга чыгарды».

Тарих фәннәре докторы Әлфия Галләмова сүзләренчә, бу декада Советлар Союзы чорында Татарстанның мәдәни тормышындагы иң зур вакыйгаларның берсе була: «Бу чарада Камал театры Ленин ордены белән бүләкләнә, артистларыбызга СССРның халык артисты исемнәре бирелә. Советлар периодында мәдәният формалашуда татар мәдәнияты лаеклы урында тора».

Тарих фәннәре докторы Индус Таһиров әйтүенчә, Татарстан үзенең яшәеше белән элеккеге Советлар союзы, Россия өчен үрнәк булып торды. «Монда миллилек һәм социаль көчләр һәрвакыт бергә яшәп килде һәм шулай булачак. Мәскәүдә шундый зур чара уздырып, татар үзенең кем булуын Россия күләмендә яңгыратуы – зур эш», – диде ул.

Гөлүзә ИБРАҺИМОВА

Ак калфак

(Дәвамы. Башы 43 нче санда).

Бу сүзләрдән тәмам эрегән Гайшәбикә әби кет-кет көлеп куйды:

– Үзебезнең авыл кызлары да: «Гайшәбикә әби, синең буй-сының бигрәк төз, яшь кызлар кебек әле син», – дигән булалар. Соң, төз булмыйча, гомер буе көянтә белән чишмәдән су ташыдым ләбаса мин, дим аларга.

– Әби, көянтә белән су ташысаң, буең зифа буламы?

– Борынгылар шулай диләр иде.

– Алайсам, хәзер мин дә көянтә белән су алып кайтам!

– Һай, балам, мин аны болай гына әйткән идем дә, өемә су кергән, краннан агып тора, мәшәкатьләнмә, кызым…

Шулай да Айсылу, Гайшәбикә әбинең күптән эшсез яткан көянтә-чиләкләрен асып, чишмәгә төшеп китте. Ян тәрәзә буенда уйга талган карчыкны Рушанның болдыр баскычыннан менгән аяк тавышлары сискәндереп җибәрде.

– Яшь килен чишмәгә төшеп киттемени? – дип ерды ул авызын керә-керешкә.

– Бәхете булсын бу баланың, бик яраттым Айсылуыңны. Шулай да үзе юкта сөйләшик әле, улым. Өйләнергә карарың ныкмы? Кыз баланың башын-күзен әйләндереп кенә йөрүең түгелме? Кара аны, бу баланы елатып, шәләй-вәләй йөрсәң, мәңге риза буласым юк! Аннан соң, никахны кайчан укытырга уйлыйсыз? Айсылу авылда яшәргә ризамы? Киңәштегез, сөйләштегезме?

– У-у, прокурордан ким түгел син, әби! – дип көлде Рушан. – Син бигрәк инде, кызлардан көлеп йөри торган егеткә охшаганмынмы мин? Үзең тәрбияләп үстергән оныгыңнан да шикләнеп торырга инде! Уем җитди, тиздән диплом алам, колхоз рәисе Самат абый кайчан кайтасың, дүрт күз белән көтеп торабыз энем, ди. Айсылу да авылда яшәргә риза, укытучы кешегә кайда да эш табылыр. Син менә үзең безне сыендырырга ризамы соң, әби? Картлык көнемнең тынычлыгын алдылар дип, ачуланмассыңмы? Каршы килмәсәң, никахны да монда – авылда укытыр идек.

– Улым, ниткән ачулану ди ул? Син шәһәргә укырга киткәннән бирле ялгыз башым тилмерәм ләбаса. Ялгызым утырып чәй дә эчәсе килми. Бик риза улым, бик риза. Никахын да укытырбыз, боерган булса… Шулай да, улым, иң әүвәл әниеңне ризалатырга кирәк. Миңа бүген шылтыраткан иде… Нинди генә булса да, нәрсә генә әйтсә дә, әниең ул синең. Ана хакын хакларга кирәк, балам. Янына бар, сөйләшеп кара, аңламый калмас.

Рушан авыр сулады:

– Ярый, тырышып карармын… Фатирга барып булмас. Әни минем яшьләрдәге бер ирне йортка керткән, безне куып чыгаруы да шуның аркасында. Базарга, әнинең сату иткән җиренә барырмын. Авылда яшәргә калабыз дисәм, бәлки, бик дуламас.

Ул арада май кояшыдай балкып, чишмәдән Айсылу кайтып керде. Аш өлгерде, күңелле генә итеп ашап-эчеп алдылар. Табыннан кузгалуга Рушан диплом эшенә тотынды, Гайшәбикә әбинең намаз вакыты керде. Өстәл җыеп, савыт-саба белән әвәрә килгән Айсылу түр якта намазлыгы өстендә оеган Гайшәбикә әбигә кызыгып-кызыгып күз салгалады. Тәсбихен читкә куеп, намазлыгын җыя башлаган карчык янына аяк очларына гына басып килде ул:

– Әби, намаз уку авырмы ул?

– Авыр түгел, балам, «Әлхәм»не, «Кульһүәллаһү»не өйрәнсәң, бернәрсәсе дә юк.

– Әлхәмдү лилләһи раббил галәмин. Әр-рахмәнир-рахим. Мәлики йәүмиддин… Шушы догамы, әби?

– Сөбханалла, кызым, өйрәнгәнсең бит!

– Мин аны кайда, кайчан өйрәнгәнемне белмим, әби. Ахрысы, мәрхүмә әбием өйрәтеп калдыргандыр.

– Шулай ул, балам, сабый чакта өйрәнгән бер дә хәтердән чыкмый. Менә, иртәгедән намазны икәү бергә укырбыз, боерган булса.

– Минем намазлыгым да юк шул әле.

– Анысы өчен кайгырма, кызым, сандыгымда кайчандыр үзем чиккән бик матур намазлыгым бар. Сиңа насыйп булган икән, Аллага шөкер.

Гайшәбикә әби эчке бер сөенеч белән сандыгы өстеннән кабартып куйган мендәрләрен алды. Үзе белән бергә картайган, шулай да бизәкләренең төсен, ямен җуймаган сандыгының капкачын сак кына күтәрә төште. Серле шыгырдап, гүя тылсымлы дөнья ачылды: Гайшәбикә әбинең сөякчел куллары сандыктагы һәр әйберне сыйпап-кагылып узды. Моңа кадәр бары музейларда гына очраткан чүпләмле сөлгеләр, чигелгән ашъяулыклар, тәрәзә өленгеләрен күреп, Айсылу ах итте:

– Әби, син боларны үзең чиктеңме?!

Гайшәбикә әби моңсу елмайды:

– Кем булсын инде, балам, үзем чиктем. Элек хәзерге шикелле кибет тулы маллар юк иде. Үзебез чигеп, тегеп, бәйләп, булмаганны булдырып яшәдек инде. Сиңа дигән намазлыгым да биредә икән. Мин үлгәч тә, төсем итеп, намаз укып тотарсың…

– Рәхмәт, әби…

Икесенең дә күңеле тулды. Авыр тынлыкны Рушанның көр тавышы бозды:

– Әби, Айсылуга минем кечкенә күлмәгемне күрсәттеңме әле?

Гайшәбикә әбинең дымлы күзләре көлеп җибәрде:

– Ә, хәзер, улым! Менә, Рушан улымның шушы күлмәккә сыйган вакытлары да бар иде.

Гайшәбикә әби сандыгыннан кул яссуы кадәр генә бумази күлмәк алды. Айсылу бер күлмәккә, бер Рушанга карады:

– Истәлек өчен сакладыңмы, әби?

– Аның өчен генә түгел, кызым. Атасының күлмәген кигән бала атасына бик якын була диләр бит.

– Рушанымның баласына дип саклыйм бу күлмәкне.

– Күрсәткәч, күрсәткәч, минем кендекне дә күрсәт инде, әби, – дип көлде Рушан.

– Кендекне?!

– Менә бу төргәктә Рушан улымның кендек җебе. Бала тугач, өч-дүрт көннән өзелеп төшә ул, үзең әни булгач белерсең, кызым. Әле ярый, Рушан район бүлнисендә туды. Шәһәр роддомында кендек җебе дип маташмыйлар анда! Сандык төбендә ятса да, кешене гомер буена туган җиренә, туган нигезе белән бәйләп тора ич ул! – Гайшәбикә әби, тыңлаучылар булганда сөйләп калыйм дигәндәй, дәвам итте: – И, элек… Дөньяга сабый бала туу белән күңелле мәшәкатьләр башлана иде… Рушан улымны бүлнистән алып кайткач, мунчада үзем юдым. Тән төзәткечләре бетсен дип тозлы суда коендырдым. Беренче чәчкә күз тиючән була, хасиятләп, аны алдым. Чәч авырлыгы кадәр көмеш бәһасеннән сәдака бирдек. Мулла чакырып, исем куштырдык…

– Кызык… Мин бу гореф-гадәтләрнең, бу йолаларның берсен дә белмим икән бит…

– Борчылма, Айсылу! Безнең бит аяклы энциклопедия – әби бар! Өтеренә, ноктасына кадәр өйрәтер, шулай бит, әби!

– Өйрәтермен, боерган булса, өйрәтермен! Аллаһ Тәгалә сезнең балаларны да күрергә насыйп итсен! Кызым, шушы калфакны бүләк итим әле сиңа…

Айсылу күтәрелеп карады да, телсез калды. Гайшәбикә әби кулындагы энҗе-сәйләннәр белән чигелгән ак калфак бүләк өчен артык затлы иде.

– Юк, әби, шулкадәр зур бүләкне ничек алыйм?

– Ал, ал, кызым. Бер булса да кияргә иде дип, үзем чиккән идем, күпме хыялландым… Тол хатынга килешмәс дип, базмадым. Син яшь әле, сиңа килешер. Аллаһ кушса, никах мәҗлесендә киярсең, ал, кызым!

Айсылуның язмыш тарафыннан шактый кыйналган, шулай да каешланмаган күңеле рәхәт сулкылдады. Үз әбисенә, үз әнисенә сыенгандай, Гайшәбикә әбине кочып алды.

– Яле, киеп күрсәт әле! – Рушан бер кичтә инде икенче кабат үксеп елаудан коткарып калды. Айсылу ишек катында торган өч җәпле көзге каршына килеп басты. Кара-коңгырт чәчләрен тыгызлап ике толымга үрде, калфагын беркетте. Рушан сөйгәненнән күзен алмады: җырларда җырланган, әкиятләрдә макталган чын татар кызы бит аның Айсылуы!

– Сөбханалла! Күз тимәсен, кызым! Рушан улымны бәхетле итәргә туган бала бул! – Гайшәбикә әби үз эченнән генә әллә теләкләрен, әллә догаларын пышылдады, яшьлек хыялының чынбарлыктагы чагылышы булган Айсылуга сокланып, ихластан яратып карады.

Илаһи мизгелне бозып, каты итеп ишек дөбердәттеләр. Гайшәбикә әбинең, нидер сизенгәндәй, бөтен эчке дөньясы калтырады. Тик яшьләргә берни сиздермәде, аларны түр якта калдырып, ишеккә юнәлде. Сизелерлек үк дерелдәгән куллары белән ишек келәсенә үрелде. Шуны гына көткәндәй, кемнеңдер авырлыгына чыдый алмыйча ишек ачылды… Ишек ачылды һәм бусагага таушалган, пычранган, хәлдән язган гәүдә ауды. Кетер актан киенгән, кетер актан басып торган Гайшәбикә әби үз аяклары астында аунаган бу мескен адәмдә үз баласының, үз газизенең, үз йөрәк парәсенең йөз чалымнарын таныгандай итте.

– Я Раббым, рәхмәтеңнән ташлама, балаларыма иман байлыгы бир, калебләренә мәрхәмәт орлыклары сал… – дип пышылдады аның иреннәре.

Тәкъдир сикәлтәләрендә абына-абына, соңгы көчен җыеп туган нигезенә кайтып егылган кызының ни үле, ни тере гәүдәсенә карап, Гайшәбикә әби нигәдер җиңел сулап куйды.

Гөлүсә БАТТАЛОВА

Кызыклы һәм кирәкле эш дәфтәре

Түбән Каманың Г.Тукай ис. үзәк китапханәсендә Разил Вәлиевнең «Безнең абый» дип исемләнгән балалар эш дәфтәрен тәкъдим иттеләр.

«Якташ әдипләребезнең иҗатын пропагандалау максатыннан яңа проект башлап җибәрдек. Аның беренчесен Разил Вәлиев иҗатына багышладык. «Безнең абый» дип исемләнгән эш дәфтәре башлангыч сыйныф укучылары өчен татар һәм рус телләрендә тәкъдим ителә. Материалда башваткыч, ребус, әдипнең тормышы, иҗат юлы, аның китаплары урын алган. QR-код аша кереп, әдип турында тулырак мәгълүмат белән танышып була», – диде Түбән Каманың үзәкләштерелгән китапханәләр берләшмәсе җитәкчесе Гөлназ Арсланова.

Эш дәфтәрендә Разил Вәлиевнең Ташлык авылы китапханәсендәге музее, язучының балаларга аталган язмалары аерым сәхифә итеп бирелгән, китапларның фотосурәтләре белән бергә кыскача эчтәлекләре урнаштырылган. Китапта «Әлифба» җыры ноталары белән тәкъдим ителә.

«Разил абый балаларга дөнья әкиятләрен тәрҗемә итүче буларак таныш. «Алтын алма», «Җырчы казлар» – китапханәдә иң күп укыла торган китаплар. Эш дәфтәрендә без балаларның үзләренә әкият, шигырь язу һәм рәсем ясау мөмкинлекләрен тудырдык. Әкиятләр бала хәтерендә саклансын өчен буягычлар да бар. Биредә Разил Вәлиевнең иҗаты белән җиңел форматта танышырга мөмкин. Һәр кеше үзенең нәсел җебен белергә тиеш, дигән борынгылар. Шуңа күрә дә китапта Разил абыйның шәҗәрәсе мисалында балаларга үзләренең шәҗәрәләрен төзергә тәкъдим иттек, – диде Гөлназ Арсланова. – Әкиятләр буенча төзелгән мавыктыргыч уен да балаларның күңеленә хуш килер дип уйлыйбыз. Разил абый кебек шәхесләр күп булмый, шуңа да аның белән горурланырга, хөрмәтли белергә, яшь буында шушы шәхесләр үрнәгендә милли горурлык хисләре тәрбияләргә кирәк».

Г. Арсланова киләсе ел китапханәдә Түбән Кама төбәгендә яшәп имам булган, фәлсәфи һәм иҗтимагый-тарихи әсәрләре белән халык арасында популярлык казанган дин галиме Таҗетдин Ялчыголга багышланачагын әйтте.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

Дөньяны шаулаткан татар

● Р. Нуриев. Документаль фильмда.

● Р. Нуриев Казанда. Рамил Гали фотосы.

(Ахыры. Башы 41, 42,43 нче саннарда).

Соңгы айларында үлемгә ышанмый. Сәламәтлеген ныгыту өчен елына 2 млн доллар акча тота ич. Ул бит әле берни эшләргә дә җитешмәде төсле...

Биюче 10 октябрьдә дуслары белән Сен-Бартелемига, тыныч кына ял итәргә китә. Ун көн кояш нурлары астында була. Елый-елый утрауның җирен үбә. Тик үз ватаны туфрагын үбәргә генә мөмкинлеге булмый. Ноябрь аенда биюченең тән тиресе бик югары. Авыру туңа, өши, башлык киеп кенә йөри, Бах көйләрен тыңлый... Дуслары аның белән хушлаша башлый. 20 ноябрьдә даһи биюченең хәле тагын да начараеп китә, аны хастаханәгә илтәләр, ашый алмагач, вена аша гына тукландыра башлыйлар. Р.Нуриев ахыргача түзә.

Даһи биюче 1993 елның 6 гыйнварында хастаханәдә, үз дуслары кулында тыныч кына үлә. 12 гыйнварда аның табутын Париждагы йорттан алып чыгалар. «Гранд-опера»га кадәрге бар урамнарда автомобиль юллары ябыла. Театр алдындагы мәйданда бик күп халык басып тора. Тамаша залы халык белән тулы. Зур булмаган оркестр Бахны уйный. Р.Нуриев кара костюмга киендерелгән, башында – чалма. Аның җәсәде – табутта. Табутны алты балет солисты күтәреп бара.

Аннары Байрон, Микеланджело, Гете һәм Рембо шигырьләрен шагыйрьләр үз ана телләрендә укыйлар. Пушкинның «Евгений Онегин»ыннан өзекне дусты, балерина Н.Кургапкина укый. Нәкъ Рудольф Хәмит улы васыяте буенча. Чайковский, Бах көйләре яңгырый. Табутны залдан алып чыкканда исә, Малерның «Сәфәр кылучы өйрәнчек-останың җырлары» башкарыла (Нуриев бу текстны кайчандыр үз хезмәтләрендә кулланган булган).

Сен-Женевьев де Буа рус зиратына кадәр ерак, ул Париждан егерме чакрым ераклыкта. Биючене Монмартр зиратында да җирләгән булырлар иде. Ләкин ул шушы читтәге зиратны алдан ук сайлый. Аны туганнары Роза белән аның кызы Гүзәл генә түгел, бар дөньядан килгән күп санлы дуслары да соңгы юлга озата бара.

Нуриевнең кабер өсте үзенчәлекле итеп бизәлгән. «Гранд-опера» рәссамы, дусты Энцо Фриджерио биюче каберенә юл сандыгы өстенә ябылып куелгандай итеп, искиткеч матур келәм «ябә». Келәм – мозаикалы смальтадан. Кемдер, аның эскизын Нуриев үзе үк ясап калдырган, ди. Кабер бизәме 1996 елда Италия мозаика остаханәсендә иҗат ителгән, орнаментларның җөйләре күренмәслек итеп тоташтырганнар, әслек келәм структурасы килеп чыгарлык кытыршы, дулкынлы итеп тә ясалган. Аны соры төстәге тәреләргә бай зиратта кирәгеннән артык җете дип тә табалар, бу мозаиканың кисәкләрен куптарып та алгалыйлар, келәмне төзекләндерү эшләре еш башкарыла...

«Вэнити фэйр» журналы Р.Нуриевнең биеп тапкан бар матди байлыгын 80 млн доллар дип бәяли. Париждагы апартаментлары, Лондондагы, Монте-Карлодагы йортлары, Вирджиния штатындагы ранчосы, Нью-Йорктагы фатиры, Франциянең Сен-Бартелеми утравындагы, Кариб диңгезе ярындагы йорты, Италиядәге, Капридан бик ерак булмаган өч утраудан торган архипелаг – Ли Галли утравы, утраудагы вилласы, бассейны, балет студиясе... Биюченең байлыгы шактый. Ли Галли утравын яхшырту өчен күп акчалар түгә ул, чөнки анда су, электр уты да булмый, кирәк- яракларны да вертолет белән генә ташырга мөмкин. Бар акчалар аның ризалыгы белән инвестицияләнгән, ә аннары шул үз ризалыгы белән төзелгән оешмаларга – Европа фондына һәм Америка фондына калдырылган. Васыятьнамә буенча, алар балет үсешенә матди булышлык күрсәтергә, яңа әсәрләргә заказ бирергә, балет труппаларына, яшь биючеләргә субсидияләр бирергә тиеш. Илебезнең Көнбатышта бер ел укыган яшь биючеләре алдына исә Россиягә әйләнеп кайтып, андагы бию үсешенә ярдәм итү шарты да куелган. Парижда аның текстиль әйберләрен, музыка коралларын, костюмнарын туплап, халык өчен күргәзмә ачарга кушылган. Фондлар шулай ук СПИД белән авыручылар өчен дарулар уйлап табу эшчәнлегенә матди ярдәм итәргә дә тиеш. Акчаларның берникадәр өлеше туганнарына да васыять ителгән: Розага, Розидага, Лилия кызы Әлфиягә ике йөз мең доллар һәм Розаның кызы Гүзәлгә, Әлфиянең улына һәм Розиданың ике улына илле мең доллар. Туганнарына кагылышлы васыятьнамә әле моның белән генә чикләнми, туганнарының АКШка күченәсе килгәннәре фондлардагы акча бәрабәренә күченә, җитди белем алырга теләүчеләре булса, фонд акчаларын сарыф итеп укый да ала диелгән була һ.б. 1997 елда Европа фонды Розага, Гүзәлгә 1800 000 доллар бүлеп бирү турында килешү дә төзиячәк, моннан кала Розага һәр ай саен аерым бер күләмдәге акча да түләнә, ул кызы белән Монакода, энесе милке булган фатирда гомер кичерә.

Әлеге фондлар Лондон һәм Нью-Йорк аукционнарында бик тиз арада даһи биюченең өс һәм аяк киемнәрен, келәмнәрен, бик кыйммәтле картиналарын, җиһазларны һәм хәтта фотоларын да сатарга тели. Роза белән Гүзәл аларны Р.Нуриевнең теләкләрен үтәмәүдә гаепли. «Рудольф бар коллекцияләре тупланган музей ачарга теләгән иде, – ди алар. – Аннары фондларга шулкадәр акча калдырмас иде, аңа йогынты ясалган булган», – дип тә белдерәләр. Компромисс табарга кирәк дигән карар кабул ителә. Бераздан Нью-Йорк аукционы сатудан – 7,9 млн доллар, ә Лондон аукционы 2,7 млн доллар табыш ала. Гаугалы хәлләр аннан соң да дәвам итә... Күп очракта әлеге фондлардагы акчаларның эреп дигәндәй юкка чыга баруы, аларның васыять буенча эшчәнлеге сүлпән булуы искәртелә.

Нуриев сәхнә костюмнарын бүләк итәргә дә яраткан булган... Берникадәр сәхнә костюмы, балет әйберләре, музыка кораллары, бит читенә язмалар язып куелган партитуралары Франциянең Милли китапханәсендә һәм Парижның Карнавале тарихы музеенда даими экспозициядә. Калган өч йөз әйбере 2013 елдан Мулендагы Сәхнә костюмнары һәм сценография Милли үзәгендә. Ул яшәгән җирләргә мемориаль такталар урнаштырылган.

2018 елда исә Казанда Рудольф Нуриевкә багышланган һәйкәл куелды. Ул театр артында ук. Билгеле, һәйкәл киңрәк мәйданга урнаштырылса, яхшырак булыр иде. Ләкин шулай да ул – Россиядә даһи биючегә багышланган беренче һәйкәл.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

● Кабере.

ОРЕНБУРГ

● Оренбургтагы кәрван-сарай бинасы.

Оренбург төбәгенә тәүге тапкыр 35 ел элек, «Татарлар Пугачев явында» дип аталачак тарихи хезмәтемә мәгълүматлар эзләргә дип барган идем. Бер тарихи романым белән әлеге хезмәт «Сәет батыр» исемле китап булып 1994 елда дөнья күрде һәм 90 мең данә күләмендә Советлар Союзы буйлап таратылды. Аннан соң инде Россиянең әллә никадәр төбәкләренә, хәтта 7-8 чит илгә дә сәяхәтләр кылдым. Менә, ниһаять, ике атна элек Оренбург каласын янә бер мәртәбә барып күрү бәхете эләкте. «Казан утлары», «Безнең мирас» журналларының мөхәррирләре Рөстәм Галиуллин, Ләбиб Лерон һәм «Татар-информ» агентлыгының хәбәрчесе Рифат Каюмов белән берлектә 700-800 чакрымлык арага сәяхәткә киттек.

● Без шәһәр музее һәм Пушкин һәйкәле каршында.

Узган баруымда манзара кылырга вакыт эләкмәгәч, бу юлы сәяхәтне шуннан башлыйк дип, атаклы кәрван-сарай бинасын карарга булдык. Бер ел ара белән 1743 һәм 1744 елларда Җаек һәм Сакмар елгалары буенда Оренбург крепосте белән Каргалы яки Сәгыйт бистәсе калкып чыккач, каланың тышкы ягында зур сәүдә үзәге төзелә. Урта Азия яки Төркестаннан дөя кәрваннары белән «мал» ташыган кыргыз, үзбәк, казах, төрекмән сәүдәгәрләре дә, Россия империясенең төрле калаларыннан җыйналган алыш-биреш осталары да сәүдә кибетләрен шул үзәктә ача. Очраклы караклар шайкасы бәреп кереп таламасын өчен, ул һәр яктан агач диварлар белән ныгытылган була. 1840 елларда Оренбург һәм Самара өлкәләренең хәрби генерал-губернаторы булып торган генерал Перовский кәрван-сарайны һәм Урта Азия ягыннан сәүдә итәргә килгән кунаклар намаз уку, гыйбадәт кылу өчен аерым мәчетне дә төзеп куярга карар кыла. Булачак кәрван-сарай проектын атаклы рус рәссамы В.Брюлловның энесе А.Брюллов әзерли. Шулай итеп, 1846 елда Оренбургның бер як читендә таштан төзелгән кәрван-сарай белән мәчет калкып чыга.

Дүрт ягыннан да икешәр-өчәр катлы йортлар белән уратып алынган бик зур комплекс бу. Мәчетнең гөмбәзле, гыйбадәт кылу залы мәйдан уртасында, ә манара үзе ике капка арасына урнаштырылган. Элек, мөгаен, «тройка» атлар һәм фаэтоннар белән шул капкалар аша кәрван-сарай уртасына кереп йөргәннәрдер. Хәзер инде әлеге комплекста сәүдә дигән гамәлнең бөтенләй эзе дә юк. Элек байлар ял итәргә тукталган яки үз конторасын ачкан барча залларга транспорт прокуратурасы, полиция бүлекләре, тагын әллә нинди ят оешмалар хуҗа булып алган. Кәрван-сарай бинасы, тарихи объект буларак, Оренбург өлкәсенең мәдәният министрлыгы карамагына тапшырылган да, андагы «эшем иярләре» элек мөселман халыкларының сәүдә үзәге булып торган сарайны өченче кулларга арендага тапшырып, ансат кына «акча суга» икән. Бүгенге Башкортстанның көньягында урнашкан 40 волость (ул мәйданны бүгенге 7-8 район дип күз алдына китерү ялгыш түгел) вәкиле шушы кәрван-сарайның икенче катындагы зур гына бер залга җыела да, 1917 елның 8 декабрендә (Кече) Башкортстан республикасы төзелү турында карар кабул итә. «Олуг агай» оныклары ул залның тарихилыгына төкереп тә бирми, аны күптән өч кечкенә кабинет итеп бүлеп куйганнар да, аларга шул ук «өлкән» кавем кереп оялаган. Шул республика игълан ителгән үзәк булганга күрә, Башкортстан хөкүмәте 90 нчы елларда кәрван-сарайны үз милке дип танытырга нәфес сузып караган иде дә, аларның дәгъвасына сыңар колак та салучы табылмады. Нәкъ Башкортстанның үзе шикелле үк, кәрван-сарайга да бүген Мәскәү хуҗа.

Хәер, бер башкорт малына гына да түгел. Революциягә кадәр татар сәүдәгәрләре һәм татар зыялылары төзеп куйган барча тарихи ядкәрләргә бүген килмешәкләр хуҗа булуын күреп, тәмам хәйран калдык. Оренбургта атаклы бертуган татар сәүдәгәрләре Әхмәт, Мәхмүт һәм Гани Хөсәеновлар үз исемнәрендәге «Хөсәения» мәдрәсәсен һәм аның янәшәсендә үк «Хөсәения» мәчетен төзеп куйган булуы бар җиһанга мәгълүм. Оренбург өлкәсендә бүген ким дигәндә 150 меңнән артык татар вәкиле яши. Кешелек кануннары буенча бизмәннәргә салсаң, ниндидер байлык яки бина синең бабаларыңнан калган мирас түгел икән, димәк, син чит-ят малга борыныңны сузма. Иллә мәгәр «өлкән агайлар» кавеменә андый гомумкешелек кануннары күрсәтмә түгел бит ул. Чип-чиста татар милләтенеке булган «Хөсәения» мәдрәсәсе бинасына да

● Шәһәр нигезләнүгә 265 ел тулу уңаеннан җәяүлеләр өчен Урал елгасы аша салынган яңа күпер.

● «Хөсәения» мәчете.

● Үзәк урамда элек сәүдәгәрләр ялга туктала торган кунак йорты – «Гостиный двор». Анда 1833 елда А.Пушкин да берничә төн уздырган.

ӨЛКӘСЕНӘ СӘЯХӘТ

● Без Оренбургның Х.Ямашев исемендәге китапханәсендә.

● Бирдә бистәсендә 1773-1774 елларда Пугачев «сарае» урнашкан йорт урынына куелган истәлек монументы янында.

1960 елларда ук авыл хуҗалыгы институты кереп урнашкан (Бөек Ватан сугышы чорында анда хәрби госпиталь дә эшләгән). «Хөсәения» мәчете дә мин фәкыйрегез тәүге тапкыр барган 1987 елда минераль ашлама төялгән йөзәрләгән капчык белән тутырылган иде. Аллага шөкер, мәчет бүген халыкка кайтарылган, ә элек Сәгыйть Рәмиев, Әхмәтзәки Вәлиди, Мирхәйдәр Фәйзи, Муса Җәлил, Җамал Вәлиди кебек атаклыларыбыз укыган мәдрәсә бинасын һаман баскык аяк табаннары таптый.

Алга таба, XX гасыр башында тулысынча татар зыялыларының шәхси йортларыннан торган зур бер бистә хасил иткән урамнар буенча сәяхәткә киттек. Революция алдыннан гына Россия территориясендәге йөзәрләгән алтын приискаларына хуҗа булып торган, ә инкыйлабтан соң бар байлыгын соңгы бакыр тиененә чаклы карак хөкүмәткә тапшырган Закир Рәмиев-Дәрдмәнд яшәгән атаклы һәм хәтта бүген дә искиткеч күренешле йортка Оренбург өлкәсе сәүдәсендәге товар бәяләрен һәм тарифны «контрольдә тотучы» департамент хуҗа. Аның күршесендә Шакир Рәмиев яшәгән йортка бүген «Биосфера» маркалы оешманың карак-бизнесменнары кереп оялаган. Дәрдемәнд белән янәшә генә яшәгән бөек Риза Фәхретдин йортына бүген зур бер предприятие хуҗа булып алган һәм хәзрәт гомер иткән бер кат кирпеч дивар өстенә тагын ике кат өстәп, мәшһүр бинаны «прихватизация»ләп тә куйган. Үзәккәрәк таба атласак, революциягә чаклы дистәләгән татар байларының кибетләре урнашкан «Сәүдә рәтләре» белән «Меновый двор» биналарына бүген янә килмешәкләр хуҗа. Бертуган Хөсәеновлар 1902-1905 елларда өч катлы һәм Европача итеп «Американ» кунакханәсен төзетеп куйган, 1907 елда аның подвалында Хөсәен Ямашев татарча беренче демократик газета – «Урал»ны да нәшер итеп яткан. Мәгәр шәһәр үзәгендәге әлеге кунакханәне революциядән соң ук килмешәкләр эләктергән, бүген аның өч катын да Федераль куркынычсызлык хезмәте вәкилләре били. Урам як диварларда, билгеле ки, бернинди күрсәткеч такталар да юк, Х.Ямашевның «Урал» газетасы турында белдерүен тыкрык якка кертеп яшергәннәр, язуын да узгынчылар һич танырлык түгел. Мин, бичара, шаккатудан айный алмый интегәм: 1,8 миллион халкы булган өлкә өчен өчәр катлы кунакханә бүлмәләрен тутырырдай куркынычсызлык хезмәте нигә кирәк икән? Оренбургта аларга кемнәр яный да, кемнәр өнен ала?..

Әле шушы ук Оренбургта Галимҗан Ибраһимов килеп укыган Вәли мулла мәдрәсәсенең биналары һәм анда укыткан муллалар һәм хәлфәләр өчен махсус төзелгән йортлар, күренекле композитор Җәүдәт Фәйзи туган һәм балалык елларын уздырган мәһабәт йорт, янә дистәләгән татар сәүдәгәрләренең болындай ихаталары, алар эчендәге сарай һәм келәтләр, йорт һәм мунчалар да булган бит. Бүген аларның да күпчелегенә килмешәк кавем вәкилләре кереп оялаган, ә бер өлеше ташландык хәлгә килеп беткән инде. Шушылар белән танышып йөргән чакта баш капкачын кайнар сорау борауламый калмый: әлеге Оренбург каласында гына да революциягә кадәр татар байлары төзеп өлгерткән йөзәрләгән бинаны «өлкән агай» вәкилләре тартып алган һәм бер гасыр буена бушлай файдаланган. Бер гасырлык аренда хакларын гына бизмәнгә салсаң да, ул агайның хөкүмәте безнең татар милләте алдында ничә йөз миллиард яки триллион тәңкәлек бурычка батты икән? Оренбургтан тыш, Әстерхан, Троицк, Уфа, Казан, Тубыл, Төмән, Касыйм, Акмәчет, Акъяр, Бакчасарай шикелле дистәләгән башка калалар да бар бит әле. Ә аларда татар зыялылары кулыннан тартып алынган миллиард сумлык байлыклар өчен әҗәтне татар халкына кемнәр генә һәм кайчан кайтарыр соң? Большевиклар илне әле 1917 елда ук сорыкорт вә әрәмтамаклардан арындырган сыман булган иде, ә татар милләтенең сулен суырудан нигә туктамыйлар?..

Үзен бөек дип атаган халыкның заманында мәйдан тоткан сәүдәгәр оныклары да рәнҗү һәм гарьлек тойгысыннан арына алмый гомер кичерәдер. Әнә, бүген Җаек елгасына терәлеп торучы педагогика һәм медицина «университетлары», 1955-1957 елларда Ю.Гагарин укыган авиация техникумы да XIX гасырда өлкә һәм Төркестанны басып алу белән идарә иткән губернаторларның сарайларына кереп урнашкан бит. Бүген Оренбург өлкәсе музее да, диварларына «монда фәлән-фәлән елларда Тарас Шевченко, Россия империясенең финанс министры С.Витте, СССР Язучылар берлеге рәисе А.Фадеев булды яки яшәде» дип язылган истәлек такталары беркетелгән әллә ничә дистә биналар да – элекке байларныкы. Россия Академиясенең беренче хокуклы әгъзасы, тарихчы Петр Рычков, 1918-1919 елларда Оренбург өлкәсенең иң беренче мәгариф комиссары булып торган, ә аннары Шәрык илләрендә эшли-эшли «Кызыл паша» атамасын алган, ләкин 1938 елда атып үтерелгән татар каһарманы Кәрим Хәкимов, 1920-1925 елларда башкаласы шушы ук Оренбург булып торган Казахстан АССР хөкүмәте эшләгән, 1920 елның октябрь аенда Казахстан автономияле республикасы игълан ителгән һәм тәүге оештыру корылтае үткәрелгән биналар – тарих энҗеләре – барысы да исән, ләкин аларның һәркайсы котылгысыз рәвештә ремонт көтеп тора.

(Дәвамы 14 нче биттә).

● Оренбургта татар эзен юкка чыгару өчен урам исемен кансыз комиссар Левашовныкына алыштырганнар.

● Оренбургның татар бистәсендә Дәрдмәнд яшәгән йорт.

● Г.Ибраһимов укыган Вәли мулла мәдрәсәсенең бер бинасы.

● Атаклы Шакир Рәмиевтән калган капкалы йортларның берсе.

● Булачак композитор Җәүдәт Фәйзи 1910-1924 елларда үскән йорт.

Оренбург өлкәсенә сәяхәт

(Ахыры. Башы 12 нче биттә).

Ярымҗимерек юллар буйлап шул биналар арасында адашып йөри торгач, кайчагында: «Провинциядә таралып яткан бу шәһәрләр Мәскәүдәге XX гасыр падишаһларының берсенә дә кирәкмәдә микәнни соң, нигә алар монда кыегая башлаган данлы йортларның берсенә дә ремонт үткәртмәгән яисә алар урынына сыңар гына да яңа сарай-бина салдырмаган?» – дип ачынып куймыйча да булмый...

Алай дисәң, шул үзәк Советская урамының бер ягында шәһәргә 1743 елның 30 апрелендә тәүге нигез салган губернатор Иван Неплюев хөрмәтенә әллә ничә колонналы капка төзеп куйганнар бит әнә. Мөгаен, ел саен аның бюстын чәчәкләргә күмәләрдер, мәдхия җырлары өзлексез сузыладыр. Ләкин алар өлкән агай белән янәшәдә, күрше фатирда ук татар, башкорт, казах, кыргыз вәкилләре дә гомер итүен исәпкә алып вакланмый. Шуңа күрә тантаналар барышында мәкерле Неплюевның 1755 елда, далаларга махсус чапкыннар җибәреп һәм «ялгыш кына төшеп калган» хатлар тараттырып, казах солтаннары белән татар-башкорт старшиналары арасында җәйләү өчен бәрелешләр китереп чыгаруын һәм низаглар вакытында 50 мең мөселман иренең һәлак булуын гына искә алып тормый. Оренбургтагы музей хезмәткәрләре өчен Акай-Килмәк фетнәсен бастырырга юлланган җәза гаскәрләре башлыклары В.Татищев белән И.Кириллов та фәкать тарихчы һәм географчы гына. Ә асылда аларның һәркайсы – Уфа белән Оренбург арасындагы Ногай юлында йөзәрләгән авылларны яндырып, йорт хуҗалары булган ирләрен дар агачларына асып, казыкларга утыртып, гәүдәләрен кисәкләргә чапкалап юкка чыгаручы җәллад. Ләкин бездә ике төрле бизмән хакимлек итә, шул сәбәпле асыл йөз, асыл бәяне ачып салучы юк...

Хәер, Оренбург каласының яшь буыны чын тарихны, гомумән, беләме икән? Мәктәп программаларында аларга А.Пушкинның «Капитан кызы» әсәрен һичшиксез укыталар, ә шул ук бөекнең тарихи «Пугачев бунт»ын яшереп калдыралардыр. Шундый нәтиҗә ясамый да булмый, чөнки 1773 елның октябреннән 1774 елның апрель аена кадәр коточкыч зур крестьяннар восстаниесенең үзәге – хәзер инде шушы кала эченә йотылган Бирдә бистәсендә булган бит. Шуннан атаклы Пугачев ярты ел буена отрядлар җибәреп, Оренбург каласын гел-гел чукып торган, гайрәтләнеп киткән чакларында үзе дә, Иван атлы чаң манарасына менеп, шуның өченче катыннан кирмән эчен дә тупка тотып алган. Губернатор Рейнсдорпның шул вакытта патшабикә Екатеринага хисап тотып язган рапортлары бик гыйбрәтле. «Карак Пугачев утка тоткан чакта, бер бомбасы Ситников атлы казак утарына төшеп ярылды да, аның яраксыз хәлгә килгән ат чанасы белән җимерек сарай калдыкларын мин 1 сум 50 тиен хактан үземә сатып алдым һәм шуларның калдыкларын ике атна буена губернатор йортын җылытырга тоттым». Йә Ходаем, бүген губернаторлар түгел, һичьюгы авыл советы рәисләре яки мәктәп директорлары булса да, үзләре туздырган акча турында шушындый рапорт язып торса икән!..

Бирдә бистәсендәге Пугачев – «падишаһ» йортыннан сыңар гына йомычка да калмаган шул. Безнең кебек, нык чокынып эзләүчеләр өчен, бистәдәге Восстание белән Салават Юлаев (ә ни өчен Каргалы авылында оешкан татар полкының командиры, полковник дәрәҗәсенә ирешеп, Оренбургтан Казанга кадәр данлы юл узган һәм барча яуларда катнашкан Муса Галиев түгел?) исемнәрендәге урамнар кисешендә кирпечтән бер шакмак әвәләп куйганнар да ул фетнә чорындагы бер туп үрнәген урнаштырганнар. Ә Пугачевның 20 мең кешелек гаскәр туплап, ярты ел буена барлык Россиягә дәһшәт бөркеп яшәве турында сыңар җөмлә дә юк. Фетнә яисә баш күтәрүләр бүген дә куркыныч һәм нык тыелган гамәл. Бүген кирмән белән бер ритмда сулыш алганнар гына дан-шөһрәт вә акчаларга ия...

Билгеле, 700 чакрымдагы Оренбург каласына килеп җиткәч, без Х.Ямашев исемендәге милли китапханәдә очрашу да үткәрми калмадык. Китапханә мөдире Светлана Әхмәтҗановага бик зур рәхмәт, 50-60 ка якын асыл татар вәкилләрен җыя белгән. Ике сәгатькә сузылган әңгәмә барышында искә алмаган тараф калмады, китапханәнең байлыгына сокланып туймадык. Элек татарныкы булган ядкәр-биналарны чит-ят куллар үзләренә алып бетерсә дә, татар рухы, татар җаны һич сүнмәгән бирегә. Нәкъ Айдар Хәлим шигырендәге кебек:

Безне талап алар баемады,
Хәер сорашалар, син күрсәң!
Без һаман бай, чөнки
таңнан торып,
Татарыбыз эшли –
Без исән! Без исән! Без исән!

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.

● Оренбургның җәяүлеләр генә йөри торган Советская урамында 1920 елның октябрендә Казахстан автономияле республикасын оештыруга багышланган тәүге корылтай үткәрелгән бина.

● Бертуган Хөсәеновлар 1906 елда төзеткән «Хөсәения» мәдрәсәсе.

Әнәк авылы

(Дәвамы. Башы 42, 43 нче санда).

Бәләбәй округының Сарай авылы (хәзер Башкортстанның Әлшәй районы авылы) «типтәр»ләренең исемлеген өйрәнгәндә, бу авылдан Сагындык Исергәповның 1785 елда Минзәлә округы Әнәк авылына күчеп утыруы турындагы мәгълүматка игътибар иттек. Аның гаиләсендә бу вакытта хатыны Сәлимә Мортаза кызы, уллары Кечек, Вәлиша, 4 кызы (икесе «башкорт»та кияүдә) була. Олы улы Рәхмәтулла Сагындыков үз гаиләсе белән яши (БР МА, И-138 ф., 2 тасв., 34 сакл. бер., 437 б. а.-438 б.).

Сагындыкның абыйсы Сөендек Исергәпов (1793 елда вафат) гаиләсе дә Бәләбәй округының Сарай авылы исемлегендә теркәлгән. Әмма Сөендекнең тол хатыны Мөхиббә Ямангол кызы (43 яшь), 4 улы һәм 2 кызы (кечесе 1784 елда мәрхүмә була) беркая да күченми (Шунда ук, 438 б.).

Сагындыктан бер ел алдарак, Сарай авылыннан Әнәккә тагын ике нәсел күченгән. Боларның беренчесе – Мортаза Исаев. Аның 2 хатыны (Гөлбәдәр Мәүләкәй кызы һәм Баян Биккенә кызы), улы Габделлатыйф һәм кызы була (Шунда ук, 448 б.). Мортаза Әнәк авылының 1762 елгы исемлеге буенча Исәй Әнәковның улы буларак билгеле иде. Димәк, болар бабасы Әнәк нигез салган туган авылына кире кайтырга булган.

Икенче нәсел – 4 бертуган Абдулла, Габидулла, Фәйзулла, Хәбибулла Шәриповлар. Алар анасы Салиха Кадермәт кызы, сеңлесе Фатыйма, Абдулланың хатыны Шәһәрбану Сәгыйть кызы, улы Гали, кызлары Шәмсениса, Шәмсикамәр, Габидулланың хатыны Гөлзия Мөрсәлим кызы белән бергә күченә (Шунда ук, 448-448 б. а.). Габидулла башка чыганакларда Гобәйдулла дип язылган. 1762 елгы исемлектә Абдулла белән Гобәйдулла Шәрип Морзин уллары дип күрсәтелгән иде. Димәк, болар да туган авылы Әнәккә кире кайтырга карар кылган.

Югарыда әйтеп үткән Сарай авылы Минзәлә округының тагын бер авыл кешеләрен үзенә тарткан. Монда 1793 елда Коллар авылыннан Йосыф Туйчин (58 яшь) гаиләсе дә күчеп утыра. Аның хатыны, уллары Күсәпкол (8), Теләпкол (5), кызлары Алтынчәч (12) һәм Карачәч (9) була (Шунда ук, 448 б. а.).

1795 елда Уфа наместничествосы Минзәлә округына кергән Әнәктә 70 ир-ат һәм 63 хатын-кыз теркәлә. Ревизия документына «выборной» Ишмөхәммәт Ишкилдин нәсел тамгасын салган.

Исемлек башында Кушкилде Юлаев (1795 елда вафат) гаиләсе теркәлгән. Аның хатыннары Сылубикә Йортбагыш кызы (52 яшь) һәм Аднабикә Мөсәй кызы (47), уллары Бакир (39), Бәшир (38), Хәмит (33), Хәмидулла (16) һәм оныклары калган.

Болардан соң Баязит (26 яшь), Мәхмүт (24), Мәксүт (20) Сөләймановлар гаиләләре турында мәгълүматлар бирелә.

Алга таба ревизия исемлегендә Дәмин (1787 елда вафат) һәм Ишем (1789 елда вафат) Мәсгүтов варисларын күрәбез. Дәмин нәселен уллары Тимеркәй (29), Миңлебай (20), Корбангали (14), Ишемнекен – Хәсән дәвам итә.

Авылда өлкәннәрнең берсе Гапсәлам Юлаев (70 яшь) була. Ул хатыны Зәбидә Ает кызы (42), уллары Габделкәрим (28), Габделвахит (21), Габделмәҗит (16), киленнәре һәм оныклары белән яши.

Ревизия исемлегенең ахырынарак Әнәк авылына күчеп утырган хуҗалыклар турында мәгълүматлар бирелә. Алар чыгышы буенча Минзәлә һәм Бәләбәй округларына караган Сабай авыллары «типтәр»ләре дип күрсәтелә. Монда үз авыллары һәм Әнәк халкыннан рөхсәт алып килеп утырганнар.

Минзәлә округы Сабай авылыннан күченүчеләрне атап үтик. Бер хуҗалык булып Аиткол Габделкәримов (34 яшь), аның хатыны Гөлсем Әхмәр кызы (42), балалары Мөхәммәтәмин (8), Мөхәммәтгали (4), Мөхиҗамал (13), Шәмсикамәр (11), туганы Мөхәммәтрәхим Габделкәримов (28, аның хатыны Фатыйма Салих кызы (25; Минзәлә округы Бүләр авылы «типтәр»е кызы), уллары Билал (3) һәм Насих (2) яши. Болардан соң ялгыз яшәүче Сәлим Даутов (37 яшь) күрсәтелә.

Бәләбәй округыннан күченүчеләргә игътибар итик. Монда җитди искәрмә биреп итү кирәк. Төгәлрәк чыганактан авылның исеме Сарай дип аталуын белгән идек, алга таба сүз шул авыл кешеләре турында барачак.

Сарайдан беренче булып алдарак телгә алынган Мортаза Исаев, аның хатыннары Гөлбәдәр Мәүләкәй кызы (Минзәлә округы Дусай-Кичү авылы татары кызы) һәм Баян Биктимер кызы, аларның улы Габделлатыйп, Габделлатыйпның хатыны Мөхиббә Айдагол кызы (ул шул округның Айман авылы «башкорт»ы кызы), аларның уллары Габделхаликъ (9), Габделхәмит (6), аларның кызлары Рәйхан (8), Галәмша (2) теркәлгән.

Аерым хуҗалык булып бертуганнар Рәхмәтулла (33 яшь), Кечек (24), Вәлиша (16), аларның анасы, гаиләләре яши. Рәхмәтулланың уллары Сәйфулла (6) һәм Зәйнулла (3), Кечекнеке – Гайнулла (3) теркәлгән. Рәхмәтулланың хатыны Пучыдан, Кечекнеке – Качкын авылы «башкорт»ы кызы була.

Иң соңгы зур хуҗалык булып бертуган Абдулла (38 яшь; уллары Габделнасыйр (12), Ибәтулла (3), Гыйсмәтулла (1)) һәм Гобәйдулла (33; уллары Җиһанша (5), Дәүләтша (3), Батырша (1)) Шәриповлар теркәлгән. Абдулланың хатыны Шәһәрбану Сәгыйть кызы Минзәлә округы Бикбау авылы «типтәр»е гаиләсендә туып-үскән. Гобәйдулла Шәрипов 1 нче хатыны Гөлзия Мирсәлим кызы (шул ук округның Пучы авылы «типтәр»е кызы), 2 нчесе Җәмилә Куат кызы (шул ук округның Бүләк авылы «типтәр»е) кызы була (Шунда ук, 448 б. а.).

Шулай итеп, Әнәк авылына яңа гаиләләр күчеп килү халык саны шактый артуга китерә. 1782 ел белән чагыштырсак, хәзер монда 2 тапкырдан күбрәк кеше яши. Никахлар ясаклы татардан «типтәр»гә әйләнгән әнәклеләрнең башкорт һәм башка сословиедәге татарлар белән бердәм этномәдәни тирәлектә яшәвен чагылдыра. XIX гасырга аяк басыр алдыннан Әнәк җитди үсеш алган авылларның берсе санала.

Таһир КӘРИМОВ.

Редакциядән: *Әнәк авылы турындагы әлеге язма Таһир Кәримов тарихи документларга нигезләнеп әзерләгән «Татар җир волостьлары» дип аталган берничә дистә томлы хезмәтнең бер өлеше генә булып тора. Бүген институт һәм нәшриятлар тарих өчен, милләт өчен өч тиенлек әһәмияте дә булмаган китаплар нәшер итү хакына ел саен миллионлаган сум чыгымнар әрәм итә. Ә татар волостьларындагы һәр авыл, аеруча Башкортстан җиренә күчеп киткән татар авылларының чын тарихын бастырып чыгару өчен хөкүмәт акча таба алмый. Ә теге макулатура белән Таһир Кәримов хезмәтләрен янәшә куеп булмый.*

КУШЫМТА

Минтимер Шәймиев шәҗәрәсе

Минтимер Шәймиев шәҗәрәсе: Килмөхәммәт (Килмәмәт; якынча 1660 елда туган)–Ибраһим (Ибрай; 1687-1783)–Ямангол (1743-1810)–Сәйфетдин (1796)–Шәһидулла (Шәйдулла; 1831)–Шаһ[и]мөхәммәт (Шәймөхәммәт; 1850-1929)–Шаһшәриф (Шәйшәрип; 1901-1967)–Минтимер (20.01.1937; хатыны Сәкинә), уллары Айдар һәм Радик. Минтимер Шәрипович Шәймиев – совет һәм Россия сәясәтчесе, Татарстанның беренче президенты (1991 елның 12 июненнән 2010 елның 25 мартына чаклы).

Архив документларыннан күренүенчә, авыл 1698 елда Морзакай Юкачев биләмәләрендә барлыкка килә. Соңыннан Морзакай җирләрендә барлыкка килгән дистәдән артык авыл (шул исәптән Әнәк) Бүләр олысына карый башлый. XVIII гасыр башында алар ясаклы татар саналса, гасыр ахырынарак тулысынча типтәр сословиесендә күрсәтелә.

III ревизия (1762 ел) документында Минтимер Шаймиевнең ерак бабасы Ибрай Килмәкәев (75 яшь), аның уллары **Ямангол** (20), Миңлегол (18), Сөбханкол (10), Миңлебай (8), Имангол (5) була (РБАДА, 350 ф., 2 тасв., 3801 сакл. бер., 793-795 б.).

Ибрай Килмәкәев һәм аның улы Ямангол – Минтимер Шәймиевнең ерак бабалары. Исемнең соңгысы аеруча игътибарга лаек. **Ямангол** – борынгы төрки халыкларда яңа туган бала янына явыз көчләрне китермәү, аларны куркыту максатыннан чыгып, ир балага Яман яки яман компонентлы берәр кушма исемне бирү йоласы булуын чагылдыра (Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре сүзлеге. – Казан, 1981, 228 б.). Чынлап та, мондый исемле кеше, ягъни Минтимер Шәймиевнең ерак бабасы, исән-имин үсә, 67 яшькә чаклы гомер итә, зур нәсел калдыра.

V ревизия (1795 ел) вакытында Ибрай Килмәкәев Килмәмәтов фамилиясе белән күрсәтелә. Ул 1783 елда 96 яшьтә мәрхүм була. Ибраһимның уллары **Ямангол** (52 яшь), Сөбханкол (42), Миңлебай (40) һәм Имангол (35) кала (БР МА, И-138 ф., 2 тасв., 51 сакл. бер., 62 б. а- 63 б.). Ямангол – Минтимер Шәймиевнең дүртенче буын бабасы.

Әлеге чыганактан күренгәнчә, Яманголның атасы Ибрай (Ибраһим), аныкы Килмәмәт булган. Килмәмәт (Килмәкәй) – Килмөхәммәт исеменең диалекталь варианты.

Яманголның 1795 елда хатыны Калынчәч (Минзәлә округының Айман авылы «башкорты» кызы) уллары Гаделша (17 яшь), Әмирхан (3), кызы Рабига (6) була. Яманголның энеләре Сөбханкол (42), Миңлебай (40) һәм Имангол (35) Ибраевларның хатыннары һәм балалары күрсәтелмәгән.

VI ревизия (1811 ел) документыннан күренгәнчә, Ямангол Ибраев 1810 елда вафат була. Аның нәселен уллары Гаделша (33 яшь), Әмирхан (19), **Сәйфетдин** (15), Хисмәтулла (5) дәвам итә. Яманголның бертуган энеләренең (Сөбханкол, Миңлебай һәм Имангол Ибраевлар) варислары булмый (Шунда ук, 100 сакл. бер., 299 б. а.-300 б.).

VII ревизия (1816 ел) вакытына Яманголның улларыннан бары 19 яшьлек **Сәйфетдин** генә өйләнгән, хатыны Шәмсениса (18 яшь) белән яши. Аларның анасы Калынчәч Сәрмәкәй кызына бу вакытта 55 яшь була (Шунда ук, 297 сакл. бер., 337 б.). **Сәйфетдин** – Минтимер Шәймиевнең өченче буын бабасы.

1834 елда **Сәйфетдин** – зур гаилә башлыгы. VIII ревизия (1834 г.) документыннан күренгәнчә, бу вакытта аның түбәндәге балалары була: уллары Зәйнулла (16 яшь), Сафиулла (14), **Шәһидулла** (3), кызлары Хөббениса (17) Фәрхениса (9) (Шунда ук, 470 сакл. бер., 34 б. а.-35 б.). **Шәһидулла** – Минтимер Шәймиевнең икенче буын бабасы. Гарәп телендә бу исем Алла юлында шәһит китүче, корбан булучы дигән мәгънәгә ия.

Сәйфетдиннең туганнары турында әйтеп үтик. Гаделша Яманголов 1818 елда, аның энесе Әмирхан 1824 елда вафат була. Әмирханның улы Мөхәммәдъяр (9 яшь) кала. Хисмәтулла Яманголовның (27) яңа туган улы Хәбибулла (3 ай) була.

X ревизия (1859 ел) Шәһидулла Сәйфетдиновның (27 яшь) гаиләсе турында мәгълүматлар бирә. Аның беренче хатыныннан туган улы **Шаһимөхәммәт** (9 яшь) була. Шәһидулланың икенче хатыны Гөлҗәмилә Ногман кызыннан (30) Бибихатирә дөньяга килә (Шунда ук, 753 сакл. бер., 561 б. а.-562 б.). **Шаһимөхәммәт** – Минтимер Шәймиевнең бабасы. Шәһидулла Сәйфетдиновның нәселдәше Мөхәммәдъяр Әмирханов 1846 елдан рекрутта була, язмышы билгесез.

Нәсел тарихы буенча башка мәгълүматлар Әнәк авылының Казан һәм Уфа шәһәрләре архивларында сакланучы метрикә кенәгәләрендә табабыз. 1901 елгы метрикәдән күренүенчә, 10 августа Шаһимөхәммәт Шәһидулла улы Сәйфетдинов белән Фәрхиҗиһан Мөхәммәтҗәләл кызы гаиләсендә Минтимер Шәймиевнең атасы Шәйшәрипнең дөньяга килүе теркәлгән. Метрикәдә татарча түбәндәге сүзләр язылган: **«Шаһшәриф.** Августның 10 нчы көнендә. Атасы [Шаһи]мөхәммәд Шәһидулла угълы типтәр Сәйф[етдинов], анасы Фәрһиҗиһан типтәр Мөхәммәдҗәләл кызы Хәмидов. Әнәк карьясендә туды» (ТР ДА, 4 ф., 177 тасв., 786 сакл бер., 126 б. а.).

Шәриф – гарәптән алынган исем, атаклы, хөрмәткә лаеклы һәм мәрхәмәтле, изге дигән мәгънәләрне аңлата.



● Шәйшәрипнең дөньяга килүе теркәлгән метрикә кенәгәсеннән фрагмент.

Атнаның сәяси мизгелләре

МАХМЫР ГАЛӘМӘТЕ

Махмыр халәте, күрәсең, сәяси азынулардан соң да килә. Юкса, Украинадагы хәлләр тирәсендәге азынулар инде чик-чаманы да югалта башлаган иде... Ә күпләп юк итү коралы куллану турындагы сүз куертуларга килгәндә, алар Россия Президенты В.Путин бер-ике ай элек Көнбатышны атом-төш шантажы куллануда гаепләп, Россиянең территориаль бөтенлегенә куркыныч астына куелган очракта, карамакта булган барлык чараларны да куллану мөмкинлеген телгә алганнан соң башланган иде. Үзәк ТВ каналларындагы шоу-программаларда ул чакта беришләр әлеге коралны куллану тактикасы турында хәтта туры эфирда бәхәсләшүгә кадәр дә барып җитте. Ә бит Россиядә хәрби агрессия файдасына гаммәви агитация үзе үк җинаять санала (РФ ЖК, 354нче маддә). Хәер, бүген инде илдә андый «вак-төяк»ләргә бик игътибар итмиләр дә кебек.

Хәлбуки, бүгенге төп уенчылар контрольсез атом-төш сугышы башлануы алар өчен бер-берсен гарантияле юк итүгә тиң булачагын да яхшы аңлый. Шуңа күрә, әлеге коралны куллануга юл куймау мәсьәләсе узган атнада кабаттан да халыкара игътибар үзәгенә чыкты. Алмания канцлеры О.Шольц Кытайга рәсми сәфәре вакытында Украина тирәсендәге хәлләргә дә тукталган. Кытай лидеры Си Цзиньпин исә анда атом-төш коралын куллануга юл куярга ярамавы турында әйткән. Аерым сәяси экспертлар бүген инде моны Кытай-Россия бәйләнешләрындагы борылыш булачак та бәяли. О.Шольц исә атом-төш коралын куллану мөмкинлеген «үтеп чыгарга ярамаган сызык», дип саный (бу хакта ул узган атнада партия съездында әйткән). Әлеге мәсьәлә һәм Шольцның Кытайга кылган сәфәре АКШ лидеры Джо Байден белән телефоннан сөйләшкәндә дә игътибар үзәгендә булган. Алар анда Украинага икътисади, гуманитар һәм хәрби ярдәмне бергәләп күрсәтергә килешкәннәр.

Ә бөекдержавачылык сөременнән айну отыры Мәскәүгә дә килә кебек. Россия тышкы эшләр министрлыгы узган атнада инде: «...первоочередной задачей становится недопущение любого военного столкновения ядерных держав», – дип белдергән. Мәскәүнең Украинаны «пычрак бомба» әзерләүдә гаепләве дә (мәсьәлә хәтта БМО КШ дәрәҗәсендә куелды) дөрес булып чыкмаган: МАГАТЭ экспертлары бу илдә законсыз атом-төш эшчәнлеген тапмаган. Бүген инде Россия Киевне ничек булса да сөйләшүләр өстәле янына утырту нияте белән яна. Бу җәһәттән игътибарны АКШ президентының дәүләт иминлеге буенча ярдәмчесе Джейк Салливанның узган җомгада Киевкә ясаган сәфәре һәм анда Украина Президенты В.Зеленский, аның офис башлыгы А.Ермак, саклану министры А.Резников һ.б. белән очрашуы җәлеп итә. Матбугатта Киевне сөйләшүләргә кыстаган мәкаләләрнең ешаюы да шул хакта сөйли. Әйтик, Washington Post Киевне Россиягә карата ачыклык күрсәтергә һәм тыныч сөйләшүләрдән баш тартмаска чакыра. Киев тә каршы түгел кебек. Әмма ул куйган шартлар Мәскәүне канәгатьләндерми.

Фоат УРАЗАЙ.

«Йөрәгемнең

Татарстанның халык артисты Нәфкать Нигъмәтуллинның 60 яшьлек юбилее уңаеннан уйланулар

... Ник син бигрәк моңлы бала, дисез,
Гомерем җилләр кебек искәнгә.
Яшьлегемдә калган сандугачым
Исләремә килеп төшкәнгә...
Илдар ЮЗЕЕВ.

Әллә бик гади булгангамы, әллә тормыш иптәшем Роза белән бер үк Байгуҗа мәктәбендә укыгангамы, икесе дә ятимлек җилләрен бик яшьли татыгангамы, иркенләп, ачылып сөйләшкәнгәме, Нәфкать миңа туганым кебек якын.

«Язмыш бит ул кәләш түгел...» – тирән мәгънәле бу сүзләрне татар Корчагины, Татарстанның халык шагыйре Фәнис ага Яруллин язып калдырган. Нәфкать туганның да язмышы йомшак җәймә түгел. Бер уйлаганда, балачак – гомернең иң татлы, иң кайгысыз мәле кебек. Әмма бу фани дөнья Нәфкатькә үзенең ачы хәсрәтләрен бик иртә татырга мәҗбүр итә, тормыш сынауларын мул итеп бирә. Чыныктыру өчендер инде. Башкортстанның Яңавыл районы Уракай авылында Тимергали һәм Хәтирә Нигъмәтуллиннарның ишле гаиләсендә җиденче бала булып дөньяга килә ул. Һәм сабый чактан ук әнисез торып кала. Кайнар күз яшьләре, йөрәктән мәңге китмәс ачы сагыш, хәсрәт-әрнүләр, төзәлмәс яра бала күңелендә җыр-моңга әверелми ничек түзсен?! Җыр-моңның ачык яраларны да дәвалый алуын, сагышлы күңелгә ял бирүен Нәфкать бәләкәйдән үк тоемлагандыр...

Мәктәп елларында ук Нәфкатькә мөстәкыйль яшәргә өйрәнергә туры килә. Башта якындагы Байгуҗа сигезьеллык мәктәбендә, 7-8 классларны Уфаның Черниковка бистәсендәге 2 нче интернат-мәктәптә укый. Бу еллар яшүсмернең күңелендә бик нык уелып кала, Нәфкать өчен зур имтихан була. Күп балалы әниләрнең сабыйларының хәлен белергә килгәч, аларны аркаларыннан сөйгән чакларын үз күзләре белән күрде бит. Шул мизгелләрдә аның да: «Апакаем, мине дә бер ярат әле», – диясе килгәндер дә бит... Нишләргә соң? Юксынып, көтеп, тәрәзәдән-тәрәзәләргә йөрсәң дә, әнкәй кайтмый шул.

Хәтирә апаның уңган, булдыклы, кешелекле, ярдәмчел, шәфкатьле булуын кайберәүләр бүген дә ихлас искә ала. Тимергали абый Гайфә апага өйләнгәч, бер баланы да читкә итми. Ул да, гаепсез сабыйларның хәлен аңлап, аларга мөмкин кадәр күңел җылысын өләшергә, рәхәтләнеп сөйләшергә, хәлләренә керергә тырыша. Бер уйласаң, бәла бер ялгызы гына йөрми. Нәфкатьнең туганнары Равия сабый чакта ук, Нәзхәт – 7, Мизхәт – 18 яшендә үлә, Себердә гомер иткән Галинур, шулай ук Асия апасының кияве дә иртә мәрхүм була. Болар һәммәсе – күңелләрдән китмәс, күз яшьләре кипмәс кара кайгы...

Ә гомер дәвам итә. Нәфкатькә үз вакытында солдат боткасын да ашарга туры килә. Соңрак, Нефтекама шәһәрендә бераз эшләп ала. Шулай, бер көнне үл этисенә сүз ката: «Әти, нишләптер монда минем күңелем тартмый, Казанга барасым килә». Әти кеше: «Үзең беләсеңдер, балам, язмыш болай да каккалады, суккалады, тормышыңны үзең теләгән җирдә корырсың инде», – дип фатихасын бирә.

Шулай итеп, Нәфкать 1974 елда Казан тарафларына юл тота. Авыл тормышына бирелеп, табигатенә сокланып үскән егет читтән торып авыл хуҗалыгы институтына укырга керә. Гыйльми-тикшеренү институтында эшләгәндә, ул мондагы оешып кына килгән вокаль ансамбльдә җырлый башлый.

Репетицияләр вакытында ук Н.Нигъмәтуллинның моңлы тавышы күпләрне әсир итә. Үзешчәннәр белән концертларда чыгыш ясаганда, кат-кат сәхнәгә чакырып җырлатуларын әле дә онытмый ул. Әнә шул дәррәү алкышлар, дусларның изге киңәшләре җыр-моңга чорналган Нәфкатькә тынгылык бирми. Тумыштан булган сәләт тә бар бит әле. Ни булса да тәвәккәлләп, ул, ниһаять, сәнгать сукмагыннан атларга карар итә. Урау-урау юллардан соң, 80 нче еллар азагында, Нәфкать Казан музыка училищесының Рәйсә Нуриева классында белем ала. Бер үк вакытта ул «Ялкын», «Якты елга» ансамбльләрендә актив чыгыш ясый.

Аулак өйләрдә, каз өмәләрендә, концертларда катнашып үскән егет җырлы юлны сайлап ялгышмый. Ә инде 1995 елда аның «Җырым синең хакта» исемле аудиоальбомының дөнья күрүе яшь җырчыга ен ялагач кына, Нәфкать үзенең урыны фәкать сәхнә түрендә икәнлегенә инана.

Башкортстандагы һәм Татарстандагы сәхнә сандугачларының кабатланмас моңлы тавышлары балачактан ук Нәфкатьнең күңел түрендә урын алгандыр. Үзенең кумирлары булган мәшһүр җырчылар: Фәридә Кудашева, Илфак Смаков, Әлфия Авзалова, Илһам Шакиров, Фидан Гафаров, әлбәттә, данлыклы районыдашы, замынында Советлар Союзының эстрадасында якты йолдыз булып кабынган, 32 яшендә (!) РСФСРның халык артисты исеменә лаек булган (башка җырчы бармы икән?!),

бик яшьли гомере өзелгән Радик Гәрәевне һәм башкаларны остазлары, сәнгать сукмагын яктыртучы маяклар дип саный ул. Остазлары башкарган үлемсез җырларны тыңлаган, күңеленә салып барган Нәфкать Нигъмәтуллин аларны үз репертуарына кертергә җөрьәт итә. «Истә, һаман да истә», «Җиз кыңгырау моңнары», «Онытәле мәшәкатьләреңне», «Арча юлы», «Син – гомер агышларым», «Тыңлачы, сандугач», «Озак торды, атым чапмады», «Ат эчерәм елгада», «Җан ярасы алмагыз» һәм башка бик күп җырларны атарга мөмтанылу алып килә. Соңрак» «Синең кулда язмышым», «Уралдым моңнарыңа», «Үзем белгән юл белән», «Күзгә моң», «Минем җырым», «Авылым каеннары», «Тип йөрәгем» һәм башка аудио-видеотасмалар җыр сөючеләрнең аерылмас юлдашына әверелә.

«Мин җырларым белән бәхетле» – бу сүзләр Татарстанның халык артисты Нәфкать Нигъмәтуллинның халәтенә һичшиксез туры киләдер. Елларны куып еллар үткәч, тәгәрмәчләрдә меңәр-меңәр чакрым юллар узгач, тамашачыларның чын сөю-

сагышларын...»

кин. Һичшиксез, алар арасында халык җырлары да шактый урын алган.

Әлбәттә, Нәфкатьнең иҗаты, уңышлары хакында язганда, аның иҗатташ дуслары хакында берничә сүз әйтмәү дөрес булмас. Уңышлы эшләү, концертларны төгәл оештыру, билгеле, төркемнең җитәкчесе Рәмзия Сәләхованың (Нәфкатьнең тормыш иптәше) күптәнге сәләтенә, тәҗрибәсенә бәйледер. Бер юнәлештә, бер дулкында 26 ел эшләү, әлбәттә, үз җимешләрен бирми калмагандыр. Шуңа да Нәфкать: «Рәмзия – минем уң кулым да, сул кулым да, гаиләм учагын җылытучы да», – ди.

Күбәләктәй очып биюче Резеда Ганиуллина, Рәмил Гыйләҗетдинов, Гайсә Маликов, Альбина Әбүзарованы исә, коллективның матур бизәкләре дисәк тә

һич арттыру түгел. Сәхнәне музыкаль яктан бизәүче талантлы егетләр шулай ук күркәм иҗади атмосфера тудыралар.

Ә менә егерме биш елдан артык сәхнәдә бергә хезмәт куйган, консерватория белеменә ия тыйнак артист – Ирек Галиев хакында аерым әйтәсе килә. Үзе татарча, русча, итальянча җырлый, гитарада, курайда уйный, кирәк икән, тамашачылар янына төшеп, биеп тә җибәрә. Өстәвенә, көйләр дә яза. Мондый талантны универсал кеше димичә, нәрсә дисең?! Коллективка хыянәт итмичә, сабыр итеп, халыкка үзенең сәләтен уңышлы күрсәтә икән, аңа «атказанган» исемен дә күптән бирергә вакыттыр. Кызганыч, гадәттә, бездә талантлылар шәүлә астында кала бирә, ә сәхнә «бакчасы»н тигәнәккә батыручы әрсезләр, халык җырларын да башкармаган бер көнлек җырлары белән хәтта «халык артисты» исеменә «лаек» булалар. Ә моны халык күптән сизеп, күзәтеп килә дә бит. Җырчылар түгел, андый җырлаучылар халкыбызның бүгенге исән, тыйнак талантлары: Фидан Гафаров, Нурия Ирсаева, Идрис Газиев, Айдар Фәйзрахманов, Фәдис Ганиев, Рөстәм Асаев, Филүс Каһиров, әлбәттә, Нәфкать Нигъмәтуллин кебек сәхнә йолдызларыннан төрле яклап үрнәк алсын иде. Инде 30 ел татар-башкорт сәхнәсен шаулаткан Нәфкать Нигъмәтуллинга «Башкортстанның халык артисты» дигән исем бирелсә дә, һич артык булмастыр...

Газиз җирен, туган-үскән йортын ерак сәфәрләрдән бик тә сагынып кайта Нәфкать. Тәрәзәләрдә утлар сүнгән инде. Кайчандыр әнкәсе йөргән сукмакларны да үлән баскан. Берүзе генә калган чакларда – моңсу мизгелләрдә Нәфкатьнең миен нинди генә уйлар борауламады икән?! Бәлки, ишек тоткаларын сак кына тотып, куллары белән тәрәзә капкачларын сыпырып, газиз әткәй-әнкәй йортын бер урап чыккач, зиратка, изге чишмәгә барып, аның шифалы суларын эчкәч, тәгәрәп ятып, бер туйганчы «балавыз сыккандыр». Әй, ничек кенә сагындыра, юксындыра бит ул туган йорт...

Шулай, тирән уйларга бирелеп йөргәч, бермәл Нәфкатьнең әнкәсенә багышлап клип төшерү турында хыяллана. Уй-хыяллар озак көттерми һәм ул тиз арада тормышка аша. Ул үз авылының искиткеч матур табигать кочагында – челтерәп аккан чишмә, елга буйларында, күпердә гомер акканын уйлап торган чакларны, зиратта булган мизгелләрне, әлбәттә, туган йорт янындагы истәлекле моментларны үз эченә алган. Һәм туган авыл киңлекләренә сыеша алмыйча кабатланмас җыр-моң агыла:

Еракларга киттем, сине үксез
иттем,
Ничә еллар ялгыз интектең.
Шул кадәр көткәч, улың
кайтып җиткәч,
Бәхилләшми, әнкәй, ник киттең?..

Бәгырьләрне телгәләгән, җаннарны өшеткән чаклар була шул тормышта. Билгеле, ул йөрәкләрне тетрәткән мизгелләр Нәфкатьнең «Җан ярасы алмагыз» (Резеда Вәлиева сүзләре, Марсель Иванов көе) җырында да ачык чагылыш таба:

Кайталмадым әнкәй, көткән чагыңда,
Кайталмадым, ачы сагыш җанымда...

Хәер, әткәй-әнкәйләрнең якты рухы җырларында гына түгел, тора-бара башка күркәм, изге эшләрендә дә чагыла. Нәфкать әүвәл туган йортын үзе теләгәнчә, матур итеп яңарта. Ә эти-әнисенең каберләре гөл-бакча булып утыра. Бертуганнарының каберләренә дә зур игътибар бирә – һәрберсенең каберенә мәрмәр таш куйдырган. Үги энисе Гайфә апаны да онытмаган. Ишектән кайтып керү белән ул аңа: «Әнкәй, исәнме!» – дигән ич. Хәтта Галинур абыйсы каберенә куярга дип тә, таш ясаткан икән. Ни үкенеч, Түбән тикле Төмәнгә баргач, аның каберен табмый кайткан.

Кайчандыр әнкәсе Хәтирә апа балаларына су алып кайткан чишмәне искиткеч зәвык белән, матур итеп төзекләндерүгә дә зур өлеш керткән Нәфкать. Авыл халкы аңа «Хәтирә чишмәсе» исемен бирүне ихлас хуплаган. Хәзер авылның челтерәп аккан, улаклы, заманча чишмәгә бизәкле плитә сукмаклар буйлап кына барасы.

Яңавыллылар үзләре дә ихлас күңелле! Райондашлары да җырчыга кадер-хөрмәт күрсәтеп тора. Югыйсә Н.Нигъмәтуллинга «Яңавыл районының шәрәфле гражданины» дигән дәрәҗәле исем бирелер идеме?! Үз чиратында халык артисты да якташларын җавапсыз калдырганы, әтисе Тимергали абыйның да әманәтен истән чыгарганы юк. Мәчетләргә, зиратларга, ятимнәргә мөмкин кадәр ярдәм итүне, сабантуйларга да үз өлешен кертүне, спонсорлык эшләрендә катнашуны күз уңыннан чыгармый ул. Аның якыннары: «Безнең Нәфкать бик юмарт, ярдәмчел, үзенә булмаса да, әмма мохтаҗларга өлеш чыгара», – диләр. Озакламый бик истәлекле, күркәм чара – ноябрь урталарында Нәфкать Нигъмәтуллинның туган ягы – Яңавыл шәһәрендә райондашлары аның матур юбилеен зурлап үткәрергә җыеналар. Ике тугандаш республика халыкларының да тыйнак, сөекле җырчысы, моңлы сандугачы моңа бик тә лаек!

Әнвәр СӨЛӘЙМАНОВ.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

12 ноябрь (шимбә). ***Рабигүл ахир аенең 18 нче көне. 19 нчы Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 17.29 сәгатьтә калка, 12.42 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 8.30 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Күп аралашмаска, күз тиюдән, чит тәэсирләрдән сакланырга кирәк. Бурычка алырга да, бирергә дә ярамый. Нерв системасы, эчәклек, арканың өске өлеше зәгыйфь.

Керәнле лимон

Хроник бронхит булганда, болай дәвалану файдалы. Керән тамырын чирек стакан ваклап, 2 лимон согын кушалар һәм суыткычта саклыйлар. Иртән һәм кичен яртышар чәй кашыгы кабалар, 30-40 минут үтмичә, су эчәргә ярамый.

13 ноябрь (якшәмбе). ***Рабигүл ахир аенең 19 нчы көне. 20 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 18.28 сәгатьтә калка, 13.14 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 8.26 сәгать.***

Үз-үзеңне танып-белү, уйлану, кичерү көне. Өйдә булырга тырышырга, гаиләгә игътибарны арттырырга кирәк. Тәкәбберлек күрсәтергә ярамый. Яңа белем җиңел үзләштерелә. Нерв системасы, сизү әгъзалары, кан тамырлары, ашказаны зәгыйфь.

Шифалы май

Тын кысканда, склероз булганда, баш мие тамырлары кысылганда, сарымсаклы май булыша. 1 баш сарымсакны чистартып, боткасыман хәлгә килгәнче төяләр, өстенә 1 стакан көнбагыш мае салып, суыткычта саклыйлар. Көненә 1 тапкыр 1чәй кашыгы сарымсак маен шулкадәр үк лимон согына кушып эчәләр. Дәва курсы – 1-3 ай, аннан соң 1 ай туктап торырга кирәк.

14 ноябрь (дүшәмбе). ***Рабигүл ахир аенең 20 нче көне. 21 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 19.40 сәгатьтә калка, 13.34 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 8.22 сәгать.***

Сәяхәткә чыгу, теләсә нинди эш башлау өчен айның иң кулай көне. Кеше хәлиткеч карарлар кабул итәргә сәләтле. Физик эш белән шөгыльләнү, җәяү йөрү, чыныгу файдалы. Саф һавада күбрәк булу, табигать белән хозурлану кәефне күтәрә. Умырткалыкның аскы өлеше, әвернә сөяк, аяк зәгыйфь.

15 ноябрь (сишәмбе). ***Рабигүл ахир аенең 21 нче көне. 22 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 20.57 сәгатьтә калка, 13.49 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 8.19 сәгать.***

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

Грипптан дәва (1)

Сарымсак ашау файдалы. Изеп, шулкадәр үк бал кушалар, йокларга ятар алдыннан 1 аш кашыгы кабып, артыннан җылы су эчәләр. Яисә 100-200 мл кайнар сөткә 1 чәй кашыгы изелгән сарымсак салып, өстен ябып, 20-30 минут төнәтәләр

(Дәвамы 18 нче биттә).

Мәдәни җомга
11 ноябрь
№44, 2022

Айга карама

һәм берьюлы эчеп бетерәләр. Кара карлыганны изеп, җылы суга салалар да, көн буена шуны әз-әзләп эчәләр. Һәр көнне төшке аш вакытында 1 аш кашыгы вак кына туралган баш суганны каймакка кушып ашау файдалы. Суганны урталай кисеп, исен борын һәм авыз белән иснәү дә нәтиҗәле.

16 ноябрь (чәршәмбе). ***Рабигүл ахир аеның 22 нче көне. 23 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 22.16 сәгатьтә калка, 13.59 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 8.15 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

Гripptан дәва (2)

200 мл кайнап торган сөткә 2 аш кашыгы суган боламыгы салып болгаталар, 20 минут төнәтәләр һәм йоклар алдыннан эчәләр. Яисә 1 аш кашыгы артыш җиләген 400 мл суда 20 минут пешерәләр, ашарга 15-20 минут кала 1 әр аш кашыгы эчәләр. Яки нарат ылысын ваклап, кайнатып суытылган 600 мл суга салалар, 2 тәүлек төнәтәләр, сөзәләр, 2 тәүлектә әкренләп эчеп бетерәләр. Бер чеметем лимон кислотасы яки аз гына мүк җиләге согы кушып тәмләтергә ярый, шикәр йә бал өстәргә дә була. Мондый эчемлекне ел әйләнәсе эчәргә рөхсәт ителә, кышын аеруча С витамины җәйгедән күбрәк.

17 ноябрь (пәнҗешәмбе). ***Рабигүл ахир аеның 23 нче көне. 23 нче Ай тәүлегенең дәвамы. Ай Кыз йолдызлыгында, 23.35 сәгатьтә калка, 14.07 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 8.11 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

Кан тамырларын чистарту

Термоска 1 стакан укроп орлыгы, 1-2 аш кашыгы валериан тамыры салып, өстенә 1 литр кайнар су коялар, 1 тәүлек төнәтәләр. Сөзеп, 1 стакан бал кушалар. Яхшылап болгатып, суыткычта саклыйлар. Көненә 3 тапкыр, ашарга ярты сәгать кала, 1 әр аш кашыгы эчәләр.

18 ноябрь (җомга). ***Рабигүл ахир аеның 24 нче көне. 24 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 14.11 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 8.08 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

Кабак катламасы

4 йомыркадан пилмән камыры басалар. Алтыга бүлеп, түгәрәкләп җәяләр. Уртача зурлыктагы кабакны чистартып, эре угычтан уалар, 1-2 баш суганны вак кына турыйлар, икесен бергә кушып, тоз, борыч өстиләр. Камыр өстенә тигезләп җәеп, өстенә атланмай уалар, рулет ясап төрәләр. Мантый пешерә торган түгәрәкләргә куеп, өстен майлыйлар һәм 45-50 минут буе парда пешерәләр. Табынга укроплы каймак белән бирәләр.

«Шаян чәкән» кыйсасы

1950 нче елларда Н.С.Хрущев инициативасы белән илдә башланган кукуруз эпопеясы әле дә дәвам итә. Элек аны «басулар патшабикәсе» – «королева полей» дип йөрттеләр. Татарстанда бу культура шактый мәйданнарда игелә. Яшел массасы терлек азыгы буларак киң кулланыла, ә тиз өлгерә торган сортларының чәкәннәреннән бөртекле кукуруз алына. Кукуруз азык-төлек сәнәгатендә төрле ризыклар, эчемлекләр әзерләгәндә файдаланыла.

1970 нче елларда Казан сыра заводы махсус технология белән кукуруз чимадын кулланып, алкогольсез газлы эчемлек эшләп чыгарды. Завод технологлары бу яңа эчемлекнең сыйфатлы һәм ләззәтле булуына ирешә, аны күпләп чыгару җайга салынды. Продукция шампан хәмере салына торган шешәләргә тутырылып, нык бөке белән ябыла иде. Сәүдәгә чыгару өчен аңа исем кушарга кирәк. Завод җитәкчеләре эчемлекне татарча атарга ниятли, тик кулланучыга ошарлык исем таба алмыйлар. Бер акыллысы тәкъдим итә: «Әйдәгез Татарстан китап нәшриятына мөрәҗәгать итик, бәлки язучылар ярдәм итәр?» Ике хезмәткәр бер тартма эчемлек шешәләрен алып, Бауман урамындагы Матбугат йортына килә. Нәшрият директоры Гарәф ага Шәрәфетдинов аларны кадрлар бүлеге җитәкчесе Гөлшат Зәйнашева янына җибәрә, ул ярдәм итәр, ди. Гозерне игътибар белән тыңлагач, Гөлшат апа мәсьәләне үзе хәл итәргә була. «Шешәне ачып күрсәтегез әле!» Тыгыз бөкедән арындырып шешәне ачу белән, эчемлек ургылып бәреп чыга, ярый әле завод хезмәткәре аны кулындагы бокалга юнәлтә.

Гөлшат апа берничә минут уйлана, ә кунаклар аның күзенә карап, сүзен көтә. Шагыйрә бу гаҗәеп яңа эчемлекне «Шаян чәкән» дип атарга киңәш итә. Бу матур, эчтәлекле исем завод хезмәткәрләренә ошый, алар бик канәгать булып, эчемлекләрен нәшрият коллективына бүләк итеп китәләр. Сусаганны баса торган, газлы, тәмле бу эчемлекне завод

берничә ел дәвамында 100 мең декалитр эшләп чыгарган. Сәүдә оешмалары аны җәйнең эссе айларында бик теләп кабул иткән, чөнки ул бик тиз сатылып беткән. Шәхсән мин үзем «Шаян чәкән» тарихын Гөлшат апа сөйләвеннән беләм һәм газета укучыларына да җиткерәсем килде. Ул популяр эчемлекнең тәме, ләззәте һаман истә, бәясе дә кыйммәт булмагач, без аны ярата идек.

Сүз уңаеннан, нәселебезнең «йөзек кашы», татар халкы мәхәббәте һәм Тукай премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, мәшһүр язучы Гөлшат апабыз Зәйнашеваның гаҗәеп образлы фикер иясе булуын әйтим әле.

Күренекле шәхесләр, төрле вәзгыять, туган илгә мәхәббәт, һ.б. аңлаешлы, үтемле тасвирлау, эчтәлеген тулырак ачыклау максатыннан, шагыйрә оригиналь, күркәм атамалар уйлап таба, аларны әсәрләрендә, иҗатында уңышлы куллана иде. Мәсәлән, мәшһүр композитор Сара Садыйкованы ул «калфаклы сандугач» дип атады, олылады. «Кояш гомере» (җыр), «Бәхет кошым» (пьеса), «гөләни» (әби), «Ясалма мыек» (җыр), «гөлбакча», «китмә, сандугач» (патриотизмны белдерә) һ.б. күп терминнар авторы ул Гөлшат Зәйнашева. «Шаян чәкән» заманы тарихта калып, инде күп еллар үткәч, бу гыйбрәтле кыйсса исемә төште. Хакимиятнең бүгенге сәясәте дә моңа сәбәпче булды, күрәмсең... Хәзер чит илләрдән кертелә торган продукцияне үзебездә җитештерү (импортозамещение) бурычы куелды. Төрле эчемлекләр эшләп чыгаручы фирмалар Татарстанда шактый. «Шаян чәкән»не яңадан чыгаручы табылмасмы? Аңа ихтыяҗ күп булачагына иманым камил! Җөмһүриятебезгә, бигрәк тә Казанга миллионнарча туристлар агыла, аларны һәм халкыбызны «Шаян чәкән» эчемлеге белән сыйласак, безнең абруй тагын да артачак бит!

Марс ГАИТОВ,
хезмәт ветераны.

Тамаша заллары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

12 ноябрь – 14.00, 18.00 – Слава Полунинның Кар шоуы. 15.00 – Шәрык клубында балалар өчен рәсем дәресе.
13, 14 ноябрь – Слава Полунинның Кар шоуы.
16 ноябрь – «Казан» бию ансамбленең «Зәңгәр шәл» дип исемләнгән концерт программасы.
17 ноябрь – «Казан» бию ансамбленең «Ефәк юл» дип исемләнгән концерт программасы.
18 ноябрь – «Әтәч менгән читәнгә» (А.Гыйләҗев).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

11,12 ноябрь – «Царская невеста» (Н.Римский-Корсаков).
16 ноябрь – «Борис Годунов» (М.Мусоргский).
18 ноябрь – «Алтын Урда» (Р.Ахиярова).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

12 ноябрь – «Гомер буе сине көтәм» (И.Гали).
13 ноябрь – «Назлы кияү» (К.Тинчурин).
15 ноябрь – «Ядәч! Исемдә! Бер гаилә трагикомедиясе» (Й.Миңнуллина, М.Гафурова, А.Бикбулатов, Э.Дусаева).
16 ноябрь – «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» (Т.Миңнуллин).
17 ноябрь – «Туй алдыннан» (Х.Вахит).
18 ноябрь – «Алай түгел, болай ул» (Т.Миңнуллин).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

12 ноябрь – «Мәхәббәт күгәрченнәре» (В.Гуркин).
13 ноябрь – «Матур City» (А.Әхмәтгалиева).
15 ноябрь – «Алтынч[ае]ч» (Л.Янсуар, Р.Гарипова).
16 ноябрь – «Кәҗүл читек» (Г.Исхакый).
17 ноябрь – «Ромео һәм Джульетта» (В.Шекспир).
18 ноябрь – «Супер кияү» (Т.Миңнуллин).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

12 ноябрь – Зур залда – «Аленький цветочек» (С.Аксаков). Кече залда – «Мактанчык әтәч» (Аманулла).
13 ноябрь – Фойеда – «Бобровый пруд», Зур залда – «Сказки Маршака» (С.Маршак), кече залда – «Серая шейка» (Д.Н.Мамин-Сибиряк әсәренә нигезләнеп куелган).
16 ноябрь – «Серая шейка» (Д.Н.Мамин-Сибиряк әсәренә нигезләнеп куелган).
17 ноябрь – «Аленький цветочек» (С.Аксаков).
18 ноябрь – «Дитя Аллаха» (Н.Гумилев).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

13 ноябрь – 11.00 – Балалар өчен «Йөз мең төрле аваз, термин һәм жанр» дип исемләнгән концерт. 17.00 – «Необарды» дип исемләнгән авторлар җырлары концерты.
14 ноябрь – «Черный квадрат» квартеты концерты.
16 ноябрь – Иван Бессонов башкаруында классик музыка яңгыраячак.
17 ноябрь – Татарстан Республикасы халык музыка уен кораллары оркестры һәм М.Щербицкийның «Поверь в мечту!» дип исемләнгән концерты.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

12 ноябрь – «Санкт-Петербург опера» театры солистлары, Санкт-Петербург шәһәре хакимиятенең мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә премиясе лауреаты җырчы Ярамир Низаметдинов концерты. Кичәдә Татарстанның халык артисты Фердинанд Сәлахов катнаша.
13,14 ноябрь – «Виртуозы Москвы» оркестры концерты. Дирижер – Владимир Спиваков.
16 ноябрь – С.Гобәйдуллина исемендәге «Concordia» халыкара заманча музыка фестивале кысаларында Татарстан Республикасының А.Сладковский җитәкчелегендәге симфоник оркестры концерты. Дирижер – Ф.Чижевский, Солист – Е.Ревич (скрипка).

Якты моң

Әсәрләре, тормыштагы кызыклы һәм гыйбрәтле гамәлләре, әйткән сүзләре белән һич онытылмый торган шагыйрьләрнең берсе – Мәхмүт Хөсәен. Ә аның шигырь сөйләве үзе бер музыка! Чөнки ул бервакытта да шигырен кәгазьгә карап укымый, бөтен хис-кичерешләрен кушып, йөрәгә аша уздырып сөйли иде. Аны тыңлаганда, үзең дә шигъри сүз тәэсирендә буласың, бу көч сине үз ихтыярына буйсындыра. Бу инде – сәнгать, сүз сәнгате. Мәхмүт абыйны юкка гына артистлар үзләренең концертларын алып барырга чакырмагандыр. Андый чыгышларының берсе Казаныбызның опера һәм балет театрында булган иде. Кәләпүшен киеп, җитез-җитез атлап сәхнәгә килеп чыгуы ук тамашачыларның игътибарын яулап алды, зал белән икесе арасында урнашкан җылы мөнәсәбәт кичәнең буеннан-буена дәвам итте. Моның өчен үзенә бер сәләт, тарту көче кирәк. М.Хөсәен шундый тәэсир итү мөмкинлекләренә ия зат иде шул.

Күп кенә шагыйрьләр бик матур, төзек, мәгънәле әсәрләр тудыра алса да, шул язганнарын халык күңеленә керерлек итеп укый белми. Еш кына бөтенләй дә укый алмыйлар. Нинди генә әсәр булмасын, аларны сәер бер табигый булмаган рәвештә укучы өстенә аударалар. Кирәкмәгәнгә акланмаган пафоска биреләләр, шуның белән язганнарының укучы күңеленә барып җитүенә комачаулык итәләр. Моны «шагыйрьләрчә уку» дип әйтү дә кабул ителгән. М.Хөсәен исә сәнгатьле уку остасы иде. Андагы мондый көчне миңа бөтенләй башка шартларда күрергә туры килде.

1990 елның октябрь аенда без аның белән Кырым Күктүбәсендә иҗат йортында булдык. Безнең белән Мәгъсүм Насыйбуллин, Габдулла Шәрәфетдинов та бар иде. Төшке аштан соң һәрберебез үз бүлмәсенә бикләнә, укып-язып утыра.

Шул вакыт бинага бер егет килеп керде.

– Абзыйлар, сезнең ярдәм кирәк! – дип безне фани дөньяга кайтарды.

Чыннан да, безнең әле бу егетне беренче күрүебез, кем ул, ни булган, кемгә нинди ярдәм кирәк? Берни дә аңламыйбыз. Егет сөйләп бирде.

– Минем исемем Мостафа. Моннан утыз-кырык чакрымда, Судак шәһәре янындагы «Розалар үзәнлеге» дип йөртелә торган урында, Үзбәкстаннан кайтып, без, җитмешләп татар егете, рөхсәт сорап тормыйча гына, авыл торгыза башладык. Мөрәҗәгать итсәк тә риза булмаслар иде. Авылыбызга «Асрет» дип исем куштык, «Сагыш» дигән сүз ул. Бүген иртән җирле хакимият вәкилләре төзегән йортларыгызны сүтегез, юкса көч кулланылачак, дип кисәтеп китте. Аларның төнлә килүе ихтимал. Без, яшьләр, алар белән җитди итеп сөйләшә алмыйбыз. Кызып китеп, балта-көрәккә тотынуыбыз бар. Сез олы кешеләр, җитмәсә язучылар да, безнең кардәшләребез, үз акылыгыз белән безне ярдәмегездән ташламассыз, дип, мине монда җибәрделәр. Машина белән сезне алырга килдем.

Иң беренче булып Мәхмүт абый кузгалды.

– Мин барам! – диде ул.

Аңа Мәгъсүм абый кушылды.

– Без Габдулла белән икебез дә фронтовиклар. Майор Мәхмүт Хөсәеновтан нигә калышып торыйк! Фоат исә фронтовик малае. Ул да каршы килмәс!

Без Мостафаның машинасына чыгып утырдык. Егетләр безне шатланып каршы алды. Түгәрәкләнеп чәй эчтек, мондагы хәлләр белән таныштык. Кичке якта егетләр белән әдәби кичә уздырдык.

Кичләтеп кенә көтелгән «кунаклар» да килде. Җитәкчеләре әйтә:

– Хәзер үк төзелеш мәйданыгызны бушатыгыз. Хәзер биредә чистарту эшен башлап җибәрәбез.

Шул вакыт палаткадан күкрәгенә орден-медальләрен таккан (иҗат йортына да алып килгән!) Мәхмүт абый, шулай ук җитди кыяфәтле Мәгъсүм һәм Габдулла абыйлар чыгып басты. Минем дә күкрәктә Казанның Бауман районы депутаты билгесе бар. Килүчеләр аптырап калды. Мәгъсүм абыйның сүзләре аларның аңына тагын да ачыграк барып җитте.

– Мин – прокурор. Мондый эшләр болай хәл ителми. Иртәгә көн бар, бергәләп район үзәге Судакка барырбыз, сөйләшербез. Хәзергә таралышырга тәкъдим итәбез.

Судакка барырга туры килмәде. Иртәгесен бу урынга җирле хакимият җитәкчеләре, хокук органнары вәкилләре килде. Алар белән сөйләшүне безнең яктан нигездә Мәгъсүм абый алып барды. Нәтиҗәдә болай килештеләр: егетләр ни өчен нәкъ менә биредә авыл салырга теләгәннәрен дәлилләп, югары оешмаларга хат яза, тегеләр, рәсми җавап алынганчы, төзелешкә тими. Хатны, әлбәттә, Мәгъсүм Насыйбуллин үзе язып бирде.

Ходай рәхмәте, хатның файдасы тидеме, әллә бүтән сәбәпме, боларга бүтән дәгъва белдерүче булмады. Берничә елдан соң Кырымга баргач, кызыксынып, бу авылга да сугылдым, аларның матур гына яшәп ятуларын күреп куандым.

Габдулла абый моңа үзенчә аңлатма бирде:

– Мөгаен, Мәхмүтнең түбәтәен күреп шүрләгәннәрдер, бер дә бүтән булмас.

Әйе, Мәхмүт абый Хөсәенне түбәтәйсез күз алдына китереп булмый, бу очракта да аның әлеге аерылмас юлдашы үзе белән иде. Бу урында Рафис Корбанның аңа карата язган эпиграммасы искә төшә:

Сәхнәләрдән чыгыш ясый,
Орден-медаль тулы түше.
Гомум мәгълүм, шагыйрь итте
Башындагы кәләпүше.

Шушы юллар исемә төшсә, күз алдыма Мәхмүт абыйның әлеге «Розалар үзәнлеге»ндәге чыгышы гәүдәләнә. Хәер, аның тормышында мондый егетлекләр күп булды.

Әлеге сыйфатының бер сәхифәсе Хәсән Туфан белән бәйле. Билгеле булганча, Х.Туфан «тегеннән» 1956 елда кайта. Бер мәҗлестә М.Хөсәен шагыйрьнең үз авызыннан тоткынлыкта язган шигырьләрен тыңлый, аларны иркенлеккә чыккан язгы карлыгачларга охшатуын әйтә. Бу «карлыгач»ларны мондый тар даирәдә генә тотмыйча, тизрәк китап укучылар тарафына да очыртырга кирәклеген аңлата. Нәшрият планына кертелмәгән булса да, комачау итүче җитмәләрне әйләнеп, аны шактый тиз вакыт эчендә чыгару юлларын таба. Мондый башбаштаклык өчен М.Хөсәенгә шелтә эләгә. Ләкин әдәбият хакына эшләнгән мондый егетлек өчен бирелгән шелтә нәрсә ул? Киресенчә, аны теләсә нинди мактау сүзләреннән дә кадерлерәк дип санарга мөмкин. Х.Туфан шушы китапның берсен, автограф язып, М. Хөсәенгә бүләк итә. *«Мәхмүт! Исәндәдер, син әйткән «карлыгач» язны көткән икән. Бу сиңа шуның истәлеге. Х.Туфан. 20.04.1958».*

Әлеге китапны М.Хөсәен тузан кундырмыйча, кадерләп саклады. Андагы һәр шигырь аның күңелендә, аның ихтыярыннан башка аңында яши. Менә шулдыр инде ул шигъри осталык, күңелләрдә яшәргә дәгъва итәрлек әсәрләр тудыру маһирлеге!

Шуннан соң ул үзенең иҗатына да башкача таләпләр куя башлый. Аның шигырь буларак бәяләнә башлавы илленче еллар ахырына туры килүе очраклылык түгел. Ул Х.Туфан, С.Хәким, Ш.Маннур, С.Баттал, Н.Арсланнар үрнәген кыйбла итә. Дөрес, әлеге исемлектәге кайберәүләрнең үк аның каршына ясалма киртәләр корулары сәбәпле, аңа шактый еллар шигърият күгенең бер читендә беленер-беленмәс кенә җемелдәп тору гына насыйп була. Әммә ул үзенең чамасын белә, күңелен төшерми, чын шагыйрь булып яши. Иҗатына талапчәнлеген киметми. Әсәрләренең шигърилегебезгә дә кирәклеген, алга таба да кадерле булачакларын аңлап эш итә.

Моны мин шагыйрьнең җитмеш яше тулуга багышланган китабын әзерләгәндә ачык аңладым. Бервакыт шалтырата:

– Беләсеңме, юбилей китабыма шигырь сайлый-сайлый аптырадым. Бусын калдырсам да, кызганыч, тегесен кертмәсәм дә аяныч. Күктүбәгә киткәнче нәшриятка бирепр калдырыйм дип тотынган идем, әммә берни дә килеп чыкмады, төзи алмадым. Бәлки, син булышырсың. Сиңа, чит кешегә, аларның нинди сәбәпләр аркасында, нинди хисләр кичереп язылганлыгы билгеле түгел, шуңа күрә читкә этеп кую да газаплы булмас.

– Юк шул, вакытым юк, бер атнадан Күктүбәгә китәм.

– Шулаймыни? Мин дә шунда җыенам бит. Мин, алай булгач, әсәрләремне шунда алып барыйм, бергәләп Кара диңгез буенда сайларбыз.

Без егерме көннән артык Кырымда шушы эш белән мәшгуль булдык. Мин алып куям, ул ачулана-ачулана кире куйдыра. Син шигырь таный белмисең дип тә әйткәли. Ачуланышып бетә яздык.

Әммә ул китапны нәшриятка тапшыра алмады. Җитмеш яшенә нәкъ бер ай кала (1993 елның 15 мартында) вафат булды. Мин аның китабын чыгаруны ахырына кадәр җиткерергә кирәк дип санадым. Аны төзеп, кереш сүз дә язып, нәшриятка илттем. Р.Рахман мөхәррирлегендә «Якты моң» дигән ул китап басылып чыкты. Шуның белән шагыйрь рухы алдындагы үз бурычымны күпмедер үтәдем дип канәгатьлек кичердем.

Ләкин күңелендә кешеләргә карата бары тик игелеклелек кенә булган зат алдындагы бурычларны үтәп кенә бетереп буламы соң? Менә шуларның берсе генә. 1989 елда әнием вафат булды. Педагогика институтындагы хезмәттәшләрем газетада кайгы уртаклашып язып чыкты. Моңа кадәр әллә ни аралашмаган, әдәбият мәйданында көрешкәләп, кыска-кыска әңгәмәләшеп кенә йөргән Мәхмүт Хөсәеннән хат алам. Никадәр җылы, үз итеп, хәлгә кереп язылган хат!

«Кадерле Фоат туган! Газетабыз күңелсез хәбәр алып килде: әнием Нурхәят апа вафат булган икән. Мондый җан тетрәткеч фаҗигане мин үзем 1976 елда кичердем. Газиз әнинеңне югалту – үзеңнең яртылаш сүнүең ул. Дөньяда әнидән дә изгерәк, кадерлерәк һәм сынмас рухыңа юктыр. Рухи халәтең авыр чакта янында аумас терәк булып ул кала. Шуңа да ул газиз, шуңа да ул мәрхәмәтле бөек зат. Чиксез хәсрәтеңне уртаклашам.

Сине озак еллар буе тыйнак дустым, талантлы каләм иясе һәм зирәк галим итеп беләм. Хәл-әхвәлең тетрәткеч булса да ихтыяр көчеңә һәм сынмас рухыңа ышанам. Сабыр төбе, сары алтын, диләр. Үзеңне сакла, син татар халкы өчен бик тә кирәк җан иясе, Фоат туган.

Синең белән бергә кайгыручы агаң Мәхмүт Хөсәен.

20 август, 1989 ел. Казан».

Никадәр ихлас сүзләр һәм аларның иң кирәк вакытта әйтелүе миңа бик көчле тәэсир итте. Бу затның шундый киң күңелле икәнлегенә рәхмәтле булдым.

М.Хөсәеннең әниләр турында шулай бик тә матур итеп әйтүе очраклы түгел. Аның «Әнием миләше» шигыре дә шуны раслап тора. Әнисенең каберe өстенә шагыйрь миләш агачы утырта. Ул тиз арада матур булып үсеп тә китә. «Әнием миләше» исемле җыр (Ганс Сәйфуллин музыкасы) әнә шулай туа.

Син гел, әнкәй, исән күңелемдә,
Бүген дә син рухи терәгем.
Бакчалардан көзен карый сыман
Кызыл миләш булып йөрәгең,
Миләш булып карый йөрәгең.

Бүген инде әлеге миләш әнисе янына җирләнгән Мәхмүт Хөсәеннең кабере өстенә дә күләгәсен төшереп тора. Аның янында басып торганда, әлеге җыр искә төшә, ул, якты моң булып, күңелдә тирбәлә.

Фоат ГАЛИМУЛЛИН.

Өч конверт

Шундый мәзәк бар. Янәсе, Сталин Хрущевка өч конверт калдырган һәм, әгәр ил кризис чигенә җитсә, аларны берәм-берәм ачарга боерган. Беренчә елдан беренче кризис башланган. Хрущев конвертны ача һәм укый: "Барысын да миңа сылта. Коба", – диелгән. Икенче кризис – икенче конверт: "Тагын бар гаепне дә миңа өеп калдыр. Коба". Өченче кризис. Хрущев укый: "Өч конверт әзерлә".

("Лента.ру").

Дүрт йөрәк "туздырабыз"

Британия медиклары раславынча, кеше организмы бертуктаусыз эшли торган үзенчәлекле фабриканы хәтерләтә. Ул бик нәтиҗәле эшли һәм безнең эчке әгъзаларыбызны даими яңарта. Галимнәр фикеренчә, сезгә 100 яшь тулса да, бавырыгызга 5 ай чамасы гына булачак. Британиянең танылган хирургы Дэвид Ллойд әйтүенчә, операция вакытында бавырның 70 процентын кисеп алсаң, 2 айдан инде ул югалткан күләменең 90 процентын яңадан торгыза. Бик каты эчкән кеше бавырының тиз арада тузып бетмәве дә нәкъ шуның аркасында гына. Үпкәнең тышкы күзәнәкләренең яше нибары 2-3 атнадан артмый, ә эчке күзәнәкләрне тулысынча яңартуга исә 1ел кирәк. Һәр 2-4 атна саен кеше тиресен алыштыра, әмма олыгайган саен аңа сыгылмалылык бирә торган матдә – коллаген аксымы кими бара, шунлыктан җыерчыклар барлыкка килә. 10 ел эчендә инсанның скелеты да алмашына, әмма олыгайгач, әлеге процесс әкренәя, нәтиҗәдә сөякләр нечкәрә. Эчәклектәге туклыклы матдәләрнең үзләштерелүенә булышучы күзәнәкләр 2-3 көнгә бер яңартыла. Даими рәвештә кислота кебек көчле химик матдә тәэсирендә ашалганга, алар тиз арада алмашынырга сәләтле. Нью-Йорк галимнәре исә йөрәкнең дә 3-4 елга бер тапкыр тулысынча яңартылуын ачыклаган. Ә менә баш мие һәм күзләр яңартылуга сәләтсез, алар кеше белән бергә картая.

("Die Presse").

Кишер чыннан да үстерә

Буе начар үскән балага кызгылт-сары төстәге яшелчәләр – кабак, кишер, татлы борычны күбрәк ашарга киңәш итеЛә. Озакка сузылган тикшеренүләрдән соң Израиль галимнәре шундый нәтиҗә ясаган. Иерусалимдагы Яһүд университеты диетологлары үсешләре нормадан калышкан 3-16 яшьлек 300 баланы күзәткән. Бер төркемнең диетасына көн саен кишер, кабак, татлы борыч керткәннәр, икенчесен гадәттәгечә ашатканнар. Беренче төркем балалары елына 8 сантиметрга, икенчесендәгеләр 4 сантиметрга гына үскән. Доктор Тали Синай әйтүенчә, А витамины, тимер һәм цинк җитешмәсә, организм начар үсә. Баланы синтетик витаминнар белән ирексезләмичә, табигый бета-каротин белән "сыйлау" яхшырак. Бер үк вакытта антиоксидант та, кызгылт-сары буягыч та булган бета-каротин – А витаминының элгәре. Әлеге витамин исә сөяк үсү процессында катнаша, күзләр һәм сулыш системасының лайлалы тышчасын, шулай ук тамырларны саклый. Өлкән кеше өчен бета-каротинның тәүлеклек нормасы 6 мг булса, сабыйлар өчен ул 2,5-4 мг тәшкил итә. 100 г кабакта 1,5 мг, 100 г кишердә – 1,1 мг бета-каротин бар. Әлеге матдәгә иң бай җиләк-җимешләр – сырганак (100 граммында 10 миллиграмм), миләш (9 мг) һәм гөлҗимеш (6,7 мг). Әмма А витаминының майда гына эрүен онытмау зарур, шунлыктан баланың рационына, һичшиксез, май кертелергә тиеш.

("The Local").

15 минут җитә

Акылдан язар өчен, кешегә 15 минут вакыт та җитә икән. "Нерв тайпылышлары турында журнал" уздырган тикшеренү нәтиҗәләре шуны күрсәткән. Галимнәр сынауда катнашучыларны берәм-берәм дөм караңгы, тавыш үткәрми торган бүлмәгә япкан. 15 минуттан соң сау-сәламәт һәм психикасы нык кешеләрдә дә галлюцинация башланган. Галимнәр фикеренчә, мондый вакытлыча акыл зәгыйфьлеге баш мие иялəшкән мәгълүматның җуелуыннан килеп чыга.

("Fishki.net").



Өрәк-кала

Төркиядәге игезәк замоклардан гына торган ташландык Бурҗ-әл-Бабас шәһәре хуҗасызлык һәм караклыкка мисал булып тора. Проектка 205 миллион доллар акча бүлгәннәр, һәм 2014 елда Согыд Гарәбстаны вә Күвәйт байлары өчен әкияттәгедәй күркәм кала салына башланган, әмма хәтта акча капчыклары да 350-500 мең долларга сатып алырга ашкынып тормаганга, 2018 елда төзелеш компаниясе банкротлыкка чыккан һәм эш туктатылган. Ул вакытка 587 замокның тышкы диварлары өелеп беткән, әмма матур фасад артында әле бернәрсә дә эшләнмәгән булган, һәм өрәк-шәһәр хәзергә кадәр шул килеш тора бирә.

("Nation Geographic").

Тикшеренүчеләр ачыклаганча, Тын океанның төньяк өлешендәге галәмәт зур чүп-чар утравының 90 процентлан артыгы нибары алты илдән туплана: 33,6 проценты Япониядән, 32,4 проценты Кытайдан, 9,9 проценты Көньяк Кореядән, 6,5 проценты АКШтан, 5,6 проценты Тайваньнан, 4,7 проценты Канададан агып килә.

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

14 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...»
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «КӨМЕШ НАРАТЛЫК». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Татарлар». 12+
17.30 «Татарстан без коррупции». 12+
19.00, 20.00, 0.15 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Каравай». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.40 «Шаян хәлләр». 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «Йөрәктән - йөрәккә». Шамил Бариев турында телеочерк. 6+
15.30 «Заман көзгесе». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
19.10, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЖЕЛТЫЙ ГЛАЗ ТИГРА». 16+
10.30, 21.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.30 «СЫН». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «СЕМЬ ФУТОВ ПОД КИЛЕМ». 12+
14.30 «Связь времен. История доброй воли». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Ступени победы». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.40 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ШИФР». 16+
22.40 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «БАРЕНЦЕВО МОРЕ». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.40, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 Невский ковчег. Теория невозможного. Леонид Говоров.
8.00 Черные дыры. Белые пятна.
8.50, 16.35 «ЛИЧНОЕ СЧАСТЬЕ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Хоккей Анатолия Тарасова».
12.15 Дороги старых мастеров. «Балахонский манер».
12.30, 22.15 «КЛУБ ЖЕНЩИН».
13.35 Линия жизни. Алексей Гуськов.
14.30 «История русского быта».
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора». с Михаилом Швыдким.
16.25 Цвет времени. Иван Мартос.
17.50 К 160-летию Санкт-Петербургской консерватории. Вокалисты. Елена Образцова.
19.00 Жизнь замечательных идей. «Спать, чтобы жить».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.50 Больше, чем любовь.
21.30 «Сати. Нескучная классика...»
23.20 «Первые в мире».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «СПЕЦБАТ». 16+
22.00, 0.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+

Сишәмбе

15 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...»
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.00 «Азбука долголетия». 6+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «КӨМЕШ НАРАТЛЫК». 16+
13.00 «Родная земля». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Теймә».
16.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 6+
21.00, 0.15 «Соотечественники». 12+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
15.30 «Яралы язмышлар». Фәтхерахман Әхмәдиев. 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 21.25 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 12+
19.05, 22.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЖЕЛТЫЙ ГЛАЗ ТИГРА». 16+
10.30, 21.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.30 «СЫН». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «СЕМЬ ФУТОВ ПОД КИЛЕМ». 12+
14.30 «Связь времен. История доброй воли». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Ступени победы». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ШИФР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «БАРЕНЦЕВО МОРЕ». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Бастионы власти».
8.35 Цвет времени. Василий Поленов. «Московский дворик».
8.45, 16.35 «ЛИЧНОЕ СЧАСТЬЕ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «В апреле у Акимова».
12.15 «Забытое ремесло».
12.30, 22.15 «КЛУБ ЖЕНЩИН».
13.50 «Игра в бисер» «Астрид Линдгрен. Трилогия о Карлсоне».
14.30 «История русского быта».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Передвижники. Савва Мамонтов».
15.50 «Сати. Нескучная классика...»
17.50 К 160-летию Санкт-Петербургской консерватории. Вокалисты. Евгений Нестеренко.
18.45 Цвет времени. Леонид Пастернак.
19.00 Жизнь замечательных идей. «Неживая жизнь».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.50 Искусственный отбор.
21.30 «Белая студия».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «СПЕЦБАТ». 16+
22.00, 0.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+

Чәршәмбе

16 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...»
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.00, 0.15 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «КӨМЕШ НАРАТЛЫК». 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Мой формат». 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем…». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 Телефильм. 12+
21.00 Документальный фильм. 12+
23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.40 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
12.35 «Кыргый океан серләре». 6+
15.30, 0.15 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 21.25 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 12+
19.05, 22.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.30 «Юлчы». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЖЕЛТЫЙ ГЛАЗ ТИГРА». 16+
10.30, 21.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.30 «СЫН». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ПОГРУЖЕНИЕ». 16+
14.35 «Десять месяцев, которые потрясли мир». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Ступени победы». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ШИФР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «БАРЕНЦЕВО МОРЕ». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Бастионы власти».
8.35 Цвет времени. Ван Дейк.
8.45, 16.35 «ЛИЧНОЕ СЧАСТЬЕ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «В честь королевы романса... Изабелла Юрьева».
12.20 «Забытое ремесло».
12.35, 22.15 «ЗАПОМНИТЕ МЕНЯ ТАКОЙ».
13.45 Юбилей Инны Соловьевой. Эпизоды.
14.30 «История русского быта».
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 «Белая студия».
17.50 К 160-летию Санкт-Петербургской консерватории. Вокалисты. Ирина Богачёва.
18.45 Цвет времени. Тициан.
19.00 Жизнь замечательных идей. «Первые обитатели Земли».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.50 Абсолютный слух.
21.30 75 лет Владимиру Ильину. Острова.
23.20 «Первые в мире».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «СПЕЦБАТ». 16+
22.00, 0.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+

Пәнҗешәмбе

17 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 6+
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00, 0.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «КӨМЕШ НАРАТЛЫК». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 6+
14.15 «Рыцари вечности». 12+
14.45 «Оныта алмыйм...»
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.30 Хоккей. «Ак Барс» - СКА. 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Безнең Республика - безнең гамәл». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
10.40 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Таяну ноктасы». 16+
12.35 «Кыргый океан серләре». 6+
15.30, 0.15 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 21.25 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 12+
19.10, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Зөлфәт турында телеочерк. 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЖЕЛТЫЙ ГЛАЗ ТИГРА». 16+
10.30, 21.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.30 «СЫН». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ПОГРУЖЕНИЕ». 16+
14.35 «Десять месяцев, которые потрясли мир». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Ступени победы». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ШИФР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+

14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «БАРЕНЦЕВО МОРЕ». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Великая французская революция».
8.35 Цвет времени. Эль Греко.
8.50, 16.35 «ЛИЧНОЕ СЧАСТЬЕ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Юрий Трифонов. Страницы творчества».
12.15 Цвет времени. Павел Федотов.
12.35, 22.15 «ЗАПОМНИТЕ МЕНЯ ТАКОЙ».
13.45 «Под знаком Льва».
14.30 «История русского быта».
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Пряничный домик. «Деревянное зодчество Русского Севера».
15.50 «2 Верник 2».
17.50 К 160-летию Санкт-Петербургской консерватории. Вокалисты. Ольга Бородина.
18.40 «Забытое ремесло».
19.00 Жизнь замечательных идей. «Загадка письменности майя».
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Сергей Дмитриев. «Русские поэты и Иран».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.50 «Зеркало для героя». Заело время».
21.30 «Энигма. Дмитрий Синьковский».
23.25 «Первые в мире».

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «СПЕЦБАТ». 16+
22.00, 0.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+

Җомга

18 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Онытa алмыйм...»
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00, 0.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «КӨМЕШ НАРАТЛЫК». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Мой формат». 12+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Аулак өй». 6+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Родная земля». 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Юлчы». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «КВН РТ-2022». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Уткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Болытларда пәрдә ачкан күңел...» Наилә Гәрәева турында телеочерк. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 0.40 «Калеб». 6+
18.20, 21.25 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 12+
19.15 «Родная земля». 12+
19.40 «Заман көзгесе». 6+
20.10, 22.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЖЕЛТЫЙ ГЛАЗ ТИГРА». 16+
10.30, 21.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.30 «Страшно. Интересно». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «ПОСЛЕДНИЙ ШАНС ХАРВИ». 16+
14.35 «Десять месяцев, которые потрясли мир». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Ступени победы». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 Фантастика. 12+
23.50 «Софи Лорен. Несравненная». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.30 «Дуэты». 12+
23.45 «Улыбка на ночь». 16+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Великая французская революция».
8.35 Цвет времени. Леонардо да Винчи. «Джоконда».
8.45, 16.30 «ЛИЧНОЕ СЧАСТЬЕ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «ЧЕЛОВЕК В ФУТЛЯРЕ».
13.00 Открытая книга. Сергей Дмитриев. «Русские поэты и Иран».
13.30 Власть факта. «Викторианская цивилизация».
14.15 Острова. Патриарх Тихон.
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Дмитрий Синьковский».
16.15 Цвет времени. Жан Огюст Доминик Энгр.
17.40 К 160-летию Санкт-Петербургской консерватории. Вокалисты. Владимир Атлантов.
18.45 «Билет в Большой».
19.45 «ЖЕСТОКИЙ РОМАНС».
22.05 «Необъятный Рязанов». Гала-концерт в Московском международном Доме музыки.

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «Следствие вели...» 16+
11.00 «ДедСад».
12.00 «Неизлечимого все меньше». 12+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «СПЕЦБАТ». 16+
22.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+

Шимбә

19 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Онытa алмыйм...»
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Туган авылым». 6+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.00 Хоккей. «Авангард» - «Ак Барс». 6+
15.30 «Видеоспорт». 12+
16.00 «Ничек сезнең хәлләрегез!» Зәйнәб Фәрхетдинова. 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.00 «КАК ВОСПИТАТЬ МУЖА». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 22.10 «Йөрәктән-йөрәккә». Мирхәйдәр Фәйзи турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Туган авылым». 6+
13.20 Дания Нуруллинаның юбилей кичәсе. 6+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 Искәндәр Биктаһировның юбилей концерты. 6+
23.00 «Галиябану». Телевизион спектакль. 12+

«ЭФИР»
5.00 «Фронтовая Москва. История победы». 12+
5.30 «Связь времен. История доброй воли». 12+
6.00 «Люди РФ». 12+
6.30 «Меганаука». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
8.00 «Один день в городе». 12+
8.30 «Полиция в городе». 16+
8.40 «Я ТРЕБУЮ ЛЮБВИ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «СТРАННАЯ ЖИЗНЬ ТИМОТИ ГРИНА». 12+
15.00 «Клятва Гиппократа». 12+
15.30 «ВЕЧНЫЙ ОТПУСК». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ПРОШЛОЙ НОЧЬЮ В НЬЮ-ЙОРКЕ». 16+
22.35 «ДЕТЕКТИВ-ГУРМАН». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «ПроУют».
11.10 «Поехали!» 12+
12.15 «Видели видео?»
13.40 «Софи Лорен. Несравненная». 16+
14.45 «ГРАФИНЯ ИЗ ГОНКОНГА». 12+
16.55 «Горячий лед». Фигурное катание.
18.20 «Снова вместе. Ледниковый период».
21.00 «Время».
21.35 «КВН». 16+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Доктор Мясников». 12+
12.35 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ПОД ОДНОЙ КРЫШЕЙ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 «ЖЕСТОКИЙ РОМАНС».
9.25 «Мы - грамотеи!»
10.05 «Обыкновенный концерт».
10.35 «БЕЗ СВИДЕТЕЛЕЙ».
12.10 Земля людей. «Эскимосы. Шум моря».
12.40 Черные дыры. Белые пятна.
13.20 «Великие мифы. Одиссея».
13.50 «Земля, взгляд из космоса».
14.40 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.50 Отсекая лишнее. «Олег Буров. Диалог».
16.35 «ТРИ ТОЛСТЯКА».
18.05 «Энциклопедия загадок».
18.35 «О БЕДНОМ ГУСАРЕ ЗАМОЛВИТЕ СЛОВО».
21.15 «Эстрада, которую нельзя забыть».
22.00 «Агора». с Михаилом Швыдким.
23.00 «ДЭЙЗИ МИЛЛЕР».

«НТВ»
5.10 «Спето в СССР». 12+
5.55 «ИНСПЕКТОР КУПЕР». 16+
7.30 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Секрет на миллион». 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. СИМБИРСКИЕ МОРОЗЫ». 12+
22.30 «Ты не поверишь!» 16+
23.30 «Международная пилорама». 16+

Якшәмбе

20 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Онытa алмыйм...»
6.00 «Син минем тиң ярым...» Зинира һәм Ризат Рамазановлар концерты. 6+
8.00 «Адымнар». 12+
8.30 Мультфильм.
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Туган авылым». 6+
11.20 «Без». Илсөя Бәдретдинова концерты. 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 12+
13.00 «Говорит Россия! Запорожская область». 12+
14.30 Гала-концерт фестиваля творчества работающей молодёжи «Безнең заман». 6+
17.30 «Видеоспорт». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «ПОБЕДИТЕЛЬ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 «Адымнар». 12+
7.30 «Казанның кадерле кичләре». Зөһрә Сәхәбиева концерты. 6+
9.30, 22.50 «Йөрәктән-йөрәккә». Шәүкәт Галиев турында телеочерк. 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.00 «Туган авылым». 6+
13.20 «Чын шигырьгә әверелә шагыйрь». Ркаил Зәйдулланың юбилей кичәсе. 12+
16.00 «Җырлап яшим». Ринат Ибраһимов җырлый. 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 Спектакль «Гаугалы гаилә». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Фронтовая Москва. История победы». 12+
5.30 «Связь времен. История доброй воли». 12+
6.00 «Люди РФ». 12+
6.30 «Угрозы современного мира». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
7.50 «Три кота. Сезон 3».
8.00 «Один день в городе». 12+
8.30 «ВЕЧНЫЙ ОТПУСК». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ПРОШЛОЙ НОЧЬЮ В НЬЮ-ЙОРКЕ». 16+
14.40 «Полиция в городе». 16+
14.50 «Страшно. Интересно». 12+
15.40 «Я ТРЕБУЮ ЛЮБВИ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «СТРАННАЯ ЖИЗНЬ ТИМОТИ ГРИНА». 12+
23.00 «АНДРОИД». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.10, 6.10 «ПРОСТАЯ ИСТОРИЯ». 12+
6.00, 10.00, 12.00 Новости.
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 К 95-летию со дня рождения Эльдара Рязанова. «Человек-праздник». 16+
13.55 «ВОКЗАЛ ДЛЯ ДВОИХ». 12+
16.40 «Горячий лед». Фигурное катание.
18.05, 23.45 «Романовы». 12+
19.05 «Поем на кухне всей страной». 12+
21.00 «Время».
22.35 «Что? Где? Когда?»

«РОССИЯ»
5.30 «ОСТОРОЖНО! ВХОД РАЗРЕШЁН». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 16.00 Вести.
12.00 «КУЗНИЦА СЧАСТЬЯ». 12+
17.00, 19.00 «Песни от всей души». 12+
18.00 Всероссийский конкурс юных талантов «Синяя Птица».
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.20 «ТРИ ТОЛСТЯКА».
8.45 Тайны старого чердака. «Пейзаж».
9.15 Диалоги о животных.
10.00 Передача знаний.
10.50 «МЕСЯЦ МАЙ».
12.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Алексей Ухтомский.
12.35 «Игра в бисер» «Лев Толстой. «Детство».
13.15 «Элементы» с Антоном Успенским».
13.45 100 лет российскому джазу. Легендарные исполнители. Ансамбль «Аллегро» под управлением Николая Левиновского.
14.45 «БАНДА ЧЕСТНЫХ».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Пешком...»
17.40 Юбилей Виктории Токаревой. Линия жизни.
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «Ульянов про Ульянова».
21.00 «БЕЗ СВИДЕТЕЛЕЙ».
22.35 Опера «Геликон-опера».

«НТВ»
5.05 «ИНСПЕКТОР КУПЕР». 16+
6.40 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Суперстар! Возвращение». 16+
23.20 «Звезды сошлись». 16+

Бала түгел, бәла ул

Үз аналарына көн күрсәтмәгән балаларны башкача атап булмас. Әлмәт районында яшәүче 1947 елгы карчыкның үз баласыннан күргән җәбер-җәфа һәм хурлыклар турында аның исемен үзгәртеп, авылын атамыйча сөйләргә туры килә. Чөнки сүз, башлыча, четерекле хәлләр турында барачак.

Галина Галкина әлеге авылга ире, ике баласы белән 40 ел чамасы элек күченеп килә. Картаймыш көнендә 1974 елгы юньсез улы Александр Кузнецов белән генә кала ул. Чөнки алданрак гаилә башлыгы вафат була, 2016 елда Кама Аланы бистәсендә яшәгән кызы дөнья куя.

Александр кечкенәдән проблемалы малай була. Акыл ягыннан бераз кимчелекле дип табылып, 8 яшендә психиатрга исәпкә куела, 1 нче класста кучми кала, коррекция мәктәбенә бирелгән тә начар укый, 7 нче сыйныфтан соң укуын бөтенләй ташлый, димәк, һөнәри белем дә алмый, очраклы эшләргә йөреп тамак туйдыра, гаиләсе, балалары булмый. Хәзер 48 яшендәге ир-ат, рухи кимчелекләреннән бигрәк, эчәргә хирыс була. 2015 елдан бирле табиб-наркологта да исәптә тора ул.

Шул елларда аның исерек баштан кылган кыланмышлары закон чиген үтеп чыга башлый. Полициягә чит кешеләргә карата эшләгән явызлыклары өчен түгел, ялгыз калган анасын кыерсытып эләгә ул. 2014-2015 елларда нәкъ шул сәбәпле «Үтерү белән янау» дигән маддә буенча өч мәртәбә хөкемгә тартыла, бары тик әни кеше каты тормаганга күрә генә, шартлы рәвештә иреген нән мәхрүм ителеп килә. 2017 елда шундый ук җинаяте өчен 1 ел да бер айга колоние поселениегә озатыла. 2018 елда ирекккә чыгып, төп нигезгә кайта.

Бичара карчык өчен газаплы көннәр, улыннан качып, күршеләрдә кунып йөрүләр башлануны аңлата бу. Ике-өч айдан Александр Сания атлы хатын белән тора башлый, күрше авылдагы хуҗалыкка көтүче булып урнашкач, шундагы торакта яшиләр. Әлеге тынычлык ике ай чамасы гына дәвам итә, хатын-кыз котырынкы исерекбашны ташлап китә. Икенче көнне үк төнгә каршы сәрхүш малай анасы тәрәзәсен шакый, карчык кеше курыкса да, аны кертмичә булдыра алмый.

Ул вакытта 69 яшендә булган Галинаның курку-шикләнүләре тиздән аклана. Бу җәһәттән, күргән-белгәннәрнең һәм Г.Галкинаның соңрак биргән күрсәтмәләрендә А.Кузнецовның элегрәк тә әнисе белән җенси мөнәсәбәткә керергә омтылуларына ишарә ясалуын искәртеп үтик. Ләкин моңа кадәр әни кеше бу хакта хокук саклау органнарына җиткерергә батырчылык итми.

Мондый хәлләрне тәфсилләп сөйләп булмый, әлбәттә. Кыскача гына әйткәндә, исерек Кузнецов алдан үзе чишенә, аннан соң әни карчыкны караватка төртеп егып, законда зарар күрүченең каршылык күрсәтә алмавыннан файдалану һәм көч кулланып җенси мөнәсәбәткә керү дигән җинаятьчел гамәл кыла. Тәкатьсезлеген канәгатьләндергәннән соң, өйалдында йокларга ята. Бичара карчык иртәнге сәгать 5 ләр тирәсендә генә күршеләргә кереп качу җаен таба.

Бу хакта авылда сүз чыкмый калмый, билгеле. Чөнки Галина хуҗабикәгә дә сөйли, төнлә белән кычкырып ярдәмгә чакыруымны ишетмәдегезме, дип шул тирәдә яшәүчеләрдән сораша һәм аларга да хәбәр итә. Ул гына да түгел, Галинага иртүк, эшкә чыкмаган көтүчесен эзләп, ферма мөдире Раиф та шалтырата, карчык аның өйдә икәнен, төнлә белән үзен көчләвен ирештерә. Маллары утарда торган терлекче А.Кузнецовны килеп алып китә.

Әлбәттә, бу хакта белүчеләрнең берсе дә полициягә йөгерми. Галина үзе һәм күршесе Татьяна иртә белән участок инспекторы Л.Минһаҗетдиновка шалтыратып карыйлар, әмма ул чакта ялда булган хезмәткәр җавап бирми. Бары тик дүрт көннән соң гына, куркып авылдашлары өендә куныпт йөргән карчык, Әлмәт эчке эшләр бүлегеннән үз участковыйлары вазыйфасын үтәүче хезмәткәрнең телефонын алып, аның белән элемтәгә керә, Эзләү-тикшерү эшләре башлангач та, авыл хатынының үзенең күлмәк-ыштаннарын, малаеның эчке киемнәрен, урын-җир җәймәләрен юып киптерүе, димәк, дәлилләрне юк итүе мәгълүм була. Ләкин тикшерү эшләренә әллә ни комачау ясамый бу.

Тагын өч көннән тоткарланган А.Кузнецов тикшерү комитетының Әлмәт бүлегеннән Алинә Баһаветдиновага биргән беренче күрсәтмәләрендә үк олы яшьтәге анасы белән якынлык кылуын таный, әмма вакыйганы сәер итеп сурәтли. Карчык кеше аны эчкәнгә күрә Сания дә ташлап китте дип орышып кына калмаган, өйгә минем белән уйнашлык кылу өчен генә кайтасың дип, кыскача әйткәндә, аның дәрт-дәрманын уятырдай гамәлләр дә эшләгән, шуңа күрә ул әлеге гамәлен ирекле дип уйлаган, имеш.

Ошбу бәянне шук ук көнне үткәрелгән «очная ставка», ягъни әнисе белән кара-каршы утырып сорау алуда да кабатлый ул. Г.Галкина, әлбәттә ки, бу хикаяне хак түгел дип белдерә һәм сәрхүшкә барысын да сөйләп күрсәтә. Шуннан соң А.Кузнецов әнисе күрсәтмәләрен раслый, гаебен танып әйтеп, яңа аңлатма бирә.

Шулай итеп сак астына ябыла, әнисен көчләүдә гаепле дип табылып 4 елга ирегеннән мәхрүм ителә һәм 2018 ел азагында Питрәч районындагы Пановка колониясенә озатыла.

Тәүәтү колониясеннән тәэлеп кайтмаячагын белгән бәхетсез ана улы белән очрашудан куркып гомер итә. Быел 8 июньдә азат ителгән Александр шул көнне үк лаякыл исерек кайтып керә. Шатлыклы вакыйга булмый бу, ләкин шуннан соң берничә көн эчмичә, хуҗалык эшләрендә булышып йөреп эчкә җылы кертә. Бусы да озакка сузылмый, нәкъ бер атнадан алдан өендә эчеп утыра, аннан соң Назыйм атлы дусты янына китә, анысы Галинага шабашкага барабыз дип, улының бу көнне кунарга кайтмаячагын әйтеп тынычландыргандай итә. Ләкин шомланган карчык 16 августка каршы төнне урам эскәмиясендә утырып үткәрә, бары тик иртәнге сәгать 5 нче дә генә өенә кайтып ята. Шикләнүләре раскилә аның, ярты сәгать тә үтми, тәрәзә шакыган тавыш ишетелә, лаякыл исерек бәндә курткамны гына алам да Әлмәткә сөйгәнем янына китәм дип алдалый.

Ул өйгә кергәч тә, дүрт ел элек булган хәл тагын кабатлана. Бу юлы явызрак та кылана әле ул, чәбәләнеп каршылык күрсәткән, битләрен тырнаган, кычкырган әнисенә суга, авызына чүпрәк тутыра, муенын да кыса хәтта һәм үтерү белән куркыта, бер сәгать чамасы көчләгәннән соң туктап: «Мин кайткач дәвам итәрбез», – дип чыгып китә. Аңа кадәр әнисенең кулларын бәйли, авызын чүпрәк белән каплый, ишекне алдан әчтән, аннан соң, тәрәзәдән чыгып, тыштан йозакка бикли.

Ләкин Г.Галкина кулларын чишү әмәлен таба, ашык-пошык киенеп оекчан килеш тәрәзәдән урамга чыгып чаба һәм күрше урамдагы йортка барып керә. Ошбу авылда куптән түгел генә яшәүче Максим шешенгән битле, ярсыган кыяфәтле әбигә чүәкләр кидерә, ни булганын аңлагач полициягә хәбәр итә, ул гына да түгел, таныш булмаган авылдашын Әлмәт эчке эшләр бүлегенә илтеп куя. Полициядә мәгълүм зат шул көнне үк тоткарланып, колониядән кайтканына 8 көн дигәндә яңадан зинданга ябыла. Әлбәттә, аның бик озакка эләгүен белдерә бу.

Әнисен көчләвен таный Кузнецов, гафу үтенүен белдерә, исерек булганга, ошбу әхлаксызлыкка бару сәбәбен аңлата алмыйм, бәлки берәр кыз белән бутагынмындыр, ди. Көчләвен генә түгел, әнисенә сугуын да, үтерәм дип куркытуын, башкасын да таный. Экспертиза хатын-кызның йөзбит, аякларда 12 күгәргән урын булуын күрсәтә. Кузнецовның үзендә дә хисапсыз күп сыдырылган яралар була. Алар Г.Галкина тырнау нәтиҗәсе икәнен дә яшерми. Өстәвенә, аның әнисен бәйләп, бикле өйдә калдырып китүе кешене ирегеннән мәхрүм итү турындагы тагын бер бик кырыс статья кысаларына эләгә яза. Тәрәзәнең ачык булуы гына коткара аны.

Психиатрлар экспертизасы үз анасына карата шундый кыргыйлык эшләгән 48 яшьлек ир-атның рухи кимчелек-тайпылышлары үз гамәлләрен аңламаслык көчле түгел дип таба. Димәк ки, сәбәпне эчкечелектән күрергә кирәк. А.Кузнецов үзе дә шулай саный. Тикшерү комитетының аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе Раил Зарипов аңа үтерү белән янап һәм көч кулланып җенси мөнәсәбәткә керү дигән җитди гаепләү белдерә. Бу инде аны кырыс җәза көтә дигән сүз, чөнки РФ Җинаять кодексында мондый җинаятьләр өчен 10 елга кадәр иректән мәхрүм итү каралган.

Наил ВАХИТОВ.

Театр училищесының гасырлык бәйрәме

Казан театр училищесы 100 еллыгы уңаеннан ноябрь ае дәвамында спектакльләр күрсәтә, күргәзмәләр ача, осталык дәресләре үткәрә. Төп юбилей кичәсе Камал театрының зур сәхнәсендә узачак.

Юбилей чаралары программасы Руслан Риманасның «День Р.» перфомансы белән башланды. Ул 7 ноябрьдә Марсель Сәлимҗанов исемендәге Актерлар йортында үтте.

Кичә Тинчурин театрында Чиләбе камера театры «Мелкий бес» спектаклен тәкъдим итте. Режиссер – Казан театр училищесында укыган Тимур Кулов.

15 ноябрьдә 16.00 сәгатьтә Заманча сәнгать галереясында «История одного дома» күргәзмәсе ачыла. Биредә «Театр-декорация сәнгате» бүлеге эшләре – картиналар, театр гримы эскизлары, бутафория предметлары һәм театр костюмы элементлары белән танышып була. Күргәзмә 15 декабрьгә кадәр эшли.

17 ноябрьдә Заманча сәнгать галереясында «ART» спектакле (Санкт-Петербург) күрсәтелә. Режиссер – Казан театр училищесын тәмамлаган Руслан Нанава.

28 ноябрьдә Камал театрында юбилей кичәсе. Программаны Казан театр училищесында укыган режиссерлар һәм актерлар әзерли.

«Безнең училище татар һәм рус бүлекләре булуы белән уникаль. Татарстан театрлары артистларының 90 проценты әлеге уку йортын тәмамлаган. Безнең егетләр Калининградтан Владивостокка кадәр эшли», – ди Казан театр училищесы директоры Руфина Таҗетдинова.

Әкиятче бабайның кайтуы, яки «Тылсымлы арена»

Тинчурин театры сәхнәсендәге цирк хайваннары пошаманга төшкән, чөнки Австралиядән зебра белән көнгерә килә икән, алар әллә нинди фокус-покуслар күрсәтә белә, шуңа күрә җирле юлбарыс, фил, аю, попугайга игътибар, хөрмәт бетәчәк, балаларның бөтен мәхәббәте килмешәк хайваннарга булачак, дип куркалар. Инде нишләргә? Арысланга Австралия кунакларын ботарлап ату берни тормый. Әмма хезмәттәшләргә тию ярамый.

Җирле хайваннарга үзләренә фокуслар өйрәнү кала. Гел бертөрле генә яшәп булмас бит инде. Үсәр, камилләшер өчен яңа һөнәрләр үзләштерү кирәк. Баксаң, һәркайсының күңелендә яшерен хыялы булган икән. Фил, әнә, очарга хыяллана. Ишәкнең дрессировщик буласы килә. Хайваннарның, хыялларын барлап, балалар мәхәббәтен югалтмау юлларын эзләгән арада арыслан гына яшерен ният белән кырыйда астыртын хәйлә корып йөри. Аның да хыялы бар – популяр булу, бөтен балаларның игътибарын үзенә генә алмакчы ул. Йолдыз чире йоктырган арысланны кичерерләрме, кабат араларына кертерләрме? Австралия көнгерәсе белән зебрасы Татарстан җиренә нинди ният белән килгән?

Анысын нәни тамашачылар К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында Шамил Фәрхетдинов пьесасы буенча Камил Гатауллин куйган «Тылсымлы арена» спектаклен үзләре карап белсен. Шундый гади генә булса да, тирән мәгънәле, бердәмлеккә, үзара ярдәмләшеп яшәргә чакыра торган бу әкият фокуслар белән үрелеп бара. Казан циркы татар телендә тамашалар куя башлаганда, кояш көнчыгыштан түгел, көнбатыштан чыга башлар, мөгаен. Биредә исә театр да, цирк да барысы бер сәхнәдә. Җете сәхнә костюмнары (рәссам Алия Гайнуллина), җырлар, биюләр (композитор Гөлназ Закирова, оркестр өчен аранжировкалаучы – Ильяс Камал, хормейстер Алия Хәмзина) игътибарны җәлеп итә. Рольләрне алмаш-тилмәш Венера Низамова һәм Гөлназ Нәүмәтова (Мультик), Илнур Байназаров һәм Айдар Фәтрахманов (Пультик), Илфак Хафизов һәм Алмаз Фәтхуллин (Юлбарыс), Миләүшә Нәҗмиева һәм Зөлфия Вәлиева (Филия), Салават Хәбибуллин һәм Зөлфәт Закиров (Ишкулла), Харис Хөснетдинов һәм Булат Зиннәтуллин (Аюхан), Адилә Хәсәнова һәм Альбина Гашигуллина (Зәбирә), Эдуард Никитин һәм Ильмас Насретдинов (Куштәпи) башкара.

Бу тарихта барыннан да ныграк куандырганы – Тинчурин театрындагы штаттагы әкиятче Шамил Фәрхетдиновның кабат язу эшен яңартуы. Үзенчәлекле артист булу өстенә, Ш.Фәрхетдинов байтак еллар нәни тамашачылар өчен кызыклы, бер-берсен кабатламый торган әкиятләр иҗат итте. Бүтән бер театрның да үз әкиятче бабае юк. Тинчуринлыларны исә бу мәсьәләдә бәхет басты. Әкиятче Шамилнең әсәрләре тәмле телле, җиңел, гади, балаларның яшь үзенчәлекләрен, психологиясен истә тотып иҗат ителгән. Хыял байлыгына шаккатарлык. Геройларны, сюжетларны ничек уйлап өлгерәдер?!

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 11.11.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2610 данә

Заказ 2778

16+